Кәрим Җаманаклы

# Әсәрләр

Алабуга
2005



# КЫРЫМ БАКЧАСЫННАН ӨЗЕЛГӘН ГӨЛ

Кеше язмышының ни кадәр үз милләте язмышы белән тыгыз бәйләнгәнлеген кырым татар халкы мисалында аеруча яхшы аңлап була. Бу халык чиккән михнәт-газап һәр кырым татар вәкиленең ата-бабасы һәм үзе өчен рухи фаҗига булып канына сеңгән ...

Алтын Урда составыннан 1443 елда мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыккан Кырым ханлыгы 1783 елда яшәүдән туктый. Аның бар мал-мөлкәтенә, мул туфраклы җиренә Рәсәй империясе хуҗа була. Күпчелек тарихчыларның инануынча, нәкъ менә шул вакыйга белән кырым татарларының милли фаҗигасе башланып китә һәм инде 1944 елгы депортация аның иң югары ноктасы була.

Рәсәй империясе составына кертелгәндә, Кырым ярымутравында, Кубаньда һәм Тамань утравында ул чакта бер миллионга якын татар, Екатеринослав, Херсон, Бессарабия җирләрендә миллионга якын ногай халкы яши. 1913 елда «Тәрҗеман» газетасы хәбәр иткәнчә, Кырым алынып, 130 ел үткәннән соң, барлыгы 200 000 кырымлы, ягъни халыкның уннан бере генә кала ... (1; 250). Чөнки руслар басып алганнан соң, 300 000 татар үз ватаныннан куыла, 1853-1856 елгы рус-төрек сугышы вакытында тагын 200 000 кырымлы туган җирен ташлап китәргә мәҗбүр була. Аларның күбесе Төркиягә, Румыния, Болгария якларына күченә. Илдә калган татарларны кысрыклау тагын да

көчләрәк дәвам итә. XIX гасыр буена кырым татарларын руслаштыру һәм җирсез калдыру сәясәте даими эзлеклелек белән алып барыла, Кырымның иң матур урыннарына рус дворяннары килеп йорт һәм дачалар сала, рус губерналарыннан крестьяннар күчереп китерелә. Октябрь инкыйлабы да кырым татарларына мөстәкыйльлек китерми: 1918 елның гыйнварында милли хөкүмәт бәреп төшерелә, азатлык хәрәкәтенең юлбашчысы Ногман Чәләбиҗиһанның үле гәүдәсен большевиклар диңгезгә аталар. 1920 елларда Кырым автономияле җөмһүриятендә милләтчелеккә каршы киң көрәш җәелдерелә һәм татар интеллигенциясе максатчан рәвештә юкка чыгарыла, коллективизация, кулакларга каршы көрәш сылтавы белән тагын күпме кеше илдән куыла. 1939 елгы халык санын алу чорында ярымутрауда яшәгән халыкның бары тик 19% гына татарлар (болар эчендә бары тик кырым татарлары гына кертеп каралмый әле) тәшкил итә ... (2; 10)

1942 елның июленнән Кырым тулысынча фашистлар кулында кала һәм бары тик 1944 елның май уртасында гына дошман ярымутраудан куып чыгарыла. 17-18 май төнендә исә ватанга хыянәттә гаепләнеп, кырым татар халкы иң каты җәзага тартыла: бер төн эчендә Кырымда яшәгән барлык татарны вагоннарга төяп билгесез якка алып китәләр. Юл газаплары (ачлык, сусызлык, йогышлы авырулар, һава җитмәү һ.б.) меңләгән кешенең вакытсыз үлеменә сәбәп була. Исән калып, Үзбәкстан, Таҗикстан, Казахстан, Мари Эл, Себер якларына илтеп ташланган «хыянәтчеләргә» дә дәүләт яшәү өчен бер нинди шартлар да тудырмый гына түгел, аларны каты контроль астында тота, эшкә, укуга, дәүләт органнарына сайлауга һ.б. хокуксыз итә. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда сөргенгә җибәрелгән кырым татар халкының 46,2% үлеп

бетә (2; 36 б.). Совет режимы тудырган геноцидның иң авыр йөге әлеге халык өстенә төшә.

Кырым – гүзәл бакча кебек бер җир. Бу бакчаның хуҗасы булган татар халкы әле бүген дә ватанына тулысынча кайтып бетә алганы юк... Югалган, таралган матди һәм рухи байлыгын эзләү, җыю һәм арттыру өчен кырым татарларына Аллаһ ярдәм бирсен, тарихындагы бу фаҗигаләре соңгысы булып, гел имин һәм рәхәт тормыш насыйп итсен иде.

Укучы кулындагы бу китап геноцид корбаны булган кырым татар интеллигенциясенең күренекле бер вәкиле Кәрим Җаманаклының әдәби иҗатына һәм гыйльми эшчәнлегенә багышлана. Гүзәл Кырым якларыннан килеп, ике дистә гомерен безнең Алабугада уздырган, монда татар зиратында күмелгән шагыйрь, фольклорчы һәм әдәбият галиме Кәрим Җаманаклының тууына 100 ел тула. Аның язмышы, аеруча яшьлек еллары турыдан-туры сугыш, сөргенлек, халкының рәнҗү кичергән дәверенә туры килә, шуңа күрә әлеге афәтләр аның да тормыш юлына гаять көчле йогынты ясаган.

Кәрим Рәшид улы Рәшидов 1905 елның 21 гыйнварендә Кырымның элекке Таврия губернасы Евпатория өязе (Кизләү районы) Җаманак авылында дөньяга килә. Әлеге күп балалы гаилә турында мәгълүматларыбыз аз булса да, аннан кырым татар халкының ике шагыйре – Кәрим һәм Мәннан (1916-1942) Җаманаклыларның чыгуы фактлары гына да күп нәрсә турында сөйли.

Кәрим 1917 елда тутан авылында башлангыч мәктәпне бетерә. 1924 елда Акмәчеткә (Симферополь) килеп, педагогия техникумында укый башлый. Ачлык, фәкыйрьлек вакытлары булса да, егетнең укырга теләге тормыш авырлыкларыннан көчлерәк булып чыга, аягына-

өстенә кияргә, ашарына юклыкка карамастан, күңел төшенкелегенә бирелмичә, бу уку йортын ул 1928 елда яхшы гына тәмамлый һәм Альма-Тархан авылында башлангыч сыйныф укытучысы булып хезмәт юлын башлап җибәрә. Ләкин белем алырга булган омтылыш аңа тынгылык бирми һәм ул педагогия институтына укырга керә, шунда әдәбият белән якыннан кызыксына башлый, тәүге шигырьләрен иҗат итә. Пединститутны тәмамлагач, аспирантурада кала. 1929 елдан партиягә кандидат итеп алына, 1931 елның декабреннән – коммунист.

1930 еллар башында аны Кырым халкы Кәрим Җаманаклы исемле шагыйрь буларак таный: әсәрләре «Яңа дөнья», «Яшь куәт», газеталарында, «Иләри» («Алга») журналы битләрендә басыла, 1927 елда «Азатлык җырлары» исемле шигырьләр җыентыгы чыга, ул Язучылар Берлегенә кабул ителә. 1934 елда Мәскәүгә Язучылар съездына бара. М.Горький кебек зур язучыларның чыгышын тыңлый. Монда Казаннан килгән каләм осталары белән таныша. Танылган драматург Таҗи Гыйззәт белән якыннан дуслашып китә һәм бу дуслык озак еллар буена дәвам итә. Казан татарларына булган җылы мөнәсәбәте аның шәхси тормышына да йогынты ясый. 1933 елда Кәрим Кырымга кунакка килгән кара кашлы, кара күзле Казан кызы Рәшидә Хөсәенова белән таныша һәм алар озак та тормый өйләнешәләр. Тормышлары бик тыйнак була: коммуналь квартирада бер бүлмәдә яшиләр. Яшь гаиләнең берданбер әйберсе – уртак сатып алган чәйнекләре генә була. Кәрим Рәшидәгә югары белем алырга ярдәм итә. Тиздән олы балалары – Илдус, аннары кызлары Фәридә туа.

1937 нче елда Кәрим Рәшидов Казанга килеп педагогия институтының Гыйльми Советында «Кырым татар халык шагыйре Шамил Туктаргазыйның иҗтимагый-әдәби

эшчәнлеге» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Диссертациягә рәсми оппонентлар профессор Галимҗан Нигъмәти һәм Шиһаб Рамазановлар диссертантның эшенә югары бәя биреләр, Ш.Туктаргазый (1883-1914) иҗатының фәндә бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән булуына басым ясап, Рәшидов хезмәтенең актуальлеген күрсәтәләр. Безнең мәгълүматларыбызга караганда, ул тугандаш кырым татар әдәбияты буенча диссертация яклаган беренче филология фәннәре кандидаты була.

Диссертация эше белән Казанга килгәләп йөргән яшь галим мондагы язучылар һәм әдәбият белгечләре белән якыннан таныша, Кырымда дәваланган Галимҗан Ибраһимовтан сәлам-хәбәрләр алып килә.

Куркыныч 1937 ел Җаманаклы өчен дә эзсез узмый. Көннәрнең берендә гади халык арасында «кара козгын» дип аталган машина килеп, аны да алып китә, куркудан йөрәкләре ярыла язган хатыны һәм балалары исә кара кайгы эчендә калалар. Берничә көннән соң аны азат итәләр. Кәрим Җаманаклының «халык дошманы» булганлыгына инанмауларын белдереп, укучылары күпсанлы хатлар язалар ...

Тормышларын рәткә сала башлаган чорда гына сугыш чыга. 1941 елның июлендә инде немецлар Одессага якынлашалар. Акмәчеттә эвакуация башлана. Иң зарури нәрсәләрне генә үзләре белән алып, Кәрим гаиләсе тиз вакыт арасында шәһәрдән чыгып китә. Алар, башка бик күп кешеләр кебек, Совет армиясенең дошманны туган йорттан куып чыгарачагына, сугышның тиздән бетәчәгенә ышаналар, ләкин Кырымга яңадан әйләнеп кайтырга аларга инде бүтән насыйп булмый ...

Кәрим Рәшидов 1941 елның көзендә фронтка китә, 361 укчы полкында хезмәт итә, фронт газеталарына

язына. 1942-1944 елларда ул Казанда яши, ничек һәм ни сәбәпле сугыштан монда килеп чыкканлыгы сер булып кала, кадрлар бүлегендәге рәсми документларында ул Татарстан Совет Язучылар Берлегенә караган «ирекле язучы» дип билгеләнгән. 1944 елдан сугышның азагына кадәр Сәмәрканд пединститутында әдәбият укытучысы-доцент булып эшли. Тик торганда Үзбәкстан якларына китеп баруы, һичшиксез, аның илдән сөрелгән кырым татар халык вәкиле булуы белән бәйле. Гаиләсе исә Татарстанда кала. Сугышка кадәр Акмәчет авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган Рәшидә җиләк-җимеш җитештерүче питомник директоры булып эшли. Бары тик 1945 елның язында гына гаилә Казанда туплана. Аларга Кырымга кайту юлы ябык килеш кала. Кәримнең бөтен туган-тумачасы, сугыштан соң хәрби хезмәтен дәвам иттергән энесе Әбхәйрдән гайре, Урта Азиядә сөргендә яши ... «Сатлык җан» дип гаепләнгән халыкның угылларына хәтта Казанда да урын табылмый ... Коммунист һәм фронтовик Җаманаклы гаиләсен Алабугага җибәрәләр.

Монда ул, нигездә, фәнни-педагогик эш белән шөгыльләнә. Әдәби иҗатка кулы бармый. Халкы бар җирдә каралтылган, туган туфрагыннан куылган чакта шигырьләре дә язылмый ... Әмма Татарстан язучылары аңа төшенкелеккә бирелергә ирек бирмиләр, рухын күтәрәләр, ярдәм итәләр. Тиздән аның язмалары «Совет әдәбияты» журналында күренә башлый, Казан татар әдәбияты белән кызыксынып китә һәм Муса Җәлил иҗаты буенча монография бастыра. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов иҗатына багышланган күләмле мәкаләләр яза. Шулай итеп ул педагог буларак та, әдәбият тәнкыйтьчесе буларак та Татарстанда тагын да үсә, таныла.

Тарихи XX съезддан соң шәхес культы фаш ителгәндә, Кәрим Җаманаклы икс тапкыр Советлар Союзы Герое очучы Әхмәтхан Солтан хакында материал туплау белән шөгыльләнә. Бу бик кыен эш була. Геройның Ватанына кайту һаман да тыелган килеш кала, шуңа күрә мәгълүмат та тамчылап кына җыела. «Кызганычка, ният ителгән повесть язылмыйча калды, авырып ятканда әтием моңа бик кайгыра иде», – дип искә ала кызы Фәридә. Шулай да Җаманаклы әлеге каһарманга багышланган «Кара диңгез кырыенда» исемле шигъри әсәр иҗат итә (*Әхмәтхан Солтан хакында кара: Д.Каримова, Д.Аляутдинова. Избранник неба // «Татарские новости» газетасы, 2004 ел, № 5*).

Алабуга пединститутына Кәрим Җаманаклы гомеренең егерме елын багышлады. Кафедрада мөдир булып эшләде, рус һәм совет әдәбияты буенча лекцияләр укыды, күп еллар дәвамында профсоюз комитеты рәисе булды. Хезмәт кенәгәсендә аның АДПИда тырыш хезмәте өчен даими рәвештә макталганы турында язмалар теркәлгән. Шулай ук 1946 елда аның намуслы хезмәте өчен медальгә лаек булуы да билгеле.

Татарстанның күренекле язучылары, композиторлары һәм артистлары белән тыгыз элемтәдә тора. Кәрим Җаманаклының өенә Салих Сәйдәшев, Нури Арслан, Эдуард Касыймов, Әнвәр Бакиров, Геннадий Паушкин һәм башкалар кунакка килеп йөриләр. Ул Мостай Кәрим, Рафаэль Мостафин, Хәсән Туфан белән дә дус була.

Җаманаклының шагыйрь йөрәге даими табигатькә омтыла. Бөек рәссам И.Шишкин әсәрләрендә тасвирланган Алабуга тирәсендәге гаҗәеп урманнарны Кәрим бик ярата, отпускларын бик еш Кама үзәннәрендә уздыра. Әмма Ватаны Кырымга кайтасы килү, аның киләчәге өчен бор-

чылу йорэген телгэли, йокысыз төннәренә сәбәпче була. «Өебездә кырым татар җырлары, көйләре язылган грамм-пластинкалар бик күп иде, әтием аларны әйләндереп, сәгатьләр буе тыңлап та туймас иде. Кайчакта исә уртага чыгып сөйгән «Кайтарма»сына бии торган иде», – дип сагынып яза кызы.

Шагыйрь, педагог, галим Кәрим Җаманаклының язмышы сугыш, ачлык, репрессияләр, сөргенлек һәм геноцид бәлаләрен башыннан кичергән кырым татар халкының аянычлы тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Ни Кәрим аганың үзенә, ни хатынына кырым татарларының аклануын, Ватанга кайтырга рөхсәт алуларын күрү насыйп булмады. Алабуга аңа һәм балаларына икенче ватан булды. Җаманаклының олы улы Илдус техник фәннәр кандидаты, бик күп еллар Мәскәүдә фәнни – тикшеренү институтында житәкче урыннарда эшләде. Аның ике кызы, өч оныгы бар.

Олы кызы Фәридә – икътисад фәннәре кандидаты, башта Алабуга дәүләт педагогия институтында, хәзер Яр Чаллы шәһәрендә югары уку йортында икътисад кафедрасында доцент булып эшли. Кызы Виктория һәм улы Антон бар. Антон – филология фәннәре кандидаты.

Кече кызы Нурия сугыштан соң туа, әтисенең эзеннән китеп, филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ирешә. Бүгенге көндә Кырымда яши, университетта рус филологиясе кафедрасы доценты. Кызы Гөлшат – чит телләр белгече, фәннәр кандидаты, улы Айдар да фән белән шөгыльләнә.

Кәрим Җаманаклы – зур гаиләдә беренче бала, шагыйрь җанлы кардәше Мәннан (сугышка кадәр шигырьләр җыентыгы нәшер ителгән) 1942 елда Акъяр янында һәлак була. «Бу бәхетле коннәргә ирешкән

кардәшләребез әкрен-әкрен Кырымга кайталар. Рәбия апам (Кәрим Җаманаклының сеңлесе) Чырчыкта кырым татар теле укытучысы булып эшләгән иде, хәзер Кизләү тарафларында яши. Икетуган агасы Фәтислам Әмираметов (Ташкентта булганда әтием гел аның өендә куна иде) инде Җанкөйдә яши. Кардәшләре Азиз һәм Ваит Урта Азиядә. Әбхәир абзый да әтием янында Алабугада күмелде», – дип яза кызы Фәрид Кәримовна.

Кәрим Рәшидов 1965 елның 1 августында Алабуга шәһәрендә авырып вафат була, кабере татар зиратында. «Татарстанда күпме еллар хезмәт итеп, аның куенында калган Кырым егетенә игътибарсызлыкта безне гаепләп булмый», – дип искә ала аның хезмәттәше, язучы Тәлгать Галиуллин. – Заманында Язучылар Союзы Э.Касыймовны, Ә.Гаделне һәм мине кертеп, мәрхүмнең иҗат мирасын туплау комиссиясе төзегән иде. Ул бик акрын булса да, индидер эш башкарды. Кызлары бар булган материалны, атларны, истәлекләрен җыештырып, Кырым татарлары телен дә яхшы белгән Әхмәт Гаделгә тапшырдылар». Күп төрле сәбәпләр аркасында бу җыентык әзерләнеп бетмичә кала. Шагыйрь Әхмәт ага Гадел, Җаманаклы мирасын югалтмыйча саклап, күпмедер күләмдә эшкәртеп, ничә еллар узганнан соң, Алабуга педагогия университетына тапшырды. Без исә, үз чиратыбызда, Кәрим Җаманаклы хакында яңа материаллар эзләү, биографиясен тәгаенләштерү, аның Мәскәү, Ташкент, Симферополь һәм башка шәһәрләрдә басылган хезмәтләрен, әдәби әсәрләрен эзләү эше белән шөгыльләндек. Шулар нәтиҗәсендә ошбу җыентык барлыкка килде. Китап төзелеше ягыннан түбәндәгечә итеп корылды: беренче бүлектә Кәрим Җаманаклы шагыйрь буларак тәкъдир ителә, ягъни аның шигырьләре урнаштырылган. Икенче бүлек Җаманаклының

гыйльми мәкаләләреннән гыйбарәт. Өченче бүлектә исә истәлекләре урын алды.

Әдәби әсәрләрен, шигырьләрен барлау иң авыр эшләрнең берсе булып чыкты. Шагыйрьнең беренче иҗат тәҗрибә үрнәкләре Кырымда «Яңа дөнья» газетасында һәм «Иләри» («Алга») исемле журналда басыла. 1927 елда Бакчасарайда «Азатлык җырлары» исемле шигырьләр җыентыгы нәшер ителә. Аннан соң 1939 елда «Балаларга Ленин хакында», 1940 елда «Ана җырлары» дип аталган шигырь китаплары дөнья күрә. Дәһшәтле сугыш һәм сөргенлек елларында бу җыентыкларның кемнең кулында булса да сакланып калуы бик икеле, һәрхәлдә, бүгенгә кадәр ул китаплар табылмаган, әмма кульязмаларының күпчелеге шагыйрьнең үз архивында калган. Бу архивта әдәби әсәрләре хакында Җаманаклы үзе тутырган белешмә дә бар. Әлеге белешмәдән күренгәнчә, ул «лирик шигырьләр» дип атаган әсәрләр циклы 1929, 1941 елларда «Совет әдәбияты» журналында, 1930, 1941 елларда «Крымгосиздат» нәшриятында басылып чыккан, сугыш вакытында язылган шигырьләренең фронт газеталарында һәм листовкаларда кулланылуын күрсәтә һәм бер төркеменең 1942 елда «Совет әдәбияты» журналында, 1943 елда «Әй, минем туган халкым» шигыренең «Кызыл Кырым» газетасында чыгуын әйтә. 1956 елда «Ленин. Яз» шигырьләр циклы «Совет әдәбияты» журналында чыга. Шушы мәгълүматтан соң белешмә бетә, ягъни автор аны шул елларда тутырган булырга тиеш.

Безнең кулыбызда Кәрим Җаманаклының 1973 елда Ташкентта Гафур Гулям исемендәге әдәбият һәм сәнгать нәшриятында кырым татар телендә чыккан «Дусларыма» исемле җыентыгының күчермәсе бар. 60 битлек кечкенә күләмле шигырь тупламасын кырым татар әдәбияты клас-

сигы Әшрәф Шәми Задә төзегән. Нигездә, бу китапчыкка Җаманаклының 1927-1944 елларда язган шигырьләре кертелгән. «Сүз башы»нда Әшрәф Шәми Задә «Кәрим Җаманаклы кырым татар әдәбияты тарихында беренче комсомол шагыйрьләрдән санала, – дип белдерә. – 1920 елларда «Яңа дөнья», «Яңа куәт» газеталары, «Билге» һәм «Яңа Чулпан» журналларының сәхифәләре, гомумән, бөтендөнья инкыйлабы хакында, кызыл байрак, Кызыл армия, урак һәм чүкеч, эшче һәм крестьяннарның берлеге хакында агитацион шигырьләр белән тулган иде. Бу әсәрләрнең авторлары күпчелек совет учреждениеләрендә, мәгариф бүлекләрендә һәм матбугатта эшләүчеләр, укытучылар иде. 1923 елның соңнарына таба укучы яшьләр арасыннан һәм беренче чиратта Тогайкой укытучылар техникумы шәкертләре арасыннан да яшь һәвәскәрләр әдәбиятка килә башлады. Болар арасында матбугатта иң актив катнашучылар һәм укучыларның игътибарын җәлеп итүчеләр Зыяэтдин Җаутүбәли һәм Кәрим Җаманаклы булдылар», – ди кереш сүз авторы (3; 3).

«Дусларыма» җыентыгына кергән шигырьләрендә төп идея – совет кешесенең ватанга булган мәхәббәте, киләчәккә зур өмет. Бу идея Җаманаклы әсәрләрендә замана шаукымына иярү кебек кенә кабул ителә алмый, комсомол шагыйрь соңыннан ленинизм, коммунизм идеологиясенә чын күңелдән тугрылыклы булып калган коммунист булып җитешә һәм, мөгаен, гомеренең азагына кадәр бу идеянең дөреслегенә шикләнми яши. «Егетлек гомереннән бер парча» (1927), «Яшьлек» (1925), «Трактор» (1926), «Яшьлеккә» (1927), «Үз кардәшемә» (1927), «Пионерларга» (1927), «Завод төне» («Завод геджеси», 1930), «Хезмәт маршы» («Эмек маршы», 1931), «Комсомолга» (1936), «Чапай хакында җыр» (1954) кебек шигырьләре совет иленең матурлыгын мактауга, бәхетле

киләчәген сурәтләүгә багышланган. Тәүге әсәрләреннән булган «Яшь шагыйрьгә» (1927) шигырендә Җаманаклы яшь каләм ияләренә мөрәҗәгать итеп, хезмәт иясе халкының мәнфәгатьләрен, омтылыш-хыялларын чагылдырып, заман таләбенә туры килерлек әсәрләр язарга үгетли, армый-талмый иҗат итәргә чакыра.

«Габдулла Тукай белән сөйләшү» (1936) шигырендә Кәрим Җаманаклы Казан татар шагыйренең кырымлылар арасында да сөекле һәм үлемсез булуын, аның дәрт-хәсрәт тулы җырларының Туктаргазый кебек кырым татар халык шагыйрьләренә үрнәк булуын әйтергә тели.

Яшь шагыйрь иҗатында совет дәүләтенең дөньякүләм алып барган тынычлык сәясәте темасы аеруча «Көтә» («Беклей», 1928), «Эй, туган халык» (1943), «Сине исә асарлар» (1943) һ.б. әсәрләрендә чагыла. Мәсәлән, «Сине исә асарлар» дигән сюжетлы шигырен алыйк. Рус әкиятендәге патшабикәнең көзге белән сөйләшүе элементына охшаш алым кулланып, Җаманаклы Адольф Гитлерны диварда эленеп торган үз рәсеме белән «сөйләштерә»:

*Адольф Гитлер дивардан*
*Үз рәсемен караган,*
*Маймыл кебек елмайган да,*
*Аннан шуны сораган:*
*– Әйт син миңа, җавап бирче,*
*Болай күпме торырсың,*
*Бар дөньяга хуҗамын, – дип, –*
*Хаким булып торырсың?*

Рәсем башта дәшми, җавап бирми, әкияттәге көзге кебек, ул да ялган сөйли алмый, ләкин хуҗасы кызып ачулана башлагач, ул болай ди:

*Мине алырлар, ертып ягарлар,*
*Аяклар белән басарлар,*

*Сине исә, үзең кебек,*
*Дар агачка асарлар.*

«Әй, туган халык» (1943) шигырендә фашистлар кулы астында калган Кырым халкына мөрәҗәгать итеп болай дип яза:

*Ләкин бүген үз йортыңда*
*Сине туный нимсәләр,*
*Нимсәләргә хезмәт иткән*
*Йөзе кара кемсәләр.*
*Синең өчен бер юл бар тик,*
*Ал Октябрь байрагы.*
*Яңа баштан советлашсын*
*Дилбәр ватан туфрагы.*
*Бу олугъ көн ерак түгел,*
*Коләр бу ана ватан.*
*Аның өчен хәзер, халкым,*
*Җан өчен җан, канга – кан!*

Хатын-кыз темасы «Хатынлыкка» (1924), «Һинд кызына» (1957) «Партизан кызы (Саидә Уссиновага)» (1965) шигырьләрендә күтәрелә. Бу җыентыкка кергән шигырьләре эчтәлек ягыннан Җаманаклының чын патриот совет шагыйре булуын расласалар да, сәнгатьчәлек ягыннан аның артык зур югарылыкка ирешә алмавын күрсәтә. Моны аңлаган Әшрәф Шами Задә дә: «Бу шагыйрьләрнең беренче әсәрләре, башлыча, тарихи революцион даталар: 9 январь (канлы якшәмбе), 23 февраль (Кызыл Армия), 12 март (февраль революциясе), 8 март (хатын-кызлар көне), 18 март (Париж коммунасы) көннәре, 1 май һәм Бөек Октябрь революциясе бәйрәмнәренә һәм башка истәлекле көннәргә багышланган риторик сүзләрдән гыйбарәт, гади тел, әдәби җәһәттән йомшак, шәкел җәһәтеннән аксак әсәрләр иделәр, – ди. – Ләкин бөтен кимчелекләренә кара-

мастан, авылдан чыгып, рус телен көч-хәл белән өйрәнеп, рус революцион әдәбиятын, Александр Блок, Владимир Маяковский һәм Демьян Бедный кебек бөек рус революцион шагыйрьләренең иҗатларыннан да хәбәре булмаган бу яшь буын шагыйрьләр яңа совет кешесен тәрбияләү максатыннан алга сөрелгән замана тематикасына ничек тә ярарга тырыша иделәр ... Үзенең яшьлек елларында язган һәм нәшер иттергән шигырьләре хакында мәрхүм Кәрим Җаманаклы 1943 елда язган бер язмасында: «... Ул вакыттагы шигырьләрнең чи булуына хәзер үзем дә қолам һәм кызарам, дигән иде», – дип искә ала Әшрәф Шами Задә. Шагыйрь Кәрим Җаманаклы иҗаты «Кырымтатар әдәбияты тарихы» уку-укыту программаларына кертелгән һәм 1920-1930 елларда актив язган Гафар Булганаклы (1905-1987), Җәмил Сәйдамәт (1903-1977), Зыяэтдин Җаутүбәле (1905-1992), Җәмил Кәнджи (1896-1945) һ.б.лар иҗаты белән бергәттән уку йортларында өйрәтелә.

Педагог буларак, Кәрим Рәшидовның эшчәнлеге бөтенләй диярлек чыганакларда телгә алынмый, югыйсә, ул – мәктәп дәреслекләре төзү өлкәсендә дә эш күрсәткән шәхес.

Җаманаклының фәнни һәм фәнни-методик хезмәтләренең исемлеге 1929 елдан башлана. Беренче фәнни мәкаләсе 1929 елда «Вопросы просвещения» (Кырым) журналында чыга, ул мәктәп пионер оешмасының эшчәнлеге мәсьәләсен яктырта. 1930-1933 еллар арасында «Крымгосиздат» нәшриятында аның өч дәреслеге чыга: «Учебник для малограмотных» (1930), «Рабочая книга по грамматике и литературе» (1932), «Әдәбият дәреслеге» (1933).

1935-1941 елларда Кәрим Җаманаклы Тел һәм әдәбият гыйльми-тикшерену институтында әдәбият һәм

фольклор секторы мөдире булып эшли һәм югары уку йортында укыта. Бу елларда «Шагыйрь Гомәр Ипчи», «Әдәбият һәм әдәбиятны өйрәнү терминнары», «Әйтешләр һәм бию җырлары», «Хикәятләр» исемле китаплары һәм асрым язучыларның иҗатларына караган күләмле мәкаләләрс басылып чыга.

Кәрим Җаманаклы – фольклорчы галим буларак, кырым татар фәненең бу тармагында нәтиҗәле эшләп, тарихка кереп калырдай шәхес.

Кырым татар фольклор үрнәкләрсн җыю, бастыру һәм өйрәнү эше XIX гасырның II яртысыннан башлана. Бу елларда этнограф В.Х. Кондарский «Кырымның универсаль тасвиры» исемле күптомлы хезмәт бастыра. 1883 елда «Кырым риваятьләре» китабы чыга. Исмәгыйль Гаспралы үзенең «Тәрҗеман» газетасында фольклор үрнәкләрен даими бастырып тора. Гаспралының ярдәме белән М.Акчурин «Нәфис мәзәкләр» («Нәвадир нәфисә», Бакчасарай, 1897) җыентыгын нәшер итә. Кырым татар фольклорын беренчеләрдән булып туплаучы һәм бастырып чыгаручыларның берсе – академик В.В. Радлов. 1896 нчы елда Санкт-Петербургта чыгарган «Шималь торек кабиләләренең халык әдәбияты» сериясендәге күптомлы хезмәтенең VII томы «Кырым ярымутравы диалектлары» китабында дастаннар, экиятләр, табышмаклары һ.б. лар урнаштыра. XX йөз башларында А.Олесницкий, А.Самойлович, В.Филоменко, С.Костюбинский һ.б.лар кырым татар фольклорын җыю эше белән кызыксыналар. 1925 елда Кырымның 55 районына фольклор экспедициясе оештырыла. Аның составында И.Боданинский, О.Акчораклы кебек танылган фольклористлар белән беррәттән яшь Кәрим Рәшидов та була. Ул әлеге корифейлар янында гыйльми эш тәҗрибәсе, авылдан-авылга

йөреп, халык авыз иҗатының бөтен жанрлары буенча бай материал туплый. Кырым ханлыгының мәркәзе булган Бахчасарайның гүзәл табигате, тарихи үткәне яшь мөгаллимне илһамландыра, тел-әдәбият мәсьәләләре белән өзлексез шөгыльләнергә этәрә. Шул вакытларда ул халык иҗатын җыю эшен башлый, фольклор өлкәсендә эзләнүләр башлап җибәрә. Кырымның күп кенә авылларын җәяү йөреп чыга. Халык авыз иҗатын җыю, халык осталары белән якыннан танышу яшь шагыйрьгә зур тәэссорат бирә, бөтен гомеренә җитәрлек эз калдыра. Педагогия институтында укытканда, гыйльми – тикшеренү институтының өлкән фәнни хезмәткәре булып эшләгәндә Кырымның төрле районнарына фольклор экспедицияләре оештыра, әдәбият тарихына кагылышлы материаллар туплый.

Кәрим Җаманаклының «Кыска җырлар һәм такмаклар» («Чин вә манеләр», Симферополь, 1940), «Кырым татар әкиятләре» (Симферополь, 1941) китаплары басыла. Бер төркем мәкаләләре вакытлы матбугатта чыга. Р. Тинҗәров, Ю.Болат белән бергә хәзерләгән «Татар халык әкиятләре» җыентыгы 1959 елда Ташкентта басыла. Кәрим Җаманаклы кырым татар дастаннарын иң беренче булып җыючылардан санала. 1941 елда басылган «Әкиятләр» китабына «Таһир илә Зөһрә», «Гашыйк Карип», «Кобланды батыр», «Кузы көрпәч» дастаннарын да урнаштыра. «Кобланды батыр» дастанының, мәсәлән, барлыгы ике генә варианты билгеле: берсе В. Радлов, икенчесе К.Җаманаклы варианты. Җаманаклы бу әсәрне Кырымның Кызыл Перекоп районының Байказак авылында аксакал Алим Сәлимшадан язып алган. «Кузы көрпәч» дастанын исә Симферополь районының Байкыйат авылы көтүчесе Якуб Арслановтан сөйләткән.

1966 елда Татарстан китап нәшриятында Җаманаклының элегрәк хәзерләгән «Кырым татар халык авыз иҗаты үрнәкләре» («Образцы крымско-татарского устного народного творчества») дигән 25 басма табактан торган җыентыгы басыла (редакторы Эдуард Касыймов). Җыентык икс бүлектән тора. Беренче бүлектә – экиятләр, икенчесендә – туйларда һәм бәйрәмнәрдә җырлана торган лирик икеюллык җырлар (чыннар) һәм такмаклар (манилэр) урнаштырыла. Кәрим Рәшидов кереш мәкалә һәм искәрмәләр яза. Әкиятләрне дә ул тәрҗемә итә, лирик җырлар һәм такмаклар Зәки Нури тәрҗемәсендә бирелә.

«Чын ве манелер джыйынтыгы»н Кәрим Рәшидов сугыш алды елларында тәртип итеп бастыра. Бу җыентыкка кергән материаллар Кырым татар теле һәм әдәбияты гыйльми-тикшеренү институтының әдәбият һәм фольклор секторы хезмәткәрләре тарафыннан тупланган. Чыннар Кырымның Кизләү, Ак-шәйх, Җанкой, Керчь, Кәфә һәм башка районнарында, манеләр исә Ялта, Алушта, Балаклава, Судак һәм башка районнарында җыеп алынган. Җыентыкка меңнән артык чын һәм ике йөздән артык мане (кыска җырлар һәм такмаклар) кертелгән. Кәрим Җаманаклы, шартлы рәвештә, бу әсәрләрне 3 төркемгә бүлеп бирә:

1. Һиҗрәт һәм 1914 елгы империалистик сугыш турында әйтелгән чыннар.
2. Тормыш һәм мәхәббәт чыннары:
   а) гомуми чыннар;
   б) кызлар җыенында әйтелгән чыннар;
   в) егет-кызларның кара-каршы әйтешкән чыннары;
   г) табышмак чыннар.
3. Манеләр.

Кәрим Җаманаклы китапта «Чын вә манеләр» исемле кереш мәкалә дә яза, анда ул бу ике фольклор

жанрының уртак һәм аерымлык якларын аңлата. Октябрь революциясенә кадәрге татар халкының авыр язмышы бу лирик жанрларда бик ачык чагыла. К.Җаманаклы чын һәм манеләрнең эчтәлекләрендәге уртак иҗтимагый темаларны (сугыш, һиҗрәт, тигезсез никах, туган илне сагыну, ачлык, фәкыйрьлек һ.б.) мисаллар белән аңлатып биргәннән соң, аларның поэтикасына конкрет туктала. Бу ике жанр арасындагы аермалар, аның фикеренчә, күтәрелгән сәяси һәм иҗтимагый мәсьәләләрнең тарлыгында яки киңлегендә һәм форма-калыпта, шигырь төзелешендә күренә. Чыннар төгәл бер фикерне җиткерүче лирик мысрагътан яки ике юллык шигырьдән гыйбарәт. Ул бу җәһәттән бәетләргә охшап тора, әмма бәетләр күбрәк язма әдәбият жанрына тарта һәм форма ягыннан цезура белән чыннардан аерыла. Манеләр белән бәетләрдәге иҗекләр саны, чыннардагы кебек, даими түгел. Мисаллар китерик:

Мане үрнәге:

*Кыя төбе саз булыр,*
*Гөл ачылса, яз булыр,*
*Мин сиңа гөл диялмам:*
*Гөлнең гомере аз булыр.*

Чын үрнәге:

*Йолдыз сирәк, күк ачык, болытсыз һава,*
*Чарасызмын, ялгызлыктан йөрәгем яна.*

Кәрим Рәшидов хәзерләгән әлеге җырлар җыентыгы фольклор галимнәре өчен бүген дә әһәмиятен җуймаган. Кырымда ул быел яңадан басмага бирелде.

«Кырым татар әкиятләре» исемле күләмле язмасында ул халык авыз иҗатының бу киң таралган жанрына җентекле күзәтү ясый. Бу хезмәте безнең җыентыкка тулысынча кертелде, шунлыктан монда анализ ясауны кирәк санамадык.

Әдәбият галиме буларак, филология фәннәре кандидаты Кәрим Җаманаклының хезмәтләре шактый күпкырлы дияргә була. Бердән, ул әдәбиятның теоретик мәсьәләләре белән якыннан кызыксына, икенчедән, Кырым татар әдәбиятының аз яки бөтенләй билгеле булмаган шәхесләрен барлый, өченчедән, үз замандаш әдипләренең иҗатына карата тәнкыйть мәкаләләре яза.

«Тугайбәй хакында поэма» исемле мәкаләсендә (*«Кызыл Кырым», 1939, № 94*), мәсәлән, ул текстолог һәм әдәбият тарихчысы буларак чыгыш ясый: моңа кадәр билгесез калган төрки авторның исемен, әсәренең язылу тарихын билгели, идея эчтәлеген ачыклый, поэмада аталган тарихи шәхесләр хакында белешмә бирә. XVII гасырга караган бу әсәр К.Рәшидовка кадәр бөтенләй билгеле булмаганга, ул аны җентекле итеп тикшерә. Янь галим, вакыт-вакыт шул чакта популяр булган сыйнфыйлык идеяләре белән мавыгып китсә дә, әсәрнең халыкчанлыгын, патриотик рухын, кырым татар һәм украин халыкларының гасырлардан килгән дуслык идеясе белән сугарылган булуын басым ясап әйтә.

«Сабир, Тукай һәм Туктаргазый» атлы мәкаләсендә Кәрим Рәшидов азәрбәйҗан, Казан һәм Кырым татарларының иң күренекле шагыйрьләрен бергә алып, аларның иҗатындагы уртак якларны күрсәтүне максат итеп куя. Өч халык шагыйренең дә төп илһамчысы 1905 елгы революция булганга, аларның һәрберсе үз халкы каршында новатор буларак чыгыш ясый. Әлеге язмасында инде Кәрим Җаманаклы һәм сәяси, һәм фәлсәфи җәһәттән өлгергән галим булып күренә, аның фикерләү колачы киң, анализлау осталыгы бай, тугандаш әдәбиятлар буенча белеменең тирән булуы сокландыра. Халыклар дуслыгы идеяләре бик тә популяр чорда язылса да, хезмәтнең танып-белү җәһәтеннән кыйммәте хәзер дә бар.

Кырым татар язучысы Гомәр Ипчи (Алкедай) (1897-1955) турындагы мәкаләсен эшкәрткәндә, әлеге шәхес турында мәгълүмат эзләп, төрле энциклопедияләргә, белешмәлекләргә мөрәҗәгать иттек, әмма андый материалны табу бик авыр булды, чөнки Ипчи дә – Сталин репрессияләре корбаны булган шәхес, «социализм төзү» чорында аны исеме онытылган, бер кая да кертелмәгән. Шуңа күрә Гомәр Ипчи турында үзебез тапкан кыскача материалны монда китерсәк, яхшы булыр дип уйладык.

Гомәр Бәкир улы Ипчи 1897 елда Бакчасарайда туа. Башлангыч мәктәпне шунда тәмамлый. 1914 елда Уфага килеп, «Галия» мәдрәсәсендә укуын дәвам иттерә. 1917 елда Кырымга кайтып берничә ел укытучы булып эшли, шунда әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнә. 1920 елдан соң Кырым Дәүләт театрында актер, режиссер һәм директор вазифаларын башкара. Шул ук вакытта «Яңа дөнья» газетасының мөхәррире дә була. Ул 1937 елда милләтчелектә гаепләнеп, кулга алына һәм 12 елга ирегеннән мәхрүм ителә. 1949 елда җәза срогы бетсә дә, аны азат итмиләр, тормәдән Томск шәһәрендәге рух авырулары хастаханәсенә (психбольницага) ябалар. Шагыйрь, әдип, драматург һәм режиссер Гомәр Ипчи 1955 елның 11 гыйнварында шунда вафат була.

Гомәр Ипчи «Фахишә» (1924), «Галим» (1925), «Нәнкәҗан ханым» (1926), «Шаһин Гәрәй» (1929) пьесаларын язган. 1930 еллар матбугатында аның «Галим», «Ачлык» һәм «Хоҗалар» («Укытучылар») исемле романнар язуы турында мәгълүмат бар, ләкин алар, башка күп кенә әсәрләре кебек, басылмыйча калалар, репрессияләнәләр. Тәрҗемәләре белән бергә 17 китап авторы булган Гомәр Ипчинең кульязмада калган әсәрләре юкка чыгарыла.

Гомәр Ипчи – кырым татар кинематографиясенә нигез салган шәхесләрнең берсе. Ул «Галим» исемле

(халык каһарманы Галим Азамат угълы хакында) беренче кырым татар кинофильмының режиссеры да.

1972 елда Ташкентта аның хикәяләр җыентыгы чыгуы билгеле. Гомәр Ипчинең тормыш юлын һәм иҗатын Исмаил Кәримов исемле галим өйрәнгән һәм «Тирәнлек» (1988) дигән әдәби әсәр язган. Шул ук вакытта ул 1989 елда Үзбәкстан Фәннәр Академиясендә «Гомәр Ипчинең тормышы һәм эшчәнлеге» темасына кандидатлык диссертациясе дә яклаган.

Гомәр Ипчи иҗатын үзе исән вакытта ук шактый югары бәяләгән Кәрим Җаманаклының ошбу җыентыкка кертелгән мәкаләсе фаҗигале язмышка дучар булган тагын бер кырым татар мәдәнияте әһеленең истәлеген яңарту булып саналсын.

1936 елда Кәрим Җаманаклы бер төркем яшь кырым татар язучылары белән бергә Ялтада сихәтләнүче татар әдәбият классигы һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов белән күрешә. Бу турыда ул 1966 елда Казанда нәшер ителгән «Галимҗан Ибраһимов хакында истәлекләр» китабында язып чыга. Алабугада яшәү дәверендә, татар әдәбияты белән якыннан танышып, Җаманаклы «Муса Җәлил – Ленин премиясе лауреаты» дигән китап чыгара. Бу язма да гадәти бер монографик хезмәт түгел: ул 1958 елда, Муса Җәлил исеме тирәсендә бәхәсләр тынып, аның чын дәрәҗәсендәге патриот-шагыйрь булуы расланган чорда, беренчеләрдән булып язылган әсәр. Аның язылуына Алабуга институтында татар филологиясе кафедрасы мөдире булып эшләгән Маһинур апа Фәйзуллинаның да тәэсире булуы бик мөмкин, чөнки филология фәннәре кандидаты М.Фәйзуллина сугышка кадәр үк Муса Җәлил белән шәхсән таныш булып, хатлар алышкан кеше була һәм

әлбәттә, бу хакта горурланып хезмәттәше һәм дусты Кәрим Җаманаклыга еш сөйләгән.

Алабуга шәһәренең яңа урамнарыннан берсенә Кәрим Рәшидов (Җаманаклы) исеме бирелде. Шәһәр хакимиятенең бу изге карары белән кырым татар язучысы һәм галименең исеме мәңгеләштерелде. Язмыш җиле 1945 елда Кәрим Җаманаклыны (1905-1965) Алабугага китереп ташлый. Башта ул бу шәһәрне сөргенлек җире сыйфатында кабул итә, яратмый, моннан китү чарасын эзли, әмма соңрак бөтен күңеле белән сөя һәм гомеренең азагына кадәр монда кала ...

*Искәрмәләр*


1. Асаноглу Исмаил. Гаспринскийның «җанлы» тарихы (1883-1914). – Акмәчет, «Тарпан». – 1999.
2. Бекирова Г. Крымскотатарская проблема в СССР (1944-1991). – Симферополь: Оджакъ, 2004. – 332 с.
3. Джаманакълы Керим. Достларыма. Шиирлер. – Ташкент. Гъафур Гъулам адына эдебият ве санъат нешрияты. – 1973. – 61 б.
4. Джаманаклы Керим. Къырымтатар масаллары // Йылдыз. – 2004. – № 3. – 13-41 б.
5. Куртиев Рефат. Календарные обряды крымских татар. – Симферополь. Крымучпедгиз. – 1996. – 64 с.
6. Решидова-Быкова Фарида. Керим Джаманаклы // Аргамак. – С. 56-59.
7. Эмирсуинова (Решидова) Н.К. Къырымтатар масалларынынъ биринджи тедкъикъатчысы // Йылдыз. – 2004. – № 3. – 42 б.
8. Чын ве манелер джыйынтыгы. Тертип эткен К.Джаманклы. – Кырым АССР девлет нешрияты. 1940. – 158 б.

9. Риза Фазыл. Шаир вә оджа // Ирмакълар. – Симферополь, 2002. – 301-305 б.
10. К.Рәшидов турында кара: Новая Кама. – 1993. – 28 сентябрь. С. 2-3; Новая Кама. – 1998. – 21 октябрь. С. 3-4; Алабуга нуры. – 1998. – 15 октябрь. Б. 3.
11. Риза Фазыл, Сефтер Нагаев. Къырымтатар едебиятынынъ тарихы. – Акъмесжит, 2001. – 640 с.
12. Деятели крымскотатарской культуры (1921-1944). Биобиблиографический словарь. – Симферополь: Доля, 1999. – 240 с.

# ШИҒЫРЬЛӘР

## АЛАБУГА-ҖАМАНАК

*Исемә төште, Алабуга,*
*Җаманагым кызлары.*
*Төшә иде алар суга*
*Кырымым йолдызлары.*

*Җырларыннан куандылар*
*Таулар, күкләр, диңгезләр ...*
*Кайтавазлар яңгыравы*
*Әле дә аларны эзләр.*

*Синең дә сылу кызларың*
*Җырлый чишмә буенда.*
*Онтыла йөрәк сызлавы*
*Булса алар уемда.*

*Алабуга, Алабуга,*
*Әйткән сүзем булсын хак:*
*Җаманакта синсең уйда,*
*Сиңа кайтсам – Җаманак ...*

## ТЕЛИМ, ӘЛБӘТТӘ!

*Һәр эштә остен, һәр эштә җәсүр*,*
*Һәркемнән көчле, һәркемнән үткер*
*Булырга бүген телим, әлбәттә.*

*Төнге юллардан, тау-чытырманнан,*
*Очлы кыядан, ташлы кырлардан*
*Дию дәй утәргә телим, әлбәттә.*

*Кояшның нурын, дөньяның йөзен,*
*Бәллүрдәй парлак йолдызлар эзен*
*Күреп белергә телим, әлбәттә.*

*Туфракның серен, көйләнең** җырын,*
*Таплы эш көнен, техника серен*
*Табып белергә телим, әлбәттә.*

*Кайгылы көнем, нәфрәтле җырым,*
*Кальбемә сеңеп сакланган җырым,*
*Сөйләргә бүген телим, әлбәттә.*

*Ялгызлык чиккән, кузьяшьләр түккән*
*Залимга мескен башкаен игән*
*Ятимгә бер дус телим, әлбәттә.*

---

** җәсүр – кыю, илсөяр, тәвәккәл*
*** көйле – крестьянин*

*Сүзеннән кайтмас, дусларын сатмас,*
*Дөреслек җебен һич тә югалтмас,*
*Ир-егетлекне телим, әлбәттә.*

*Һәм дә шул чакта корычтай сафта,*
*Дуска ярдәмгә, өйдән еракка*
*Яуга китәргә телим, әлбәттә.*

*Барысын белеп, куанып-көлеп,*
*Ленинчыл яшьләр сафына кереп,*
*Барырга алга телим, әлбәттә.*

*Дөньяда мондый, һәр эштә җәсур,*
*Һәркемнән көчле, һәркемнән үткер,*
*Кыю булырга телим, әлбәттә.*

## ДУСЛАРЫМА

*Йөрәгемдә утлар кайный,*
*Әй, дусларым, күрсәгезче!*
*Белсәгезче минем серем,*
*Күңел яккан ачы җырым.*

*Һәммәсе дә ачык чүлдә,*
*Тар, хәрабә, кыйшык өйдә,*
*Бәгыремнән өзелгәндер,*
*Шигырь булып тезелгәндер.*

*Сабан арты йөргәндәме,*
*Болында таң күргәндәме.*
*Мине, дуслар, уйлагыз сез,*
*Җырларымны җырлагыз сез.*

*Әле мине аңларсыз сез,*
*Язмышымны барларсыз сез,*
*Минем ачык күңелемне,*
*Минем сабый күңелемне*
*Сагынырсыз, арарсыз* сез.*

---

* *арарсыз – юксынырсыз, эзләрсез*

## ЕГЕТЛЕК ДАНЫ

*Кара болытлар кайгы апкилсә,*
*Өметне сүндергән яулар бирсә.*
*Котырган дошман эт булып өрсә,*
*Бик тиз туктатыр егетлек даны.*

*Яшеннән дәррәу гөрселдәү купса,*
*Канлы яу туптан укларын атса.*
*Йөрәккә ялкындай кайгылар капса,*
*Ил дип ут кичәр егетлек даны.*

*Тау-кыя авып дәрьялар ташса,*
*Чатырның томанлы түбәсе шашса,*
*Тормышның бураны дәһшәтен сачса*,*
*Яуга яу булыр егетлек даны.*

*Җирне тетрәтеп, гарасат купса,*
*Ирне ир, илне ил еландай йотса.*
*Кешелек бәхетен каруннар тотса,*
*Якты рух уятыр егетлек даны.*

*1928*

---

**сачса – чәчсә, туздырса*

## НИНДИ ТЫН

*Айлы бер төн. Тау итәге.*
*Һәммә нәрсә йокыда.*
*Таулар, кырлар ял итәләр.*
*Айлы төн кочагында.*

*Диңгез дә тын, һич шауламый.*
*Тирән сулый, тирбәлә ...*
*Төрле үлән, яфраклардан*
*Хуш ис оча тирәгә ...*

*Һич тузан юк, чыклар төшә,*
*Дымлы һава, исми җил ...*
*Нинди гүзәл тыныч кичә,*
*Ял ит бераз, монда кил!..*

## БОЛГАРЛАР

*Кара диңгез, Азау буйларыннан*
*Килгән бире тәүер-болгарлар,*
*Аю тауларына охшаш Ослан*
*Тауларына сокланып бик озак торганнар.*

*Әйдә, булсын Ана-илдә Аю,*
*Монда булсын Ослан-Арыслан!*
*Бу таманны итик торак җае,*
*Әй, болгарлар, килеп алыстан!*

*Голчәчәктәй итик Идел буен*
*Калган Илдәй булсын ул гүзәл.*
*Әле бик күп еллар вә гасырлар*
*Сагыну-сагыш үзәкне өзәр!*

*Алкын дип тә, салкын дип тә, әле*
*Җырларбыз без, Идел сулары ...*
*Күңелләргә генә түгел, җанга*
*Сихәт итәр диңгез буйлары ...*

*Уйлар басар әле күңелләрне,*
*Мул булса да тормыш, өебез ...*
*Ерак илне сагынып, диңгезләрне*
*Күп тапкырлар китәр көебез.*

*Урманнарга кереп моңланырбыз,*
*Төшебезгә керер тау, диңгез,*
*Тик җибәрмәс безне еллар түгел*
*Тормыш түгел, корылган нигез! ...*

*Сагынучылар әле сагынырлар,*
*Җырлаучылар әле җырларлар.*
*Ерактагы даулы диңгез сыман*
*Дулкынланыр яшел урманнар.*

*Канда гына яшәр утлы ялкын*
*Мәйданнарда гына болгарлар* ...*

---

* *болгар – җиңелү белмәс батыр (кырым татарча)*

## ХӨРМӘТЕМ ЗУР КАЗАНГА

*Борынгыдан фән-мәгърифәт йорты булган карт Казан,*
*Укырга дип Володя да монда килгән бер заман.*

*Яшь каһарман атлап йөргән бусагадан кердем мин,*
*Бу белем йорты эчендә күпме нурлар күрдем мин!*

*Кысан гына тар бүлмәгә күпме истәлек сыйган ...*
*Биредә мин юлбашчының кайнар сулышын тоям.*

*Ераклары якын итеп килгән монда яшь Ильич,*
*Дусларына көрәш рухы биргән монда яшь Ильич.*

*Зур ялкынның башлангычы булган, димен, Казанда –*
*Шуңа күрә, хөрмәтем зур чал Казанга һаман да.*

## «ТУКАЙ» ПОЭМАСЫННАН

*Ерак түгел киң Иделле Казан өчен*
*безнең җирләр,*
*Тукай җырын чын күңелдән яратып*
*кызлар, ирләр.*
*Тукай үзе килмәсә дә, килгән аның*
*җыры очып,*
*Йөргән халкым арасында бетмәс матур*
*хисләр чәчеп.*
*Тәмле хисне, музыканы кайсы йөрәк*
*яратмаган?!*
*Моңлы җырлар үз моңнарын кай җирләргә*
*таратмаган?!*
*Телдән телгә күчеп йөргән «Шүрәлеләр»,*
*«Кисекбаш» лар,*
*Азмы йөрәк яндырмаган мактанылган*
*кыйгач кашлар!*
*Яшь былбыллар сазын чиртеп җырлаганнар*
*шигырьләрдә,*
*Шигырь булган Казан арты Кырлайдагы*
*киң кырлар да.*
*Аны укып рух күтәргән, хәят сөйгән*
*күп йөрәкләр,*
*Тукай аша балаларга сердәш булган*
*күбәләкләр.*
*Туган халкы, хөр Россия булган*
*Тукай илһамчысы,*

*Шатландырган үскән үлән,*
*яңгырларның нур тамчысы.*
*Бөек Пушкин шигырьләре рухландырган*
*Габдулланы.*
*Иткән алар олы шагыйрь*
*ятим калган бер баланы.*
*Үрмәләгән алга табан,*
*мәдех язган Ямашларга,*
*Юл күрсәткән халкы өчен*
*көрәшүче чын яшьләргә.*
*Үрнәк булган халкын сөйгән данлы*
*шагыйрь Хөсәенгә*,*
*Алар бергә шигырь укып йөргәннәр*
*өйдән-өйгә ...*
*Кайсы өйгә керсәң, бүген түрдә*
*колеп тора Тукай,*
*Илне сөйгән халкым белән мәңге*
*бергә бара Тукай.*
*Халкым аны онытмас һичбер вакыт,*
*һичбер заман,*
*Рухландырып халыкларны ул барачак*
*алга табан.*

---

** Хөсәен Шамиль Туктаргазый - Тукайның замандашы, якын дусты. Кырым татар халык шагыйре. Демократик-революцион шигырьләре өчен 1913 елда байлар һәм муллалар тарафыннан фаҗигале рәвештә үтерелгән.*

## КАРА ДИҢГЕЗ КЫРЫЕНДА

**Кырымда, Алупкада, үзенең туган шәһәрен дә ике тапкыр Советлар Союзы Герое Әхмәтхан Солтанга куелган һәйкәлгә карап.**

*Батырлыкның юк кабере,*
*Үлмәс булып килә дөньяга.*
*Нәселебез исеменнән*
*Җырлар язам бүген мин аңа.*

*Кара диңгез дулкынына*
*Кара күзләр горур текәлгән.*
*Зур таулар башы аңа*
*Хөрмәт иткән кебек иелгән.*

*Узганнарны искә алган кебек,*
*Уйга чумган Әхмәтхан.*
*Могҗизалы бу җирләрдә*
*Хикәятләр әйткән бер чабан.*

*Татар улы Надыр карт*
*Лачын җырын монда җырлаган.*
*Бу җырларны олы Горький*
*Өзелә-өзелә тыңлаган.*

*Мондый җирдә туып үскән*
*Минем көчле, батыр Солтаным.*
*Покрышкиннар нәселдәше*
*Лачыннарны биргән Ватаным.*

*Горурланам, таулар кебек*
*Баш иямен, туган, мин аңа.*
*Батырлыкның юк кабере*
*Үлмәс булып килгән дөньяга.*

## КИПАРИС ТУРЫНДА БАЛЛАДА

*Аю-Дагдан ерак түгел*
*Ялгыз гына бер кипарис.*
*Томан кебек сарган аны*
*Кайгы-хәсрәт, тирән бер хис.*

*Диңгездә дә шундый бер хәл,*
*Хәсрәтләнә, яман үкерә.*
*Җирнең кара битенә ул*
*Ачуланып һаман төкерә.*

*Нигә ялгыз калдырдыгыз,*
*Дигән сыман дулкыннар.*
*Дулкыннарның тавышында*
*Моңсулану, юксыну бар.*

*Бу кипарис гади түгел –*
*Олы Пушкин дусты аның.*
*Айлы төндә, күләгәсендә*
*Тыңлаган ул диңгез валын.*

*«Тантаналы матурлык» дип*
*Мактанылган дулкыннар.*
*Йөрәгендә мәңге калган*
*Монда туган ялкыннар.*

*Йөргән биредә Мицкевич,*
*Польшасына монда сагынган*
*Нечкә, кайнар күңелендә*
*Шигъри утлар кабынган.*

*Ләкин дуслар, бүген монда,*
*Могҗизалы, гүзәл Кырымда*
*Немец фашистлары йөри*
*Канлы балта алар кулында.*

*Куркынычлы дошман кебек*
*Кипарисым минем аларга.*
*Җирәнәләр бу ерткычлар*
*Гүзәллеккә текәлеп карарга.*

*Муса башын кискән балта*
*Кипариска һаман селтәнә.*
*Селтәнсә дә кисә алмыйлар,*
*Ул үсә, һаман иркен генә.*

*Саклый аны халыклар рухы*
*Истәлеге итеп шагыйрьнең.*
*Хөрмәтем күп минем аңа*
*Матурлыгы, изге Кырымның.*

*Һич җиңелмәс, мәңге үлмәс*
*Шигърият, акыл дөньясы,*
*Чөнки Пушкин булды күптән*
*Шагыйрьләрнең шигъри кыйбласы.*

## КЕМ УЙЛАГАН

*Кем уйлаган ярты авыл малаеның*
*батыр булып китәсен,*
*Кирәккәндә дошманнарның*
*башларына җитәсен.*

*Дөресен әйтсәм, мин авылның*
*иң юашы булып үскәнмен,*
*Шулай да эт баласы көерыгына*
*чабып кискәнмен.*

*Нишләтәсең, малай чакта була торган*
*мондый эшләрең,*
*Алар өчен шамар тисә сызлагандыр*
*азмы төшләрең.*

*Кабат әйтәм, гаепсезгә*
*кыйнамадым нәни песине,*
*Рәнҗетмәдем юк-бар белән*
*газиз, сөйгән әнине.*

*«Юаш малай» кушаматын*
*башта миңа болай тактылар,*
*Ә, соңыннан белсәгез сез,*
*кушаматлар җанны яктылар.*

*Бер заманны юаш түгел*
*«куркак куян», диеп йөрделәр,*
*«Чебен-күбәләктән курыккан*
*егет», диеп тә көлделәр.*

*Ләкин белмәделәр бу малайның*
*нинди булып китәсен,*
*Кирәккәндә ил дошманы башларына*
*аның җитәсен.*

*Узды көннәр, айлар егерменче еллар*
*килеп җиттеләр,*
*Авылыбызда большевиклар комсомолец*
*мине иттеләр.*

*Авыр еллар иде. Ленин даһиебызны*
*куйдык кабергә,*
*Җанлы Ильич белән саубуллаштык,*
*дуслар, гомергә.*

*Авыр елда ант иттек:*
*бердәм-батыр булырга,*
*Олы Ленин тәгълиматы сафлыгы*
*өчен нык торырга.*

*Юашлыкның, куркаклыкның эзе-чиге*
*миндә калмады,*
*Гадел сугышларда йөрдем, кул-аягым,*
*билем талмады.*

*Перекопта, Севостополь юлларында*
*дошман турадым,*
*Фашистларның канлы күзләренә текәлә,*
*төкерә карадым.*

*Куып киттек килгән якларына*
*вәхшиләрнең хәрам сөресен,*
*Таптап йөрдек үләләрен,*
*буып куйдык тересен.*

*Кем уйлаган ярты авыл малаеның*
*батыр булып китәсен,*
*Кирәккәндә дошманнарның*
*башларына җитәсен.*

## БАЛЛАДА О КИПАРИСЕ

*Близ Аю-Дага под скалою*
*Стоит угрюмый кипарис*
*Туман печальной пеленою*
*Над кроною его повис.*
*Высокий в траурном уборе,*
*Он молча слушает прилив.*
*Разгневанно плюется море*
*В лицо истерзанной земли.*
*Рыдают волны: «Кто оставил*
*Его наедине средь скал?*
*Зачем, зачем на теле старом*
*Морщинами лежит тоска?*
*Кто тот безумец, что оставил*
*На нем следы позорной стали?»*
*Здесь Пушкин лунными ночами*
*Стихом встречал могучий вал,*
*О Польше, родине печальной,*
*Адам Мицкевич тосковал ...*
*Под небом Таврии прекрасной*
*Сегодня здесь фашист в Крыму,*
*И дерево врагом опасным*
*Со страху кажется ему.*
*Заносит он топор, который*
*Мусы Джалиля кровь впитал,*
*Но кипарис стоит упорный,*
*Несокрушимый, как металл.*
*Любовь и ненависть народа –*
*Источник стойкости безмерной.*

## МОРЕ

*Седые волосы раскинув,*
*Напевной силою полна,*
*Подобно древнему акыну,*
*Поет торжественно волна.*
*И я любуюсь, как упруго,*
*Вскипая пеной шумных вод,*
*Несутся волны друг за другом*
*Безостановочно вперед.*
*Так ясным днем и ночью мглистой*
*Всегда, – с зари и до зари –*
*Идут шеренгами на приступ*
*Могучих волн богатыри.*
*И эта мощь воды и ветра,*
*Стремленье вечное вперед*
*Напоминают мне бессмертный*
*Мой героический народ.*
*Проходят месяцы и годы,*
*Но нет, не старится волна.*
*Лишь в час жестокой непогоды*
*Пробьется пены седина.*
*Но схлынет буря, стихнет ветер –*
*И вновь светла пучина вод.*
*Вот так же молод, так же весел*
*Мой нестареющий народ.*

*1927 г.*

## ПЕРВОЕ РАДИО В АУЛЕ

*Не веря – щупают руками*
*Продолговатый странный ящик.*
*Серебряными бородами*
*К нему склоняются все чаще.*

*Не спрятался ли там певец?*
*Шайтан ли их теперь попутал?*
*Но пионеры под конец*
*Им разъясняют это «чудо».*

аның дөре булмаска
мөмкин!

## СТОЙ, ПАРОВОЗ!

*Летят вагоны. Паровоз*
*Умчал их в яркий Май.*
*Один утес, другой утес,*
*Как будто невзначай.*

*В вагоне паренек сидит,*
*В рубахе – смугл – простой.*
*Его пленил природы вид,*
*И крикнул он: – Постой!*

*Стой, паровоз! Как я хочу*
*С утесом стать «на ты»!*
*Остановил свое чу-чу*
*Поэт – дитя мечты.*

# ФӘННИ ЯЗМАЛАР

## КЫРЫМ ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕ

Кырым татар әкиятләре – каһарманлык хакындагы эпос характерын йөртүче эпик әсәрләр. Әкиятләрдә гади халыкның башыннан кичкән авыр тормышы, бәхет һәм азатлык турындагы хыяллары чагыла.

Бу әкиятләр безгә барыннан да элек халыкның каһарманлык сыйфатын һәм аның гаҗәеп әдәби осталыгын күрсәтә. Шулай ук алар – бай фантазиягә ия булган әсәрләр дә.

Әкиятләрдәге фантазия халыкның яшәеше, табигый теләкләре һәм хыяллары белән бәйле.

Гаҗәеп багъ-бакчалар, бәрәкәтле туфраклар, күккә ашкан зиннәтле сарайлар, һәр нәрсәне гөл иткән, «азат» кешеләрнең, батырларның фидакарь эшләре, бөтен гаҗәеп матурлыкларның җыелмасы – халыкның табигый һәм иң самими омтылышлары ул.

Шуның өчен әкиятләр – гади халыкның көнкүрешендә һәм аның культурасы тарихында аерым бер әһәмияткә ия булган әсәрләр.

Иң элек әкиятләр кешенең тормышын җиңеләйтүгә, аның фантазиясен үстерүгә хезмәт иткән бер чара да. Шулай итеп, әкиятләрнең вазифасы халыкның үз көчен, үз акылын, үз иреген һәм кыюлыгын, ватанга булган мәхәббәтен тәрбияләүдән гыйбарәт.

Үзләрендә шундый мөһим вазифа йөрткән өчен алар халык тарафыннан яратып тыңлана һәм иҗат ителәләр. Мәсәлләрнең хосусиятләре Ф.Энгельсның немец халкының «Халык китаплары» хакында язган фикерләре белән бәйләп әйткәндә, тагын да ачыграк аңлашыла.

Энгельс язма әдәбиятның, халык иҗаты әсәрләре арасында йөргән халык китапларының вазифаларын һәм максатларын ачыклап болай ди: «Халык китабының вазифасы – үзенең көндәлек авыр эшеннән арып кайткан авыл кешесенең күңелен күтәрү, аңа күңеллелек бирү, аны җанландыру, аның авыр хезмәтен оныттыру, ком-ташлы җирен хуш исле бакчага әйләндерү; аның вазифасы – һөнәрченең алачыгын һәм интеккән эшченең тузган кечкенә өен поэзия дөньясына алып кереп, алтын сарайга әверелдерү, сөйгәнен гаҗәп матур патша кызы рәвешендә тасвир итү. Ләкин шул ук вакытта халык китабының вазифасы – халыкны үз көчен, үз акылын, үз ирекен аңларга мәҗбүр итү, аның горурлыгын, ватанга булган мәхәббәтен уяту да», – диде.

Ф.Энгельсның халык китаплары хакында әйткән бу фикерләре турыдан-туры гомумхалык иҗатына да карый.

Бу әсәрләрдә, югарыда ассызыкланганча, халыкның бәхет һәм ирек хакында булган өметләре, горурлык көче һәм патриотизмы бар тирәнлеге белән күренә.

Шундый кыйммәтле һәм бай эчтәлеккә ия булган кырым татар әкиятләре төзелешләре ягыннан гади һәм сюжет ягыннан да кызыклы. Алар һәрвакыт гади кешеләрнең көрәшен һәм аның батырлыгын күрсәтүче фактларны үзләрендә саклыйлар.

Әкият геройлары – хезмәт иясе вәкилләре, һәр төрле авырлыкларга түзә алучы, төрле кыенлыклардан оста чыгучы, зирәк акыллы, сабыр, һәр адымын уйлап атлаучы кешеләр. Бу геройларга каршы куелган җиде башлы дию́ләр, аждаһалар,

падишаһлар, солтаннар һәм аларның вәзирләре исә мескен, куркак, чарасыз калган типлар буларак хикәя ителәләр.

Әкиятләрдә эксплуататор сыйныфка каршы көчле нәфрәт бар. Падишаһлар, солтан һәм ханнардан, кешеләр генә түгел, хәтта хайваннар-еланнар да җирәнәләр.

Мәсәлән, «Хан һәм елан» әкиятендә ханның ялганчы булуы, түбәнлеге бар тулылыгы белән күрсәтелә.

«Бервакытны бер елан ханның ялганчымы-юкмы икәнлеген тикшереп карарга уйлаган, чөнки ул ханнарның үзләреннән башка беркемне сөймәгәнлеген белә икән ...

Елан ханның кызын алырга теләгән.

Хан:

– Мин кызымны үземнән артык сөям, – дигән.

– Яхшы, – дигән елан, – әгәр шулай булса, кичкә кадәр син үзеңне һәм патшалыгыңны хәрабәләр эчендә күрерсең. – дигән.

Ханның коты очкан, ул:

– Ал, кызымны гына түгел, җанымны да ал, бары патшалыгыма, байлыгыма тимә. Ялварам сиңа! – дигән.

Җирәнүнең ни икәнлеген белмәгән еланда шунда ук җирәнү тойгысы туган һәм аңа:

– Синең йөрәгең елан йөрәгеннән дә битәр икән. Әгәр дә кыз минеке булса, тимер сөңге алып, аны утта кыздырыр һәм тәнемә басар, бер түгел, бар җиремдә авырту тояр идем, бар мал-мөлкәтемнән аерылыр, ләкин кызымны сиңа бирмәс идем, – дигән. – Хан, синең йөрәгең ялганчы икән, йөрәгеңдә дөреслеккә урын юк икән! Минемчә, моннан соң кешеләр елан турында түгел, хан турында ямьсез итеп сөйләсеннәр, елан йөрәгенә түгел, хан йөрәгенә карасыннар, мин сиңа карарга да җирәнәм, хан, – дигән.

Елан моны әйткән дә, җир өстеннән шуышып, ханның зәһәр йөрәгеннән җирәнеп, оясына качкан».

Ханны еланга каршы куеп сурәтләү халыкның изүчеләргә карата булган нәфрәтен тагын да көчлерәк һәм җанлырак итеп күрсәтә. Шуңа күрә дә экиятләрдә мондый хәлләргә урын күп бирелә.

Моннан башка тагын экиятләрдә падишаһлар, солтан һәм ханнар уңмаган, булдыксыз итеп тасвирланалар. Ягъни алар үзләре мөстәкыйль рәвештә бер генә эшне дә башкарып чыга алмыйлар, иң кечкенә генә мәсьәләне дә үз вәзирләреннән киңәш-акыл сорап кына чишә алалар. Шуңа күрә экиятләрдә эксплуататорларга карата зур сәяси сатира һәм тирән тәнкыйть бар (...) Халыкның шагыйрьлеге, акылы һәм сизү-сизенү сәләтенең киңлеге монда ачык күренә. Халык иҗатына тирән акыл һәм алдан күрүчәнлек хас.

Моны безнең «Курыкмас Кучук (Кече) угълан» экиятендә, русларның «Норка-зверь» һәм грузиннарның «Пашкундж» исемле экиятендә бик ачык күрергә мөмкин. Бу өч экияттә фабула һәм сюжет охшашлыгы бар. Һәрберсендә җиңеп чыгучы кече угыл турында сүз бара.

«Норка-Зверь» исемле рус экиятенең һәм «Пашкундж» исемле грузин экиятенең кыскача сюжеты шуннан гыйбарәт: бер патшаның өч улы була. Патшаның бакчасында бервакыт каяндыр угъры пәйда була. Патша өч улын чиратлап бакчаны каравылларга куя. Каракны өлкән улларының берсе дә тота алмый, бары тик кече угълан гына аны күреп, ук белән ата һәм яралый. Бу карак дию булып чыга. Угъланнар өчесе дә диюнең канлы эзе буенча китәләр, диюнең эзе бер коега килеп җиткәч бетә. Кече угълан, абыйларыннан аермалы буларак, коега төшәргә курыкмый, аны бау белән коеның төбенә төшерәләр. Кое төбендә Кече угълан дөньяның өч гүзәлен күрә. Бу кызлар дию урлап китергән кызлар була. Кече угълан, диюне үтергәннән соң, кое төбендә кызлар барлыгын абыйларына хәбәр итә. Агалары бу кызларны

бау белән тартып өскә чыгаралар, Кече угъланны исә кое төбендә калдыралар. Кече угълан кое төбендә икенче бер дию белән көрәшә. Ул халыкны сусыз тотучы дию була. Угълан аны җиңеп, халыкны сусызлыктан коткара. Җир асты шәһәренең патшасы аңа бу эше өчен, син безне сусызлыктан коткардың, ни телисең, егет, шуны сора, ди. Кече угълан патшадан үзен җир өстенә чыгарырга куша. Патша аны Пашкунджь куышына җибәрә һәм бу эшне бары тик әлеге куышның гына башкара алачагын әйтә.

Егет куышның эченә керә һәм анда ике бичара баланы күрә. Бу балаларның берсе бүген үзенең аждаһа тарафыннан ашалачагын әйтә. Икенче бала Гвеншап исә үзенең аждаһага икенче көнгә ризык буласын белә.

Бу вакытта аждаһа куыштагы балаларны ашарга килә, Кече угълан аждаһаны үтерә, балаларны үлемнән коткара. Ул арада куыш иясе дә килә, аждаһаны күрә, сөенеченнән Кече угъланны аркасына утыртып җир өстенә чыгарырга сүз бирә. Куыш иясе Кече угъланга үзе белән кырык мичкә шәраб, кырык мичкә чи ит алырга куша. Шулай итеп юлга чыгалар. Юлда аларның итләре бетә, Куышның хәле китә. Моны күргән Кече угълан үзенең аягыннан ит кисеп алып аңа каптыра һәм алар якты дөньяга чыгалар. Кече угълан, кызларның иң матурын үзенә алырга теләгән агасын үтереп, күзе төшкән кызны үзенә хатынлыкка ала.

Шул ук сюжетны без «Курыкмас Кече угълан» экиятендә дә күрәбез. Кыскасы, безнең экиятләрдәге кебек, рус халкы һәм Кавказ халыкларының экиятләрендә дә җиңүче көч, каһарманлык гаиләнең төпчек улына хас итеп сурәтләнә. Экиятләрдә олыларның башлаган эшләрен даими рәвештә иң яшьләр тарафыннан дәвам иттерелүе күрсәтелә.

Эпос геройларының батырлыгы нәселдән-нәселгә күчеп дәвам итә. Күпчелек дошманның һөҗүмнәрен кат-

гый рәвештә кире кайтару һәм җиңу каһарманнарның кечс нәселенә – улларына йөкләнә.

Моның иң җанлы мисалы – дөнья күләмендә әһәмияткә ия булган «Сасунлы-Давид» исемле әрмән халык эпосы һәм кыргызларның «Манас» атлы гениаль әсәре. Бсзнең Кырым татар халкының иң борынгы эпосларыннан берсе булган «Идегәй» эпосында да моны ачык күрергә була. Идегәйнең Туктамыш хан һәм аның улы белән булган көрәшне Идсгәйнең улы Нурадын дәвам иттерә һәм җиңүче булып Нурадын кала.

Шуңа күрә әкиятләрдәге өч туганга һәм аларның иң кечесенә, аның даими диярлек җиңеп чыгучы булып калуына һәм аның акыллы эшләренә бары тик әкиятнең төзелешендә очрый торган гади бер күренеш итеп кенә карау дөрес түгел.

Бу көнгә кадәр әкиятләр турында чыккан һәм чыга килүче күп кенә мәкаләләрдә, аеруча гыйльми хезмәтләрдә, әкиятләрдәге өч угъланның, кагыйдә буларак, кечесенең җиңүче булып калуы хакында әйтелсә дә, моның сәбәбе һәм гыйльми нигезе әле һаман тулы һәм дөрес итеп бирелмәгән.

Хезмәтләре дөньякүләм әһәмияткә ия булган академик Веселовский бу мәсьәләне әкиятнең корылышында яткан гади бер симметрия рәвешендә аңлата. Ул: «Бер геройның өч тапкыр китеп-килүе кебек, өч геройның берсенең калган икесе эшли алмаган эшне башкаруы моның бары тик симметрия таләбе булганлыгын аңлатуы җайлы. Әкияттән чыккан нәтиҗә азакта биреләчәк: бу да геройларның берсе бөтен авырлыкларны җиңә, башкалары исә берни эшләмичә, аның казанышын үзләштермәкче булалар һәм аны дошман күрә башлыйлар», – ди.

Веселовский фикеренчә, өч каһарманның эшләгән эше бер каһарманның өч тапкыр китеп-килүенең нәкъ үзе

икән. Моннан килеп, Веселовский әлеге хәлгә экиятләрнең төзелешендәге симметрия дип исем бирә һәм гел шул фикердә кала.

Бу әйбәт, әмма, әйткәнебезчә, соңына кадәр дөрес һәм гыйльми караш түгел. Безнең фикеребезчә, экиятләрдәге бу момент, бары тик бер композиция формасы гына түгел, ә бәлки аларның иң төп прогрессив моментларыннан берседер.

Монда, беренчедән, халыкның үз киләчәгенә һәм ничек кенә булса да, җиңәчәгенә булган ышанычы һәм өмете бөтен тирәнлеген саклый. Икенчедән исә, яшьлекнең, халыкның аңында чиста булып һәм киләчәкнең яхшылыкларын үзенә алачак ышанычлы бер буын булып яшәгәнлеген күрсәтә.

Кече туганнарның күпчелегенең экиятләрдә җиңүче һәм акыллы итеп сурәтләнүенең асыл мәгънәсе дә менә бу момент белән аңлатыла ала ...

Экиятләрнең бик күбесе авыл халкы арасында барлыкка килгән һәм авыл халкы арасында сыйнфый күренешне гәүдәләндергән экиятләр бик күп. «Көсә масалы», «Ыргат масалы» кебек экиятләр моның ачык мисалыдыр. Моның кебек экиятләр – халык арасында иң күп сөйләнгән әсәрләр. Олылар да, кечеләр дә аларны кызыксынып тыңлыйлар. Бу экиятләрдә эксплуататор сыйныфка каршы кискен ачу хисе (протест) бар.

Экиятләрдә кеше образлары белән берлектә хайван образлары да зур урын тота. Кешеләрнең якын дуслары буларак атлар һәм кошлар алына. «Атморад» кебек дөлдел (җәйрән, канатлы атлар) кешеләрне иң авыр бәлаләрдән коткаручы һәм һич чишеп булмастай мәсьәләләрне хәл итәргә булышучы бер юлдаш итеп күрсәтелә.

Моны, мәсәлән, «Памук (мамык) кыз» исемле оста иҗат ителгән экияттә күрергә мөмкин. «Бер патшаның оч

улы була. Көннәрдән бер көнне патшаның күзе сукырая. Угыллары аталары өчен дәва эзлиләр. Иң азакта патшаның кече улы дөлдөлгә атланып, атасын сукыраюдан саклаучы чара эзләп чыгып китә. Ул, ат тоягы басмаган җиргә барып, бер уч туфрак ала. Шул җирдә бер гаять гүзәл кыз белән очраша һәм аңа өйләнә. Юлда бер патша бу кызны үзенә алмакчы була. Бу кыз исә диңгездә яшәгән һәм гаҗәеп канатка ия булган бер кошның бик матур кызы була. Патша егетне куркытып. бу кызны алырга теләгән чакта егеткә акыл бирүче һәм аны коткаручы дөлдөл ат була.

Дөлдөл егеткә: «Патша егерме биш яшенә кайтса, ягъни яшәрсә, мин аңа кызны бирермен, – дип әйт, патша яшәрер өчен чара эзләр, без аны ул вакытка кызык итәрбез, – ди. Егет патшага килеп дөлдөл өйрәткәнне әйтә. Патша яшәрер өчен юллар эзли, әмма таба алмый. Үз кулы астында булган бөтен халкын җыя, алардан: «Ничек итеп яшәрим икән?» – дип сорый. Картлардан берсе: «Диңгездәге кырык бияне тотып савыгыз һәм аларның сөтен зур бер казанга салып кайнатыгыз, соңыннан, падишаһым, шул кайнап торган сөткә кереп чыгыгыз», – ди. Патшага бөтен эшне эшләп бирәләр, сөтне кайнаталар, ләкин патша кайнар сөткә чумарга курка. Шунда дөлдөл егеткә эндәшеп: «Мин пошкырырмын, сөт суыныр, син сөткә чумып чыгарсың, синнән соң патша керер», – ди. Шулай эшлиләр. Патша сөткә төшә. Дөлдөл ул арада тагын бер тапкыр пошкыра. сөт кайнап чыга. Патша сөттә бөрешеп үлә. Вәзирләр патшаның янында чакта, егет кызны алып үз иленә кача».

Шулай итеп, бу әкияттәге егеткә батырлык юлын өйрәткән һәм җиңәргә ярдәм иткән хайван ат була. Бу ат-күкләргә очкан, һәр нәрсәнең серен белгән, акыллы, батыр һәм каһарман бер ат. Мондый атлар кырым татар әкиятләренең иң сөйкемле образларыннан санала. Бу

төр атлар, гадәттә, фәкыйрьләргә ярдәм итүче хайваннар. Аларның юлына бер нәрсә дә каршы тора алмый. Патшаның атларын исә хәтта кешеләр дә уза ала. Бу хәл «Кырымның кара чәче» дигән әкияттә бик ачык күренә. Монда патшаның дөлдөлен чулак бер адәм уза (...)

Әкиятләрдә ат образыннан кала, бөркет образы да бик популяр. Бөркет, еш кына, диюләргә каршы көрәшүче образ буларак бирелә. Бөркет җиде кат караңгылыкта җирнең төбендәге халыкны газаплап тоткан җиде башлы диюләрнең, аждаһаларның башын кисеп, халыкка тынычлык биргән, су китергән егетләргә ярдәм итүче самими, ышанычлы дус итеп күрсәтелә.

Мәсәлән: «Фәкыйрь улы аучы» дигән әкияттә аучы егеткә патшаның кызын алып бирүдә ярдәм итүче аю, арыслан, төлке, бөтен ерткыч хайваннарны бергә җыеп, патшага каршы җирдә һөҗүм оештыралар. Бөркет исә, барлык бөркетләрне туплап, һавадан һөҗүм итә, таш яудыра. Шулай итеп, патшаны җиңәләр, патша кызын фәкыйрь егеткә алып бирәләр.

Патша кызын алу һәм шуның белән патшалыкны да үз кулына төшерү хыялы – әкиятләрдәге геройның төп идеалларыннан берседер. Бу хәл халыкның хакимиятне үз кулына алу хакындагы элек-электән яшәп килгән хыялы белән бәйле. Халыкның әкиятләрдә яшәп килгән бу өмет-теләкләре бик борынгы дәверләрдән бирле дәвам иткәнлеген ачык аңлар өчен, әкиятләрдәге гаҗәеп бөркетләргә, атларга һәм төрле хайван образларына да игътибар итәргә кирәк.

Хаклык һәм бәхет өчен көрәшкән кешеләргә һәркем, һәрнәрсә ярдәмгә килә.

Борынгы вакытларда кешеләр тормышны могҗизалы затлар һәм гаҗәеп хәлләр белән тулы дип күзаллаганнар,

диңгез патшалары, су анасы булганына инанганнар, алар хакында бик күп легендалар, экиятләр иҗат иткәннәр. Һәр төрле могҗизалар, каргышлар яки кайчак кешенең үз шәхси теләге нәтиҗәсендә, икенче кешене куркыныч хайванга я дә берәр предметка, табигать күренешенә әверелдерә ала дип ышанганнар. Бездәге «Вай-вай анам кызы» легендасы кебек әсәрләр әлеге ышанулар нәтиҗәсендә мәйданга чыккан. Бу инанычларның барлыкка килүенең төп сәбәбе дә: кешеләр ул вакытларда, ягъни башлангыч дәвердә, әле табигать кануннарын белми иделәр. Шуңа күрә алар табигать көчләреннән куркынып гаҗиз булганнар, аларның табигать хакындагы фикерләре бөтенләй башка төрле иде. Алар, югарыда әйтелгәнчә, табигатьне гаҗәеп могҗизалы барлыклар һәм явыз көчләр белән тулы дип сурәтли иделәр. Мондый тасвирлар нәтиҗәсе буларак, табигатьтәге бу могҗизалы көчләрне җиңүгә багышланган экиятләр, легендалар мәйданга чыга, табигать көчләрен үзләренә буйсындыру омтылышы арта. Нәтиҗәдә, диюләрне, аждаһаларны, еланнарны җиңү хакында экиятләр, келәмгә утырып очу (кайбер экиятләрдә намазлык өстенә утырып очу) кебек әсәрләр туа. Шул ук вакытта һәр нәрсәне белүче һәм кешеләр телен белүче, аларга ярдәм итүче дөлдөлләр хакында да экиятләр иҗат ителә (...)

Кырым татар экиятләренең зур күпчелеге реаль чынбарлык белән бәйле әсәрләр. Аларда халыкның тормышы һәм хыял-омтылышлары тагын да ачыграк һәм конкрет чагыла.

Мәсәлән, 1896 елда академик В.Радлов тарафыннан язып алынган «Бөск Ламбат масалында» (Зур Ламбат экияте) халыкның үз милли азатлыгы өчен барган көрәшләре һәм омтылышлары ачык күренә. Монда нигез буларак, Кече угъланның кырык башлы аждаһага каршы көрәше алына.

Кечс угъланның һәрбер хәрәкәте тыңлаучыларда байларның халыкка каршы кыланышларына нәфрәт уяту максаты белән эшләнгән.

Кече угъланның кырык башлы диюне җиңеп, Кырым җирләрен ул вакытта аның асыл хуҗасы булган халыкка кайтарып бирүен әкият сөйләүче тыңлаучыларга төп нәтиҗә итеп хәзерләп бирә.

Әкиятче Кече угъланга булган мәхәббәтен аерым детальләрдә ачык күрсәтә. Мәсәлән, Кече угълан, алдау юлы белән алтын туплаган Җоллад патшаның золымыннан халыкны коткара, сугышларда гаҗәеп батырлыклар күрсәтә, шәхси тормышында һәм һәрбер эшендә зур тугрылык вә гуманизм бар. Бу момент бигрәк тә аның үз хатынына һәм хатынының аңа булган мөнәсәбәтендә күренә. Әйтик, сугыштан җиңеп кайткан чакта Кече угълан юлда коега төшә һәм бу вакыт коедагы Кокче убыр аны кое төбенә тартып ала. Ул убырның кулыннан хатынын коткара, ләкин үзе Кокче убыр кулына эләгә. Әкиятнең кульминацион ноктасы да менә шул җирдән башлана.

Халыкны һәм хосусан хатын-кызларны коллыкта тоткан могҗизалы Кокче убырның җаны кырык башлы аждаһаның йөрәгендә саклана торган бер тартмада торган була. Кече угълан төрле юллар белән бу турыда белә, кырык башлы аждаһаны үтерер һәм үз хатынын коткарыр өчен чара эзли. Үз максатына ирешү өчен ул бер көтүче урынына көтү көтәргә керә. Көннәрдән бер көнне кырык башлы аждаһа авылны таларга килә. Аждаһа халыкның җирен, мал-мөлкәтен тартып алучы, туздыручы-яндыручы явыз көч итеп күрсәтелә.

Кече угълан исә Кырым халкының каһарманы итеп, җиңелмәс кодрәткә ия итеп бирелә; аждаһаның утыз тугыз башын кисә, бер генә башын калдырып, интектереп үтерә.

Моннан соң авылның старосталарына «Әмер ит, бүген монда Кече Ламбаттан, Тегермән авылыннан, Партинеттан, Куркюлеттән, Кызыл-Таштан, Гурзуфтан, Алуштадан, Никитадан кешеләр килсеннәр», – ди. Бу авыллардан кешеләр җыелып килә. Кече угълан килгән халыкка: «Әй, җәмәгать! Моңа кадәр бу малларны ничек бүлә идегез?» – дип сорый. Җәмәгать: «Ничек бүлик инде, монда бер аждаһа пәйда булды, ул безнең атыбыз булса, атыбызны, малыбыз булса, малыбызны ашады, аның рөхсәтеннән башка аяк та атлап булмый иде», – ди.

Кече угълан: «Карагыз, җәмәгать, бүгеннән ары бу өлеш сезгә вакыф булсын! Бәлки көтмәгәндә, бер бай кеше килеп чыгар да, бу җир минеке дияр, моны ишетсәм, үтерермен аны! Бай-фәкыйрь булмасын, барысы тигез куллансын, арагыздан берегез чыгып, бу җир минеке димәсен!» – ди. Авыл халкы Кече угъланга моның өчен акча бирергә тели, ләкин ул акчаны алмый. Аждаһаның йөрәген ярып, анда сакланган тартманы ала һәм андагы тургайны үтереп, Кокче убырның башына җитә. Шулай итеп, үз хатынын һәм аның белән коллыкта тотылган башка хатын-кызларны азат итә. Аларны Кырымнан читкә, үз ватаннарына илтә. Бу момент исә кырык башлы аждаһаның бары тик Кырым халкын гына түгел, башка халыкларны да коллыкта тоткан явыз көч икәнлеген күрсәтә. Моның кебек демократик моментлар экиятнең кыйммәтен һәм халык иҗатының әһәмиятен тагын да үстерәләр.

Бу экият тирән гуманистик рухка ия. Анда гәүдәләндерелгән хезмәт иясе халкы чын һәм иң яхшы демократик идеал итеп бирелә. Ягъни бу төр экиятләрдә суы ширбәт, туфрагы алтын, багъ-бакчалары бетмәс-төкәнмәс хәзинә булган туган җирдән мәхрүм ителгән халыкның сыкрануы чагылыш таба. Патша колонизаторлары һәм

байлар тарафыннан җирсез калдырылган игенчеләр авылы-авылы белән, йорты-йорты белән күченеп китәргә мәҗбүр булган иделәр. Калганнары да таулы-ташлы һәм уңдырышсыз җирләргә генә урнаша алган иде.

Шушындый авырлыкларга һәм милли изүгә чыдый алмыйча, 1860-62 елларда гына да 231177 татар авыл кешесе Кырымны ташлап китәргә мәҗбүр булган. Авыл халкының 60 меңнән артыгы Кара диңгез дулкыннары эчендә батып юкка чыга. Үлмичә исән калганнары исә барган җирләрендә солтаннар, байлар тозагына төшеп, ач-ялангач теләнче хәлендә гомер итә. Кырымның гүзәл табигатенә, бәрәкәтле җирләренә колонизатор сарайлары төзелә, бик күп җирләр татар байларына, морзаларына өләшенә, гади халык алар кулында коллыкта һәм милли изелүдә тотыла. Халыкның бу коллыктан котылу хакына оештырылган көрәше һәм теләк-омтылышлары табигый рәвештә аның авыз иҗатында урын ала. Бу төр экиятләрдә халыклар дуслыгы мотивы чагылыш таба.

***

Кырым татар экиятләрендә дин әһелләренә, муллаларга каршы кискен сатира, ачу һәм протест тойгысы күренә.

Сатирик экиятләр үзләренең төзелеше җәһәтеннән башка экиятләр белән чагыштырганда гаять кыска формада булуы белән аерылып торалар. Мондый форма әлеге экиятләрне тагын да тормышчан һәм озын гомерле итә.

Бу экиятләрдә аеруча игътибар итәргә кирәк булган мөһим бер момент бар, ул да булса дингә, динчеләргә – казый һәм муллаларга каршы көрәштә хатын-кызларның да актив катнашуы.

(...) Әкиятләрдәге кызлар – батыр йөрәкле, үз бәхетләре өчен көрәшүче кызлар. Моның иң җанлы мисалы «Аккабак кыз» әкияте. Бу әсәрдә «яла ягылган» хатын һәм үз тормышын үзе кора белүче кыз образлары бирелә. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, «Аккабак кыз» әкиятенең сюжеты А.С. Пушкинның «Салтан патша турында әкият» дигән әсәренең сюжетына (хосусан әсәрләренең башлану өлеше) бик якын тора. Рус галимнәре «Салтан патша» әкиятенең конкрет кына кайсы чыганакка нигезләнүен бүгенге көнгә кадәр әйтә алмадылар. Бер төркем галимнәр бу әсәрне, халык иҗатыннан бигрәк, Көнбатыш Европа язма әдәбиятына ияреп язылганын әйтергә телиләр.

Азадовский үзенең «Пушкин әкиятләренең чыганагы» дигән бер мәкаләсендә Көнбатыш Европада «яла ягылган ана», язма әдәбияттан башка, халык авыз иҗатында да билгеле булган традицион сюжет», – дип әйтә дә, үз фикерен дәвам иттерен: «Салтан патша турында әкият»тә дә Көнбатыш Европа авантюр повестьларының тәэсире шактый күренә. Чародей образы, әйтерсең, князь Гвидонның үз йөзе инде, болар барысы Көнбатыш Европа повестьләренә якын тора», – ди.

Безнең фикеребезчә, «Салтан патша» әкиятенә Кырым татар әкиятләреннән «Аккабак кыз» әкияте кебек әсәрләрнең дә йогынтысы юк түгел. Монда һәм сюжет, һәм дә тематика җәһәтеннән зур бер охшашлык бар. Пушкин, Кырымда булганда, татар халкы иҗатын зур кызыксыну белән өйрәнгән. Ихтимал, бу вакыт ул әлеге тор әкиятләр белән дә таныш булгандыр. Пушкин әкиятендә булган кебек, «Аккабак кыз» әкиятендә дә өч бертуган кыз тәрәзә төбенә утырып, җеп җегерлиләр. Алар шунда үзләренең патшабикә буласы килүен сөйләп, бер-берләренә хыялларын ачалар.

Кызларның зурысы: «Мин патшабикә булсам, бер чатыр корыр идем, ул чатырга патшаның бөтен гаскәре сыяр иде», – ди. Уртанчысы: «Мин патшага бер казан ясар идем, бу казанда пешерелгән ашны бөтен гаскәре ашаса да, яртысы артып калыр иде», – ди. Кызларның иң кечесе исә: «Мин патшага бер угълан, бер кыз тудырыр идем, аларга карап ай һәм кояшны күргәндәй булыр иде», – ди.

Патша бу кызларның сөйләшүен тәрәзәнең теге ягыннан тыңлап тора һәм икенче көнне кызларның өчесенә дә яучы бирә һәм өчесен дә үзенә кияүгә ала.

Көннәрдән беркөнне патша сугышка китә, ул киткәч, кече кыз бер угълан, бер кыз таба. Чынлап та бу балалар гаять тә матур булалалр.

Патшага илче җибәреп, балалар туув хәбәр итәләр. Апалары, сеңелләреннән көнләшеп, бер хезмәтчегә әйтеп, балаларны сандыкка куеп, диңгезгә ташлаталар. Балалар урынына исә ике эт баласы китереп, бишеккә куялар. Бервакыт патша өенә кайтып керә. Ул өендә бала урынына көчекләрне күрә. Бу хәлне күргәннән соң, нишләргә белми, ачулана, кече хатынын иң авыр җәзага тарта: юл уртасына чокыр казытып тереләй күкрәгенә кадәр күмдерә. Ике ягына ике эт баласын күмдерә. Бу хатын өчен тәрбә ясата, аның тышына «Килгән-киткән кеше төкереп узсын», – дип яздыра. Шулай итеп хатынны җәзалый. Сандыкка салып диңгезгә ташланган балалар бераз вакыттан соң икенче патшалыкка килеп чыгалар. Анда бу балаларны сәйранга чыккан патша кызлары табалар һәм өйләренә алып кайталар. Балалар бу патшалыкта үсеп буйга җитәләр. Көннәрдән беркөнне алар үз ата-аналарын эзләргә чыгалар. Юлда бер җирдә яшьләр тукталып өй корып җибәрәләр, егет аучылык итә, шуның белән тамак туйдыралар. Бу егет беркөнне ауга чыккач патша белән очраша. Ата белән угыл бер-бер-

сен танымыйлар. Өенә кайткач, бу егет турында патша хатыннарына әйтә. Ул хатыннар бу егет белән кызыксына башлыйлар һәм аның диңгезгә ташланган бала булуын беләләр. Патша хатыннары хезмәтче яллап егет белән кызның туганлыгын бозарга тырышалар. Ләкин аларның бу эше барып чыкмый, шуннан соң алар егет белән кызны өйләренә кунакка алып, агулап үтерергә уйлыйлар. Егет бу вакытта Аккабак исемле кызга өйләнгән була. Алар кунакка өчәүләп (егет, килен һәм кыз) киләләр. Аккабак кыз патша хатыннарының максатын аңлый, егет белән кызны үлемнән коткара, килгән кунакларның икесенә исә патшаның кече хатыныннан туган балалар хакында әйтә. Патша бу хәлгә бик аптырый һәм ашыгыч рәвештә кече хатынны азат итәргә боера.

Шулай итеп «яла ягылган» хатын Аккабак кыз ярдәме белән азат ителә һәм яңадан рәхәт гомер итә башлый. Бу әкияттән күренгәнчә, иң зур батырлыкны эшләүче һәм яла ягучыларны фаш итүче Аккабак кыз була.

Мөндый хаклык һәм дуслык өчен көрәшкән хатын-кыз образлары Кырым татар әкиятләренең төп образлары санала. Әкиятләрдәге кызлар – «айның ундүрте», «дөнья гүзәле», «сурәтен суга салып эчәрдәй» дигән охшатулар белән бирелгән дилбәр кызлар. Аларга булган тирән мәхәббәтне бернинди көч тә җиңә алмый.

Әкиятләрдә, гомумән, халык иҗатында һәм язма әдәбиятта мәхәббәт – төп темалардан берсе. Халык иҗаты турында сүз йөрткәндә, мәхәббәтнең әтрафлы һәм тирән эшләнүе аеруча әкиятләрдә һәм эпик поэмаларда көчле күренә. Мәхәббәт турындагы әкиятләр зур поэмалар шәкелендә булалар. Бу әкиятләр күп вакытта шигырь белән зиннәтләнәләр. Мәсәлән, нигездә эпик поэма булган «Кузыкөрпәч» кебек әкиятләр бу төр әсәрләрдәндер.

Алар, феодализм шартларында дини изүгә каршы торган һәм инсан шәхесенең азатлыгын алга сөргән прогрессив әсәрләр буларак мәйданга чыкканнар. Бу әсәрләрдә фантазия байлыгының, хөрлек турындагы хыялның һәм мәхәббәт тойгысының тирәнлеге бик оста һәм көчле күрсәтелә.

Әкиятләрдәге бер-берсен сөйгән яшьләр – чын матур гаилә корыр һәм гомер итәр өчен җиңеп булмастай авырлыкларны җиңгән, патшалыкларны җимерә алган яшь кешеләр. Кызлар да егетләрнең бу көрәшендә аларга актив ярдәм итәләр, чөнки аларның һәрберсендә бер-берләренә булган чын, саф һәм эчкерсез мәхәббәт яши. Алар һәрвакыт бер-берләренә тугърылыклы булып калалар. Шуңа күрә дә бу әкиятләрнең әһәмияте хәзерге көндә һәм киләчәгебез өчен гаять зур.

«Мәхәббәт, ачлык кебек үк, дөнья белән идарә итүче» бер кодрәт. Культура дип аталган нәрсәләрнең һәммәсе булмаса да, зур бер өлеше хатын-кызга булган сөю хисләре нигезендә туган. Ачлык белән көрәш нәтиҗәсендә кешеләрне мәрхәмәтсез изгән залим «мәдәният» туса, мәхәббәт белән исә без ул культураның, цивилизациянең югары формасына күтәрелгәнен танырга мәҗбүр булабыз.

(...) Халык әкиятләрендәге мәхәббәт кешенең иң интим (яшерен) тойгысы буларак биеклеккә күтәрелә һәм тыңлаучыларга рух һәм гыйбрәт бирә, кешеләрдә яшәү шатлыгын арттыра.

Әкиятләрдәге мәхәббәт сатлык, черек яки ялган бер хис түгел. Бу мәхәббәт – хезмәт иясе халкының, изелгәннәрнең мәхәббәте – чын кешелек хисләре. Шуңа күрә бу хисне һичбер төрле байлык белән дә бозу яки сатып алу мөмкин түгел.

Мәхәббәт – олугъ язучыларның эсас һәм бөек

темаларыннан берсе. Моңа Горькийның, Пушкинның, Лермонтовның, Низаминың, Нәваиның, Гетеның, Шиллерның һәм Шекспирның әдәби мирасы мисал була ала.

Классик язучыларыбыз халык иҗатыннан даими файдаланганнар. Зур классикларга иҗат итү процессында Кырым татар фольклорының да тәэсире зур була. Пушкин һәм Гоголь Кырым татар халык иҗатыннан туктаусыз үрнәкләр алганнар. Мәсәлән, Пушкин Кырым татар экиятләре һәм җырлары нигезендә гаҗәеп «Бакчасарай фонтаны»н иҗат иткән булса, «Салтан патша турында экият»ен язганда да Кырым татар экиятләренә мөрәҗәгать иткән. Иҗаты интернациональ характерда булган бу шагыйрь казах халык иҗатын яратып өйрәнгән. Мәсәлән, аның архивында казах халкының «Кузыкөрпәч, Баянсылу» исемле дастаны нигезендә эшләнгән поэманың киң планы сакланган. Шагыйрьнең дошман кулыннан вакытсыз үлүе бу поэманы тәмамларга ирек бирмәде.

Пушкинның игътибарын җәлеп иткән «Кузыкөрпәч» поэмасы бездә дә бар. Бу әсәрнең төп темасы «Таһир илә Зөһрә»дәге кебек эчкерсез сөю һәм бәхетле тормыш өчен булган көрәштән гыйбарәт. Бу поэманың сюжеты «Таһир илә Зөһрә» поэмасы белән бер, ләкин «Кузыкөрпәч»тә татар халкының элекке тормышы һәм гореф-гадәтләре тулырак чагылыш тапкан.

Моннан кала, әсәрдә халыкның рухи бозыклыкларга һәм үз эшенә намуслы карамаган кешеләргә карата нәфрәте күрсәтелә (...)

Поэманың кыскача сюжеты шуннан гыйбарәт: көннәрдән бер көнне икс бай ауга чыга. Алар балалары туганчы кыз алып-кыз бирешү турында вәгъдәләшәләр. Бу моментның элекке татар экиятләрендә иң характерлы бер сыйфат булуын да искәртергә кирәк (Кырым татарларында

яшьтән үк балаларны ярәшү кайбер районнарда, мәсәлән, Судак һәм Алушта районнарында соңгы вакытларга кадәр дәвам итте).

Әкияттәге ике байның да балалары туа, берсенең хатыны ир, икенчесенеке кыз бала таба. Балалар үсеп буйга җитәләр. Беркөнне егетнең атасы үлә. Кызның атасы исә: «Мин ятимгә кыз бирмим», – дип, үз җиреннән башка җиргә күчеп китә. Әкиятче моннан чыгып кызның атасы бозык йөрәкле, усал кеше булуын тасвир итә. Бу момент «Кузы көрпәч» поэмасын «Таһир илә Зөһрә» поэмасыннан аера. Моннан башка да ике әсәрнең чишелешендә бераз аерымлыклар бар. Мәсәлән, «Таһир илә Зөһрә» поэмасында гашыйкларның каберләре өстенә үсеп чыккан гөлләр бер-берсе белән кавыша алмасалар, Кузыкөрпәч белән Баянсылуның каберләре өстендә үскән гөлләрне бернинди явыз көч тә аера алмый, алар мәңгелеккә кавышып, гел чәчәктә утыралар.

Берничә сүз әкиятләрнең композициясе һәм стиле хакында.

Әкиятләрдәге вакыйгалар берсе артыннан берсе чылбырланып киләләр, һич көтелмәгән вакытта булып узалар. Кайбер әкиятләрдә берничә кечкенә әкият-вакыйга бирелә, ләкин алар әкиятнең топ эчтәлегенә зыян салмыйлар. Һәрбер мисал конкрет бер нәтиҗә һәм тулы бер фикер тәшкил итә. Күп кенә алда күрсәтелгән әкиятләрнең азагы мәкальләр кебек көчле әйтелгән гыйбарәләр белән бетә. «Кара келди» әкиятенең азагында «башкаларга хыянәт итсәң, үзеңә дә шул килер», – диелә (...) Мондый мәкаль-гыйбарәләр, ихтимал, әкиятләрнең нәтиҗәсе буларак та формалашкандыр дип тә әйтергә урын бар. Әкиятләр халык иҗатының иң борынгы жанрларыннан берсе икәнлеген исәпкә алсак, мондый нәтиҗә мантыйклы дип әйтә алабыз. Шөбһәсез, бу

фикер тирән тикшеренүне таләп итә. Монда тагын шуны да әйтергә кирәк ки, экиятләрнең башлангычы һәм йомгагы даими бер формада була. Әкият «бер заманда бар икән ди, юк икән ди, патшалыкның берсендә бер егет белән бер кыз бар икән, ди», – дип башланса, мотлака, «Хәсрәт хәсрәткә кавыша, алар морадларына ирешәләр», – дип бетә. Моннан башка экиятләрдә вакыйгалар хикәя ителгәндә кабатлаулар, бер-беренә охшатулар күп була. Мәсәлән, өч угъланның юлга чыгулары, җир астына төшеп бәхет өчен көрәшүләре бик күп экиятләрдә төрле-төрле формаларда кабатланып киләләр. Моннан кала тагын кырым экиятләрен шигырь-такмаклар да бизәп килергә мөмкин. Кырым татар фольклорының зур бер поэтик сәләткә ия булуын да ассызыкларга кирәк. Халыкнын музыкага булган һәвәсе һәм шагыйрьлеге экиятләрдә ачык сизелеп тора. Әкиятчеләр экият сөйләгәндә үзләренә генә хас кой-мәкам кулланалар. Бу көй-мәкам аеруча экиятнең шигырь белән әйтелгән өлешендә зур роль уйный. Мәсәлән, «Нар камыш» кебек экиятләрнең үзләренә генә хас көе-мәкамы бар.

Кырым экиятләренең бик күбесе шигырь белән әйтелә. Бу хәл экиятнең төзелешенә куәт һәм җанлылык бирә, тыңлаучыларның экияткә булган һәвәслеген кат-кат арттыра. Мәсәлән, «Әсирлеккә сатылган угълан» дигән экияткә тукталыйк. Мондагы бәетләр әйтергә теләгән төп фикерне көчәйтү һәм тыңлаучыларда экияткә кызыксыну уяту өчен китерелә. Әкиятче сөйли-сөйли дә, экият уртасында:

*«Аз китә, күп китә,*
*Төпкә таба туры китә.*
*Әйләнеп бакса, ни күрсен:*
*Инә буе юл китә», – ди.*

Әкиятчеләр тыңлаучыларны һич тә арытмыйлар, аларның игътибарын яңадан-яңа мәсьәләләргә җәлеп итеп

торалар. Алар үзләренә дә игътибар итүне телиләр. Шуңа күрә, әкият сөйләгәндә:

*Без бу җирдә туктаек,*
*Берәр касә эчәек.*
*Тамакларыбыз чылансын,*
*Әкиятчеләр уйлансын, – диләр, аннары:*
*Тамагыбыз чыланды,*
*Әкиятче дә уйланды, –*

дип тагын әкиятне дәвам иттерәләр.

Халык әкиятчеләрне чын күңелдән хөрмәт итә, ярата, күп мәртәбәләр тыңласа да, кичләр буе җыелып, тагын шул ук әкиятне кабат-кабат тыңлый һәм тыңлаган саен аннан аерым бер зәвык таба. Мондый моментлар исә әкият сөйләүнең аеруча бер талант һәм осталык таләп иткәнлеген тагын бер кат исбатлый.

Кырым әкиятләре башламнарга, такмакларга да бай. Такмаклар, нигездә, тыңлаучыларның төп игътибарын әйтеләсе мәсьәләгә җәлеп итү өчен хезмәт итә. Кайчакта аларның төп эчтәлек белән һич кенә бәйләнеше булмый. Такмаклар үзләренә генә хас көйгә, тиз-тиз әйтеләләр. Менә шул мисалга игътибар итегез:

*Әүвәл-әзәл икән, ди,*
*Әүвәл заман икән, ди,*
*Цөя дәллал икән, ди.*
*Син бишектә икән, ди,*
*Мин ишектә икән, ди.*
*... Көнебез бакыр икән, ди,*
*Өебез такыр икән, ди ...*

(...) Такмакларның вазифасы – тыңлаучыларны хәзерләү. Мондый кызыксындыру белән башланган кырым татар әкиятләре, гадәттә, язгы-көзге кыр эшләре беткәч, кышның озын кичләрендә сөйләнә. Әкиятчеләргә хөрмәт

күрсәткән халык алар өчен авылларда махсус каймаклы каһвә (кофе) хәзерләгән, тәмле аш-су да пешергән.

Әкият сөйләү кайвакытта иртәнгә кадәр дәвам итә. Бу вакытта да бетмәсә, икенче яки өченче кичләргә калдырылган. Башка халыклардагы кебек, кырым татарларында да әкият көндез түгел, кич белән, аеруча кышкы кичләрдә сөйләнгән. Борынгы ышанычларга карасаң, көндез әкият сөйләп утыру гөнаһ икән. Бу төр ышанулар бик күп халыкларда бар. Әкиятләрнең билгеле бер ел фасылында һәм көннең аерым бер вакытында сөйләнүе, безнең фикеребезчә, халыкның хезмәте белән бәйле. Билгеле булганча, әкият озак вакытта сөйләнә. Әкиятчеләр исә күп вакытта тыңлаучыларның өендә сөйлиләр. Әкият сөйләү-тыңлау эше шул кадәр кызыклы була ки, әкиятче бер яки ике әкият сөйләп кенә үз эшен бетерми, әкиятләр берсе артыннан берсе дәвам иттерелә. Күпчелек вакытта әкиятне картлар сөйли. Аларда исә зур сабырлык һәм түземлек бар! Алар үзләренең һәрбер сүзен тыңлаучыларга барып җитәрдәй итеп әкрен-әкрен, сабыр гына сөйлиләр. Мондый чын әкиятчеләр сүзгә бай һәм әдәби стильгә оста булалар. Шуңа күрә бу әкиятчеләр тарафыннан сөйләнгән кырым татар әкиятләренең теле ачык һәм садә була. Бу тел – халыкның көндәлек сөйләшү теленә һәм дә әдәби теленә азык биреп торган, җанлы һәм матур тел.

Әкиятләрдәге стилистик гадилек иң әүвәл җөмләләрнең кыскалыгында һәм аңлаешлылыгында күренә. Моннан башка алар чагыштыруларга да бик бай. Мәсәлән, «Зур Ламбат әкияте»ндәге Кече угъланның каһарманлыгын тыңлаучыларга көчле һәм үтемле итеп күрсәтү өчен «Елгалардан җил кебек, тау башларыннан сәл (агым) кебек китә», – диелә. Кече угълан каршы куелган дошман гаскәрләренең күплеген аңлату өчен, «Күктәге йолдызларны санап була, әмма гаскәрләрнең чатырларын санап бетереп булмый», – диелә. Янә дә «Кәл

огълан» («Таз малай») экиятендә элекке дәвер кызларының тормышын төгәл һәм кыска итеп аңлату өчен, «Читлектә утырган кош кебек яши», – ди. Әкиятләрдәге кызлар ай һәм кояш белән чагыштырыла ...

(...) Телнең байлыгы һәм матурлыгы аеруча чүл районнары экиятчеләренең сөйләмендә күренә. Аларда «Идегәй», «Чура батыр» кебек халык эпосының тәэсире көчле. Һәр ике эпоста да гаҗәеп тел байлыгы бар. Бу тел – гасырлар буена халыкның үзе тарафыннан эшләнгән җанлы һәм яшәүчән тел ул.

Бер-ике сүз экиятчеләребез һәм аларның әһәмияте турында әйтергә телибез.

Кырым татар халкының гаять оста экиятчеләре бар, ләкин тарихта алар хакында бернинди документ та сакланмаган дияргә була. Академик В.Радловның 1896 елда рус әлифбасында басылып чыккан хезмәтенең 7 нче томы кырым татар экиятләрен язма формада саклап калдыру җәһәтеннән кызыклы һәм гыйльми әһәмияткә ия булса да, экиятчеләрне өйрәнү ягыннан бу җыентыкның кыйммәте юк, чөнки анда экиятләрнең кемнән һәм кайчан язылып алынганлыгы күрсәтелмәгән, бары тик кайсы авылдан алынганлыгы гына әйтелгән.

Әкиятчеләрнең биографияләрен һәм аларның аерым-аерым бирү ягыннан 1937 елда «Кырым татар экиятләре» исеме белән Алупка музее тарафыннан чыгарылган җыентык кызыклы. Бу – музейның тәүге башлангычларыннан берсе. Ләкин, безнең фикеребезчә, җыентыкка әсәрләре кергән экиятчеләр профессионал түгелләр, ә бәлки үзешчәннәр генә. Шөбһәсез, иксез-чиксез байлыкка ия кырым татар фольклорын халык чичәннәре һәм экиятчеләре яшәткән. Ләкин алар хакында беркем тарафыннан да тулы мәгълүмат тупланмаган. Бу мөһим эш бүген

дә иң авыр мәсьәләләрдән берсе булып кала бирә. Аеруча халык чичәннәренең дәверләрен, сөйләгән әсәрләрен тулысынча белми торып, фольклор тарихын тулы һәм тирән өйрәнү эше бик авыр. Шуның өчен бу мәсьәләне, бөтен мөһимлеген аңлап, чишү юлын эзләргә кирәк.

Бүген дә бездә исән булган һәм халкыбызның әкиятләрен белүче, аларны халык арасында таратучы Бекмамбәт Колмамбәт дигән бер карт бар. Бу карт үзе хакында болай ди: «Мин, Бекмамбәт Колмамбәт, 1860 елда Керчь районы Салын авылында фәкыйрь гаиләдә туганмын. Минем атам да, анам да байларда хезмәтче булып эшләделәр. Мин үзем исә 12 яшемнән байларда бозау көтә башладым. Минем хезмәтче булып йөрүем 1922 елга кадәр дәвам итте (...) 1922 елдан башлап, совет дәверендә үзем белгән халык әдәбиятын сөйләдем, җырладым, уйнадым. Мин моннан кала 1895 елларга кадәр байларга, морзаларга һәм патшага каршы җырлар чыгаручы халык чичәне Ишморза карт дигән Маяк-Салын авылыннан бер агайны авылдан-авылга ияртеп йөрдем (...)»

Бекмамбәт Колмамбәт аганың кыйммәте шундадыр ки, ул кырым татар фольклорының бөтен жанрларын һәм аларның иң гүзәл үрнәкләрен ничә еллар буена саклап һәм таратып йөргән. Ул шулай итеп кырым татар җәмәгатьчелеге өчен зур иҗтимагый эш башкарган.

Ул «Идегәй» һәм «Чура батыр» кебек борынгы эпос әсәрләренең иң тулы вариантларын һәм 19 гасырда яшәгән халык чичәне Ишморза картның җырларын белә. «Идегәй» һәм «Чура батыр» кебек, Ишморза картның җырлары да кырым татар классик әсәрләре рәтендә. Бекмамбәт агай Ишморза карт кебек халык чичәне янында тәрбия алган. Ул халык иҗатын туплау һәм аны халык арасында җәелдерү эшен үзенә асыл вазифа, төп эш итеп алган. Халык аны бу

эше өчен ярата, хөрмәт итә. Бу картның иҗат хәзинәсендәге бай материалларны Тел һәм әдәбият гыйльми-тикшеренү институты язып алды, аның сөйләгәннәрен бастырып чыгарырга әзерләнә. Аның кыйммәтле ягы – халыкның каһарманлык сыйфатын һәм ватанга булган тирән мәхәббәтен күрсәткән әсәрләрне хәтердә саклавы.

Бекмамбәт картның еллар буе саклап килгән кыйммәтле материаллары Бөек Октябрь революциясе нәтиҗәсендә киң һәм ирекле рәвештә иҗтимагый урыннарда һәм эшчеләр аудиториясендә тыңлана башлады.

Революциягә кадәр бу халык акыны киң җәмәгать трибуналарына чыгып, бар тавышына үз иҗатын халыкка җиткерә алмады. Аның тыңлаучылары бары тик аерым фәкыйрь авылларның крестьяннары, көтүчеләр генә булды. Байлар, муллалар картның эшенә төрле юллар белән аяк чала, аны халыктан ераклаштырырга тырышалар. Буржуаз милләтчеләр аның репертуарыннан Ишморза картның җырларын төшереп калдырырга омтылдылар. Бекмамбәт карт – кырым татар халык иҗатын туплаган һәм аның иң яхшы әсәрләрен пропаганда ясаган бер карт. Бездә мондый картлар тагын күп, ләкин алар белән җитди һәм даими эшләүче генә юк. Колхозларда бик күп матур итеп әкият сөйләүче картлар һәм карчыклар бар. Экспедицияләр оештырылганда, яки башка юллар белән фольклор туплаганда күбесенчә җырлар, көйләр язып алына. Бу бик яхшы, ләкин әкиятләрне дә җыярга кирәк.

Һәрбер әкиятченең үзенә генә хас стиле һәм иҗат характеры бар. Бекмамбәт карт аеруча эпик әсәрләрне ярата. Бу аның сөйләгән әкиятләрендә дә сизелеп тора. Мисал өчен «Мамык кыз», «Томалай арув» әкиятләрен алыйк, бу ике әкияттә дә кызларның акыллы, кыю фикерле һәм батыр йөрәкле булуы хикәя ителә. Карт үз әкиятләрен,

«Идегәй», «Чура батыр» һәм «Көр оглан» кебек әсәрләрне аерым бер җылылык белән сөйли. Бекмамбәт агай эпос әсәрләрне үзенчә көйгә салып әйтә, бу хәл тыңлаучыларда аерым бер мәхәббәт уята.

Без моның белән бергә, Пушкин һәм Горький кебек генийларның Кырым белән бәйле мөнәсәбәтләрен һәм аларның иҗатында булган кырым татар фольклоры мотивларын бөтен җитдилеге белән өйрәнергә тиешбез. Горький, үлеменә берничә ай элек Кырымда булганда (Маршак белән берлектә), балалар өчен язып бастырырга теләгән әсәрләре өчен файдаланырга теләп, бездән кырым татар әкиятләренең исемнәрен һәм эчтәлекләрен яздырып ала. А.М. Горький, әкиятләрдән файдаланып, совет балаларына кызыклы әсәрләр бирергә теләде. Ләкин халык дошманнарының канлы куллары әдәбият генисн бездән вакытсыз аерды.

Әкиятләрдә хикәя ителгән матур багъ-бакчалар, гөлләр, былбыллар, таулар, кыялар һәм диңгезләр – болар барысы Кырымның гүзәл табигатеннән алынган. Гаять зур әдәби әһәмияткә ия булган кырым татар әкиятләре халыкның ватанга булган мәхәббәтен аңлату һәм тәрбияләү өчен хезмәт итә. Әкият геройларының зур күпчелеге үзләренең бәхете өчен көрәшеп, ерак илләрдә, башка патшалыкларда, җиде кат җир төбендә калсалар да, әсәр азагында барыбер җиңү белән үз туган җирләренә, нигез йортларына әйләнеп кайталар. Мондый сыйфатлар халыкның үз ватанына булган тирән мәхәббәте белән аңлатыла.

Бездә бүген тупланган әкиятләр – аерым бер әкиятчеләрдән генә түгел, Кырымның төрле районнарыннан җыелган әсәрләр. Шуңа күрә аларга югарыда бирелгән бөя киң халык репертуарын күздә тотып бирелде.

*Чыганак: Керим Джаманаклы. Къырымтатар масаллары // Йылдыз (Украина. Кырым Мухтар Джумхуриети). – № 3. 2004. – 13-41 б.*

## ТУКАЙ, САБИР ҺӘМ ТУКТАРГАЗЫЙ

Билгеле булганча, милли әдәбиятлар, әдәби иҗатлар, төрле дәрәҗәдәге әдәби элемтәләр, тәэсирләр, каршылыклар аша үсәләр. Шуның белән бергә, милли әдәбиятлар һәм әдәби иҗатлар, үзләренә хас булган үзенчәлекләрне саклау белән бергә, гомуми интернациональ әдәбиятны баетуга да өлеш кертәләр.

(...) Күпмилләтле әдәбиятыбызның тарихи үткәнен, хәзерге чорын өйрәнгәндә, әдәби элемтәләр, тәэсирләр һәм каршылыклы әдәби йогынтылар турындагы проблемаларны кую һәм хәл итү аеруча әһәмияткә ия.

(...) Реакцион буржуаз галимнәр – әдәбиятны, әдәби процессны гади чагыштыру юлы белән өйрәнүчеләр һәм буржуаз компаративистлар бигрәк тә сугыштан соңгы чорда, Европа әдәбиятларын «өйрәнү» нәтиҗәсендә Көнбатыш илләрдә бердәм культура, бердәм әдәбият барлыкка килгәнлеген расларга, славян халыклары әдәбиятларының «бу культура», «бу әдәбият» тәэсирендә үскәнлеген күрсәтергә тырышалар. Шул ук формада Көнчыгыш халыклары әдәбиятларын өйрәнүче компаративистлар да, буржуаз чагыштыру методы белән эш итүчеләр дә төрек-татар телләре системасындагы әдәбиятларның көнчыгыш буржуаз әдәбиятларының йогынтыларында үскәнлеген расларга омтылалар.

Менә мондый шартларда аерым әдәбиятлар, аерым иҗат ияләре арасында булган элемтәләрне, тәэсирләрне, йогынтыларны барлык тирәнлеге белән өйрәнү мәсьәләләре хәзерге көн әдәбият белеменең игътибар үзәгендә тора.

Безнең әдәбият белемебез буржуаз теорияләргә, буржуаз йогынтыларга, вульгар чагыштыручыларга, вульгар аналогияләргә нигезләнеп эш йөртүчеләргә каршы кискен көрәш алып барырга тиеш.

Буржуаз чагыштыру методы һәм вульгар аналогия принциплары белән эш итүчеләр әдәби йогынтыны, әдәби тәэсирләрне механистик бер формада булган гади бер акт дип карыйлар. Алар аерым язучыларның субъектив иҗат үзенчәлекләрен, эстетик принципларын бөтенләй исәпкә алмыйлар. Буржуаз галимнәр әдәби иҗатны, аерым милли әдәбиятларның милли үзенчәлекләрен конкрет тарихи, иҗтимагый, политик шартлардан бөтенләй аерып алынган хәлдә үскән автономияле бер процесс дип карыйлар.

Әйтелгәнчә, әдәби элемтәләр, тәэсирләр һәм каршылыклы йогынтылар бик катлаулы иҗади бер процесс, шуңа күрә аны гади бер вульгар аналогия юлы, механистик чагыштыру алымы белән генә хәл итү һич тә мөмкин түгел. Милли әдәбиятлар арасында да бик күп гомуми уртаклыклар, охшашлыклар, якынлыклар булырга мөмкин, ләкин боларның һәммәсендә әдәби йогынты яисә әдәби элемтә юлы белән барлыкка килгән хәл дип бәяләү берьяклы булыр иде.

Бик күп әдәби иҗатларда булган гомуми уртаклыклар, якынлыклар тема, идея, проблемаларның куелышы, әдәби стиль һәм метод бердәмлеге, компаративистлар, вульгар социологлар раслаганча, автоматик яисә стихияле бер акт түгелдер.

(...) Билгеле бер чорларда аерым милли әдәбиятларның үсеш процессында, аерым язучыларның иҗатларында булган мәгълүм уртаклыклар, охшашлыклар, конкрет тарихи иҗтимагый шартларның үзенчәлекләре һәм ул үзенчәлекләрнең әдәбиятта чагылыш дәрәҗәләре белән органик рәвештә бәйләнгән һәм аларның нәтиҗәсе, чагылышы.

Менә шундый методологик принциплардан чыгып эш иткәндә, Совстлар Союзы халыкларының әдәбият тарихларының үсеш процессларында һәм аерым милли әдәбиятлар вәкилләренең иҗатларында булган уртаклыклар, якынлыклар һәм охшашлыкларның төп сәбәпләрен бик ачык итеп билгеләргә мөмкин.

Тукай, Сабир һәм Туктаргазый – бер үк тарихи чор барлыкка китергән халык шагыйрьләре. Аларның үзләренә генә хас индивидуаль милли үзенчәлекләре белән бергә бик күп иҗади уртаклыклары, охшашлыклары да бар.

Бу хәлләрнең нигезендә тик бер әдәби элемтәләр, каршылыклы иҗади йогынтылар гына түгел, беренче нәүбәттә, иҗтимагый тарихи шартлар һәм аларның үзенчәлекләре ята.

Бу өч шагыйрь арасында яшь ягыннан иң олысы азәрбәйҗан халык шагыйре Сабир (Мирза Галиәкбәр Таһир-Задә) 1862 елда 30 майда Азәрбәйҗанның Шәмәхә шәһәрендә, вак сәүдәгәр гаиләсендә туа. 7 яшендә мәдрәсәгә керә. 1874 елны Шәмәхәдә чорның күренекле шагыйре, педагог Сәет-Әҗим Ширвани мәктәбендә белем ала. Бу мәктәптә гомуми белем бирү белән бергә азәрбәйҗан һәм фарсы телләре аерым фән булып укытылалар. Сабир үзенең остазы Сәет-Әҗим Ширвани тәэсирендә, бик яшьли шигырьләр яза башлый. 23 яшенә кадәр Сабир туган шәһәре Шәмәхәдә яши. 1885 елда сәяхәт

итү һәм көнкүреш мәсьәләләрен җиңеләйтү нияте белән Иран, Урта Азия-Төркестанга сәфәргә чыгып китә. Ләкин атасының вафат булуы сәбәпле, бер-ике елдан соң туган шәһәренә кайтырга мәҗбүр була. Гомеренең күп өлеше авыр иҗтимагый шартларда уза. Булачак бөек шагыйрь сабын кайнатучылык белән һәм шуңа охшаган башка эшләр белән дә шөгыльләнергә мәҗбүр була.

1910 елны мөгаллимлек итә башлый. 1911 елның 25 июлендә вафат була.

Тукайдан 24 яшькә, Туктаргазыйдан 13 яшькә олырак булуына карамастан, Сабирның әдәби эшчәнлеге дә 1905 ел революциясе шартларында формалаша. Аның беренче шигыре 1903 елда «Шәркъи Рус» (Русский Восток) газетасында басылып чыкса да, чын иҗади эшчәнлеге 1905 елда «Хәят» газетасында басылган «Интернационал» исемле шигыре белән башланып китә. 1906 елдан алып гомеренең актык көненә хәтле Сабир «Мулла Насретдин» журналында язышa. Билгеле булганча, 1906 елның апрель аеннан Тифлистә азәрбәйҗан телендә революцион-демократик юнәлешле «Мулла Насретдин» исемле сатирик журнал чыга башлый. Сабирның иҗаты бу журналның редакторы, чорның күренекле язучыларыннан Җәлил Мәһмәт Колый-Задә ярдәмендә үсә. Колый-Задә рус культурасын, аның әдәбиятын яхшы белүче, иҗтимагый актив көрәшчеләрнең берсе була. Шул шартларда Сабир бөек халык шагыйре буларак формалаша.

Тукай һәм Сабирның каләмдәше, чордашы Хөсәен Шамил Туктаргазый* 1881 елның 10 нчы апрелендә, Кырымда Күккүз дигән зур татар авылында ыргат**

** Туктаргазый Шамил-Хөсәен – кырым татар шагыйре, Г.Тукай чордашы.*

*** ыргат – крестьян.*

гаиләсендә туып үсә. Авыл мәктәбендә бераз белем алганнан соң, белемен үзлегеннән арттыра, яшьли укытучылык итә башлый. 32 ел буенча туктаусыз халык укытучысы булы эшли. Ул чорның мәктәп дәреслекләрс һәм укыту методлары белән риза булмау аркасында, Туктаргазый әлифбаны, аерым хрестоматияләрне һәм башка дәреслекләрне үзе төзи, аларны, гектограф аша бастырып, башка мәктәпләргә дә тарата. Кайбер дәреслекләрне, балаларга рус телен тизрәк өйрәтү нияте белән, рус хәрефләре белән бастыра. Кырымда беренче булып татар һам рус телләрен аерым фән итеп укыта башлый. Үзе төзегән хрестоматияләргә үз шигырьләре, пьесалары белән бергә Тукайның аерым шигырьләрен, Пушкин әсәрләрен тәрҗемә итеп кертә. Туктаргазый: «Миңа Гаспринский тарафыннан төзелгән яисә Төркиядән китертелгән дәреслекләрнең һичберсе дә ошамыйлар, алар без, татарларның, хәзерге яшәү шартларына тулы җавап бирмиләр», – дип яза. Ул чорның яңа дәреслекләре нинди типта булырга тиешлеге турында уйланып язган мәкаләләрен «Шура» журналында да бастыра. Туктаргазый үзенең идея юнәлеше буенча Кырымда Карасубазарда Рәшит Мәһдиев редакторлыгында чыга торган демократик юнәлештәге «Ватан хадиме» газетасы ягында тора.

Рәшит Мәһдиев ул чор кырым татар интеллигенциясенең алдынгы вәкилләреннән берсе була. В.И. Ленин аның Думада ясаган бер чыгышына карата: «Кырым татарлары вәкиле депутат Мәһдиев (Таврида губернасы) кайнар революцион речендә «җирне һәм иреkне» яклап сөйли ... оратор безнең окраиналарда җиргә изге хосусый милекнең ничек килеп чыкканлыгын» ... башкорт җирләренең ничек урнашуын, министрларның һәм действительный статский советникларның, жандарм

идарәсе начальникларының 2-5 шәр мең дисәтинә җир алуларын күрсәтә», – дип яза (В.И. Ленин, 23 том, 405 бит).

Рәшит Мәһдиев белән фикердәш булган Шамил Туктаргазыйның аерым шигырьләре «Ватан хадиме»ндә дөнья күрә. 1910 елда «Һалеһи Кырым» исемле шигырьләр җыентыгы да Карасубазарда басылып чыга. Тукай кебек үк, Туктаргазый да революцион хәрәкәттә актив катнаша. 1905 елларда Керчьтә булган яһүд погромнарына каршы оештырылган эшчеләр демонстрациясендә ул да була. Социал-демократларның кушуы буенча, аерым революцион листовкаларны татар теленә тәрҗемә итеп халык арасында тарата. К.Маркснең, В.И. Ленинның аерым әсәрләрен һәм «Искра» газетасын укый. Ул үзенең революцион-демократик идеяләре һәм актив көрәше өчен, 1913 елда татар буржуазиясе тарафыннан Керчь ярымутравында Карҗебия авылында фаҗигале рәвештә үтерелә.

Күргәнебезчә, Россиянең өч почмагында яшәгән өч халык шагыйренең төп илһамчысы 1905 ел революциясе һәм ул елларда көчле рәвештә җәелеп киткән халык хәрәкәте була. Бу революцион ситуация ул шагыйрьләр иҗатының төп юнәлешен билгели. Аларның һәрберсе үз халкының әдәби мирасына, халык авыз иҗатына нигезләнеп иҗат итә башлый. Ләкин аларның өчесе дә революция барлыкка китерелгән яңа таләпләрдән чыгып, яңа эстетик карашлар, идеяләр, яңа әдәби тойгылар белән яши һәм көрәшәләр. Аларның һәркайсысы үз әдәбиятларында моңа кадәр булмаган, яисә була алмаган яңалыкларны кертәләр. Бу яктан алар – чын мәгънәсендә новаторлар, зур шагыйрьләр. Билгеле булганча, беренче рус революциясе әдәбият һәм сәнгать алдына моңарчы күрелмәгән яңа эстетик таләпләр куя. Революция кешеләрдә булган иң яхшы сыйфатларны уятты, аларда үз көчләренә ышанычны арттырды, хаклы

рәвештә горурлана белү дәртләрен уятты һәм җәмгыятьне яңадан үзгәртеп төзүгә чакыру кебек яңа эстетик идеяләр дәрте кузгатты.

Прогрессив әдәбиятның һәрвакытта да генераль юлы булган халык тормышын яңа бер тирәнлек һәм кискенлек белән көн тәртибенә китереп бастырды.

Революция таләпләре Россиядә яшәгән барлык халыклар әдәбиятында төрлечә яшәп килгән реализмның да характерын үзгәртә башлады, аның активлык сыйфатларын югары дәрәҗәгә күтәрде. М.Горький сүзләре белән әйткәндә, бу чорда «Тормыш сөючәнлек кыяфәте һаман үсә, киңәя, кешеләрдәге булган шатлыклар арта һәм кешеләрдә булган ышану сизелерлек дәрәҗәдә үсә» (Т. 28, 232 бит).

Моңа кадәр әдәбиятта булган реалистик агымнар бөек оптимистик рухлар белән сугарыла. Әдәбиятта батыр романтик пафослар яңгырый башлый. Прогрессив әдәбият дөньяның күләгә якларын актив фаш итүгә көчә, киләчәккә ышанычны арттыра.

Әдәбият алдына яңа темалар, яңа проблемалар килеп баса. Яңа образлар тудыру мәсьәләләре көн тәртибенә бөтен җитдилеге белән куела. Төп тема булып беренче рус революциясе идеяләрен җырлау, халыклар дуслыгын ныгыту, милли азатлык бурычларын тирән чагылдыру, буржуаз милләтчелеккә каршы көрәшне арттыру кебек милли темалар әдәбият алдына килеп басалар. Бу бөек темалар культура, мәгърифәтчелек, хатын-кызларны азат итү, дингә каршы көрәш кебек мөһим темаларны яңа формада үз эчләренә алалар. Боларның бөтенесе дә Тукай, Сабир һәм Туктаргазый иҗатларында революцион-демократик рухта чагылалар.

Аларның һәркайсы 1905 ел революциясен бик зур шатлык белән каршы ала, халыклар дуслыгы темасын төп

тема итеп сайлый. Билгеле булганча, рус самодержавиесе, революцион хәрәкәтне зәгыйфьләтү теләге белән ул чорда халыклар арасында милли дошманлыкны арттыру өчен барлык чараларны күрә. Шуңа күрә һәрбер халыкның революцион-демократик язучыларының төп темаларыннан берсе халыклар дуслыгын ныгыту, милли азатлык өчен барган көрәшне кочәйтү темасы булды.

Сабирның программ шигырьләреннән берсе булган, 1905 елда «Хәят» газетасында басылган «Бәйнелмиләл» («Интернационал») «Мөселман вә әрмән ватандашларыбызга» исемле шигыре очраклы бер хәл түгел, коннең актуаль темаларына язган бер шигырьдер.

Шагыйрь тирән бер хис белән үз халкына, әрмәннәргә, халыкларның иң алдынгы көчләреннән берсе булган шагыйрьләргә, әдипләргә мөрәҗәгать итеп:

*Ике иптәш, ике күрше – бер ватанның әвлады**
*Гасырларча тынычлыкта узды аларның гомердады***

*Мәлгунь иблис фетнәседер, дошманлыкка булды сәбәп.*
*Күрсен моны, бу начарлык наданлыктандыр һәп.*

*Асу-кисү, авыл-шәһәрләр була тарма-тар,*
*Әй шагыйрьләр, бу фетнәдән чыгу өчен кылың карар.*

Сабир бу шигырендә халыкара милли дуслыкка, кардәшлеккә дошман булган «Мәлгунь иблискә», ягъни рус самодержавиесенә каршы көрәшкә бердәм булып күтәрелергә чакыра. Бу гадел көрәшнең башында шагыйрьләр, әдипләр торуын сорый. 1905 ел революциясе бу халык шагыйрьләре алдына халыклар арасында интернациональ тәрбия мәсьәләсен һәм аны хәл итәргә

---

* *әвлады – баласы*
** *гомердады – гомер тәме*

тырышырга кирәклеген китереп куйды. Шуңа күрә дә бу бөек тема һәр өч шагыйрь иҗатында даими темалардан саналды.

Бу шагыйрьләрнең иҗатларында булган көч, куәт һәм гайрәт шундадыр ки, алар яңа эстетик идеал тирәнлегеннән чыгып, кешеләрдә булган иң яхшы кешелек сыйфатларын үстерү, ныгыту мәсьәләләрен һәм аларның үз көчләренә ышанып, көрәшкә бердәм булып күтәрелү теләкләрен җырладылар, ул көрәшнең өзлексез булуын чын күңелдән теләделәр.

Сабир, Тукай, Туктаргазый революцияне халыкара «яхшылык», «гомуми тигезлек», «барлык изелүчеләрнең бәтерелүенә китерүче», «кешеләргә – барлык халыкларга якынлык, дуслык китерүче» итеп җырладылар. Алар иске дөньяга ләгънәт укыдылар. Аның караңгы якларын фаш иттеләр.

Сабир:

*Бер яхшылык күрмәдек бу дөньяда,*
*Күрсәк идек яхшыны башка дөньяда*
*Бер уч хокук булса иде адәмдә.*
*Яшәсен ялкынлы галәүле хөррият!*
*Яшәсен мәңгегә яктылык хөррият!*

Туктаргазый исә 1905 ел революциясен котлап:

*Кеше углы без һәммәбез бер.*
*Тик шунысы бар кайберемез фәкыйрь,*
*Булмыйк байларга хакир*
*Кил, янагым, кил, янагым!*
*Балыкны ашаса балык,*
*Моны тәкъдир итә Халик**
*Кил, янагым, кил, янагым!*
*Телик без, хак бер булсын,*

---

**Халик – Алла*

*Бу юлга җан корбан булсын.*
*Кил, янагым, кил, янагым!*

Шул ук теманы халык шагыйре Тукай:

*Кайда китте цензуралык,*
*Коллык, тарлык һәм хурлык!*
*Артка карасак борылып,*
*Ерак алар калдыя,*
*Тигез булды законда*
*Татар, урыс, япон да;*
*Ак алъяпкыч, зипун да*
*Там азатлык алдыя.*

Бу шагыйрьләр бер тавыш белән революцияне котлаганнары кебек, бердәм рәвештә буржуаз парламентаризмның эчке йөзен фаш иттеләр. Моны аларның Дәүләт Думаларына карата язган шигырьләрендә, сатираларында бик ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, Сабир үзенең 1907 елда язылган «Мин әйткән кебек булып чыкмадымы?» дигән сатирасында, Тукай һәм Туктаргазый кебек, Дәүләт Думасының халыклар файдасына бер нәрсә дә хәл итмәвеннән көлә. Ул Бакудан киткән депутатка мөрәҗәгать итеп:

*Син түгел идеңме һәммә безне коткаручы Думадыр,*
*дип әйтүче?*
*Мин булмадыммы ул вакыт шик-шөбһәбез бардыр*
*дип әйтүче!*
*Әйт, син Баку депутаты, китмәдеңме булып*
*халыкны яклаучы! (...)*

Тукай һәм Сабир иҗатларының көчләре һәм әһәмиятләре шунда, алар беренче рус революциясенең халыкара әһәмиятен яхшы аңладылар. Бигрәк тә революциянең Көнчыгыш халыкларына ясаган уңай йогынтысын бөек рухлану белән җырладылар. Алар Манчжуриядә, (...)

Иранда һәм Төркиядә булган революцион хәрәкәтләр белән дә бик нык кызыксындылар, ул илләрдә булган революцион-демократик хәрәкәтләрне котладылар, реакцион көчләрне фаш иттеләр.

Тукайның бу темага язган шигырьләре кебек, Сабирның Ирандагы, Төркиядәге революцион һәм контрреволюцион хәрәкәтләргә багышлап язган көчле шигырьләре хәзерге көндә дә үз әһәмиятләрен югалтмадылар. Мәсәлән, Сабирның «Иран үземнекедер», «Сатирам», «Усманга инанма» кебек шигырьләре моның ачык мисалы булып торалар. Шагыйрь бу әсәрләрендә ул ил халыкларын уяулыкка, эчке һәм тышкы реакцион көчләргә каршы көрәшергә чакыра, революцион-демократик таләпләрне, милли бәйсезлек идеяләрен бер коч белән якларга чакыра.

Тукай, Сабир һәм Туктаргазый – үз әсәрләрендә революцион демократик рух, чын гражданлык идеяләрен чагылдыручы шагыйрьләр.

Алар революцияне һәрвакытта кешс сөючәнлек, гуманистик, гражданлык хисләреннән чыгып якладылар. Аларның иҗатларының көче шундадыр ки, алар һәртөрле изүләргә, кешеләрне хокуксыз итә торган һәртөрле формаларына каршы көрәштеләр.

1908 елда Сабир үзенең «Фисилҗан» (көнчыгыш халыклары яратып ашый торган бер милли аш исеме) шигырендә:

*Кем дә инсанны сөяр, ул хөррият ашкы булыр,*

*Хөррият булган җирдә исә инсанлык яхшы булыр, –*

дип җырлады. Менә моның кебек бөек гражданлык мотивлары алар иҗатында төп урын алып торалар. Бу шагыйрьләрнең иҗатларындагы саналып узган барлык уртаклыклар, охшашлыклар һәммәсе, беренче рус революциясе бу ялкынлы халык шагыйрьләренә көчле бер илһам

бирде. Алар эшче-крестьяннарның чиксез изелгәнлекләрен, ләкин һәрвакытта хакыйкать, дөреслек, җиңү тантанасы алар ягында булганлыгын һәм булачагын җырладылар.

Сабирның «Баку эшчеләренә», «Эшче, син дә үзеңне бер инсанмы хисаплыйсың?» һәм «Игенчеләр» кебек шигырьләрендә көрәшнең капиталистик дөньяның баш дошманы булган эшчеләрне экономик, политик, мораль яклардан изү-кысу өчен генә түгел, бәлки аның кешелек сыйфатларын бөтенләй бетерү өчен дә барганлыгы әйтелә.

Капиталистлар дөньясы өчен эшчеләр «кеше дә түгел» «инсан да түгел», чөнки аның «малы», «дәүләте», «байлыгы», «поны-акчасы» юк.

*Эшче, үзеңне син дә бер инсанмы санарсың?*
*Пулсыз кеше, инсанлыкны хасанмы санарсың?*
*Инсан булганның бөек бер сыйфаты булсын*
*Инсан булганның дәүләте, малы булсын.*
*Җимерек түгел, сарае, гүзәл йортлары булсын.*
*(хасан – яхшы бер сыйфат дип исәпләү)*

Бу шагыйрьләр революцион хәрәкәтнең үзәгендә, алдынгы сафларда эшчеләр сыйныфы булганлыгын ачык сизделәр һәм аның хәл итүче ролен аңларга омтылдылар. Бу хәл Сабирның 1906 елда язылган «Баку эшчеләренә» дигән шигырендә тагын да ачык күренә:

*Тәгәрмәч чартлады, кирегә әйләнер хәзер.*
*Эшче дә артык үзен кешегә санар хәзер.*
*Булмый бу эш, каплашсын һәр эшкә эшче*
*Дәүләте булган бер җирдә ни эшләсен эшче.*
*Иркенләп үзенчә сулыш алсын эшче*
*Яисә хокук өчен көрәш ачалсын эшче.*

Моның кебек идеяләр аның «Аристократик мотивлар» шигырендә тагын да көчлерәк яңгырыйлар.

Шул ук 1906 елда Шамил Туктаргазый, Сабир кебек, хокуксыз булуга һәм аның сәбәпләренә тукталып үзенең «Дөньяда ниләр бар?» шигырендә:

*Кайберәүләр тарта щенә,*
*Кайберәүләр тарта буена,*
*Кайберәүләр үз диненә,*
*Кайберләре сугыш мәйданына.*
*Һәммәсенең максаты шул:*
*Син казан бир есин ул**
*Кеме киер алтын таг,*
*Эш биргән тук? Эшче ач, –*
дип яза.

Бу шагыйрьләр эшчеләрнең көрәшләрендә гаделлек, җиңелмәс бер көч, гайрәт күрсәләр дә, кайвакытта алар эшчеләрнең тормыш шартларын яхшырту мәсьәләләренә һәм тигез хокуклы булуларына капиталистларның «мәрхәмәтләренә», «алланың кодрәтенә» дә кайтарып калдырдылар (...) Туктаргазый да, Сабир һәм аерым очракларда Тукай шикелле үк, ходайга мөрәҗәгать итә:

*Әй, ходаем, ник яраттың?*
*Халыкка каттың,*
*Соң оныттың!*

Моның кебек каршылыклар, кочсез яклар һичбер вакытта да гомум революцион демократик рухны киметмәделәр. Нигездә мондый хәлләр реалистик, раслаучы принциплардан чыгып язылган шигырьләрнең тарихи һәм әдәби әһәмиятләрен киметмиләр.

Сабир, Тукай һәм Туктаргазый шигырьләренең, гомумән, алар иҗатларының асыл әһәмиятләре шундадыр ки, аларның һәрберсе диярлек көннең актуаль, конкрет факт-

---

**есин ул – ашасын ул*

ларына, тарихи вакыйгаларга бәйле буларак язылганнар. Шуның өчен аларның иҗатларында бик катлаулы революцион чор, күп төрле политик, иҗтимагый, культура, мәгариф мәсьәләләре, гомумән, гаять әһәмиятләре булган гади көнкүреш мәсьәләләре художестволы бер формада чагылганнар. Өстән генә караганда, бу шагыйрьләр һәрвакытта берберләре белән фикерләшеп эш иткәннәр яисә үз әсәрләрен бергәләшеп иҗат иткәннәр кебек күренә. Чорның кайсы актуаль мәсьәләләрен алмагыз, аларның һәммәсе диярлек бер үк вакытта бу шагыйрьләр иҗатында куелган һәм алар бер үк формада хәл итәлергә тырышылган. Мәсәлән, югарыда китерелгән мисаллардан башка бу халык шагыйрьләренең милләтчеләргә, либераль буржуазиягә каршы язылган политик шигырьләренең, иҗтимагый тормышта поэзиянең, шагыйрьнең ролен аңлатуга карата язылган әсәрләрен күз алдына китерсәк, югарыда әйтелгән хәл тагын да ачыграк булып күз алдына килеп баса. Бу шагыйрьләр өчесе дә бердәм тавыш белән рус самодержавиесенә, аның колониаль политикасына каршы туктаусыз көрәш ачканнары кебек, көчле бер рәвештә җирле милләтчеләргә каршы да шундый ук көрәш ачтылар. Алар үз халыклары алдында милләтчеләрнең эчке йөзләрен ачып бирделәр.

Мәсәлән, Сабир үзенең 1906 елда язылган «Минем анда ни эшем бар?» дигән сатирасында тыштан «милләт файдасына», «халык файдасына» дип кайгырткан кешеләрнең, ягъни милләтчеләрнең, чын мәгънәсендә милләт һәм халык турысында түгел дә, үз файдалары өчен кайгыртканлыкларын фаш итә:

*Милләт нишә тараж* булса,*
*булсын минем ни эшем бар?*

---

* *тараж - хәсрәтле, кайгылы*

*Дошманнарга мохтаҗ булса, булсын,*
*минем ни эшем бар?*
*Акрын бул, ятканнар уяныр, барсы ятсыннар,*
*Мин һич рази түгел, ятканнарны уятсалар.*
*Әгәр уянганнар булса, тиз түшәккә ятсыннар.*
*Милләт ничә тараж булса, булсын*
*минем ни эшем бар?*
*Дошманнарга мохтаҗ булса, булсын,*
*минем ни эшем бар?*

Шул ук елны Шамил Туктаргазый бу темага кагылып, үзенең «Милләтчеләргә» дигән шигырендә:

*Алдыгыз да саттыгыз бу милләтне,*
*Кайсыгыз бай булды, булды таҗ?*
*Сез дә безнең кебек чиксез зилләтле*
*Бик беләбез сездә акча «нет» я «есть»*
*Әй ялганчылар, нидер бу илләте*
*Итте фетнәгә бу халыкны алт вә өст.*

Г.Тукай исә 1908 елда үзенең «Милләтчеләргә» дигән шигырендә шул ук политик теманы яктыртуда үз халкына мөрәҗәгать итеп:

*Милләтчеләр сезне фәкать алдый гына,*
*Дигән булып: җапланасың син тиз генә,*
*Алданма син, калган акчаң өчен алар*
*Укыйлар баш очында ясин гына, –*

дип чыга.

Һичшиксез, бу шигырьләрнең берсе дә бер-берләренең йогынтысы нәтиҗәсендә түгел, конкрет тарихи шартларның үзлегеннән чыгып, ул шагыйрьләр алдына килеп баскандыр. Иҗади юнәлешләрендә, дөньяга карашларында булган гомуми уртаклыклар бу күренгән гомумилекләрне китереп чыгарганнар.

Һичшиксез, алар бер-берләренең шигырьләрен укып, даими рәвештә таныш булып барганнар. Хәтта алар бер-берләренең шигырьләрен үз ана телләренә тәрҗемә иткәннәр***. Ләкин моның кебек аларның бер-берләреннән өйрәнеп яздылар дип әйтергә мөмкинчелек бирмиләр. Аларның һәр өчесе дә, әйтеп узганыбыз кебек, конкрет шартлардан, конкрет таләпләрдән чыгып язылганнар. Алар, башка шигырьләрендәге кебек, бу шигырьләрендә үз оригинальлыкларын саклаганнар. Бу хәл бөтен укучы өчен дә ачык күренеп тора.

Тукай, Сабир һәм Туктаргазый – һәркайсысы үз халкы арасыннан күтәрелгән шагыйрьләр. Шуңа күрә алар – үз халыкларының һәртөрле ихтыяҗларын, кирәкләрен иң тирәннән хис иткән кочле көрәнчеләр, бөек гражданнар.

В.И. Ленин фикерләре белән әйткәндә, Тукай, Сабир һәм Туктаргазый кебек кешеләр рус самодержавиесе тарафыннан дәүләткә каршы булган «куркыныч», «сөйкемсез», «өченче элементлар» яисә «өченче кешеләр» дип аталалар.

В.И. Ленин 1901 елда үзенең «Эчке күзәтү» дигән хезмәтендә «... Земствода врач, техник, статист, агроном, педагог һ.б. булып эшләүче мондый кешеләр санының һәм йогынтысының үсүе безнең реакционерларның игътибарын күптән инде үзенә тартып килә, алар бу сөйкемсез «Өченче кешеләргә» шулай ук «земство бюрократиясе» дигән кушаматны тактылар» (т. 5, 287 б.).

---

**** Мәсәлән, Г.Тукай Сабирның «Мулланың зары» шигырен тәрҗемә итә. Бу хакта азербайҗан галимнәреннән Азиз Мир Әхмәдовның «Тукайның Сабирдан бер тәрҗемәсе хакында» дигән мәкаләсе бар (Азербайҗан ССР Гыйлемләр академиясенең хәбәрләре, 1954 ел, № 5. Баку)*

Тукай, Сабир һәм Туктаргазый көчле революцион шагыйрь булулары ягыннан самодержавие өчен куркыныч кешеләр булган кебек, земство мәктәпләрендә эшләүче «өченче элементлар», «өченче кешеләр» булулары ягыннан да куркыныч иделәр. Сабир, Туктаргазый тик бер шагыйрь, әдип кенә түгел, ул чорның алдынгы мөгаллимнәре, укытучылары да иделәр. Тукай, турыдан-туры мәктәпләрдә укытмаса да, мәктәпләр өчен дәреслекләр әзерләү, ул чорның прогрессив мәктәпләре файдасына иткән хезмәтләре һәм мәгърифәтчелек идеяләре белән шул ук укытучылар сафында иде. Менә алар үзләренең бу якларыннан да һәм самодержавие, һәм реакцион милли буржуазия өчен, муллалар, динчеләр өчен дә бик куркынычлы иделәр.

Сабир Бакуның Балах районында укытучылык итә. Туктаргазый исә 16-17 яшеннән алып гомеренең азагына хәтле Кырымның төрле районнарында укыта. Ул мәктәпләр өчен 20 ләп дәреслек, әлифба, хрестоматия, тарих һәм әдәбият дәреслекләре төзи. Үзе төзегән бу дәреслекләрне гектографтан басып башка мәктәпләргә дә тарата. Ул бу дәреслекләренә үзе тарафыннан язылган шигырьләр, бер пәрдәлек пьесалар һ.б. лар белән беррәттән, Пушкинның аерым шигырьләрен дә татарчага тәрҗемә итеп кертә. «Шура» журналында «Татар мәктәпләре өчен нинди дәреслекләр кирәк» дигән дискуссиядә дә актив катнаша. Аның «Шура» журналында басылган мәкаләсе аеруча әһәмиятле.

В.И. Ленин әйткән кебек, бу типтагы «өченче кешеләр» сыйфатында йөртелүчеләр халыкның үз арасыннан күтәрелгәнлекләре һәм аларга бик якын торулары өчен реакцион буржуазия аркасында зур бер куркыныч иде.

В.И. Ленин бу типтагы интеллегенциядән файдаланырга теләктәшлек күрсәтергә кирәклеген әйтә.

«Россиядә бөтен халык арасында, аның барлык сыйфатлары арасында иҗтимагый кузгалу үсә, һәм безнең бурыч, революцион социал-демократларның бурычы, бөтен тырышлыгыбызны шул кузгалудан файдалануга, алдынгы эшче интеллегенциягә аның крестьяннар, студентлар арасында һәм гомумән интеллигенция арасында нинди союзниклар барлыгын аңларга, аны әле тегендә, әле монда кабына торган иҗтимагый протест утларыннан файдаланырга өйрәтүгә юнәлдерүдән гыйбарәт» (Ленин, Т. 5, 294 бит).

Социаль-демократларның бу бурычларны үтәү юлында Х.Ямашев кебек революцион марксистлар Тукай иҗатына бик уңай юнәлеш бирделәр. Аны тагын да көчлерәк көрәшкә рухландырдылар. Хөсәен Шамил Туктаргазыйның социал-демократлар тарафыннан төзелгән аерым революцион листовкаларны, прокламацияләрне русчадан татарчага тәрҗемә итү кебек эшләргә тартылуы да очраклы хәлләрдән түгел. Бу типтагы интеллегенциянең ул чорда уйнаган рольләре хәзергәчә тулысы белән өйрәнелмәгән.

***

Тукай, Сабир һәм Туктаргазый иҗатларының әһәмиятләре, югарыда әйтелгәнчә, яңа эстетик карашлар, яңа идеяләр тудыра белүдә. Мондый карашлар ике мәсьәләне хәл иткәндә, яктыртканда бик ачык күренеп тора.

Аның беренчесе шагыйрьнең һәм поэзиянең җәмгыятьтәге ролен, тоткан урынын билгеләгәндә, икенчесе исә заманның алдынгы кешеләре образларын, ягъни уңай образларны тудыруда булган көрәштә, омтылышта чагыла.

Бу шагыйрьләрнең өчесе дә, рус революцион демократлары Белинский, Чернышевский кебек, әдәбиятның, поэзиянең төп юлын билгеләгәндә аларның чын мәгънәсендә халык тормышы белән тыгыз бәйле булырга тиеш икәнлеген таләп итә. «Кайда тормыш, анда поэзия», «кайда дөреслек, анда иҗат көче» дигән лозунглардан чыгып, үз иҗатларын халыклар өчен тормыш дәреслеге итәргә тырыштылар. Алар бу мәсьәләләрне теоретик яктан бөтен тирәнлеге белән гыйльми рәвештә эшләп хәл итмәсәләр дә, иҗатлары белән аның болай булырга кирәклеген расладылар. Революция чорында, поэзия, революцион-демократик поэзия аеруча зур роль уйный. Бу чорда поэзия, әдәбият, гомумән, китаплар тик бер уку өчен генә түгел, «бәлки эш өчен, кешечә җанлы эш өчен, тарихи иҗат өчен кирәк» булалалр.

В.И. Ленин үзенең «Кадетларның җиңүе һәм эшчеләр партиясенең бурычлары» дигән хезмәтендә революцион бер чорда, кешеләргә акыл, фикер бирүдә бөек хәзинә булган китаплар укуның һәм аларның кирәклеген билгеләп: «... миллионнарча изелгән кешеләрнең аңы һәм фикере уянганда, китаплар уку өчен генә түгел, бәлки эш өен, кешечә җанлы эш өчен, тарихи иҗат өчен кирәк, алар кеше фикеренең һәм акылының юкка чыгуы турында кычкыралар», – ди (В.И. Ленин, Т. 10, 242 бит).

Мондый шартларда Тукай, Сабир, Туктаргазый поэзиясенең, әдәбиятның иҗтимагый тормышта, политик көрәштә актив роле барлыгын яклап чыгулары, аның алдына яңа бурычлар куюлары, һичшиксез, бөек бер новаторлык.

Тукайның «Аз гына русчадан» дип аталган «Китап» исемле шигыренең төп мәгънәсе китапның яңа бурычларны үтәү өчен кирәклеген раслауга багышланган.

*Җицеләям, максумланам мин шул чакта,*
*Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка.*
*Ышанычым арта минем үз-үземә,*
*Өмет белән карый башлыйм булачакка.*

Мондый шигырьләр хәзерге көндә, безнең чорда да үз әһәмиятләрен югалтмадылар. Алар киләчәкнең яңа кешеләрен тәрбияләп үстергән гаҗәп гүзәл булган чорда тагын да көчле яңгырыйлар. Бу шагыйрьләр һәрбер язган шигырьләрен халык файдасы өчен, җәмгыятьнең реакцион көчләренә каршы язганлыкларын һәрвакытта да ачык аңлап эш иттеләр. Төрле авырлыкларга, милли кысуларга, изүләргә карамастан, үз әсәрләрен халыкка җиткерү юлларын эзләделәр. Бу мәсьәләләрдә дә алар иҗатында бик охшашлык һәм уртаклыклар бар. Мәсәлән, Хөсәен Шамил Туктаргазый 1910 елда язган «Язмам артык» дигән шигырендә:

*Язмам артык, биздем артык язмадан!*
*Ни язсам да, яздыкларым җирдә калыр,*
*Мондый язу язуның ни фаркы булыр*
*Үзең өчен кошта мизар азмадан?*

Мондый мотивлар һич тә көрәштән, язудан кул тарту түгел, бәлки кара реакциягә каршы юнәйтелгән каты бер һөҗүм тавышы иде. Туктаргазый үз әсәрләренә матбугат таба алмаса да, һәрвакытта укучыларны тапты. Аларны гектографта басып, мәктәпләргә, халык арасына таратты. Аның шигырьләре Тукай шигырьләре белән беррәттән халык арасында кулдан-кулга, авыздан-авызга күчеп йөрделәр.

Бар көчләре, әдәби талантлары белән реалистик нигездә торган бу шагыйрьләр поэзия алдына һәрвакытта дөреслекне язу, начарлыкны – тормышның күләгә якларын фаш итү, киләчәккә бөек бер өмет саклау идеалларын яздылар.

Сабир 1909 елда «Юк, язмыйм» дигән шигырендә:

*Язганыма ялан-фәлән кайтмыймын,*
*Ишан кебек рушвәт полга сатмыймын.*
*Дәүләтләргә ялтаклану белмимен,*
*Гамьлы булган ялган җирдә көлмимен,* -

дип җырлады.

Бу шагыйрьләр чын мәгънәсе белән халык шагыйрьләре булып халыкка хезмәт итүләре белән горурландылар. Аларга илһам бирүче төп көч – халык, аларның якты киләчәге өчен алып барган гадел көрәш булды.

Сабир, Тукай һәм Туктаргазый кебек үк, үзенең халык шагыйре булуы, халкына, ватанына хезмәт итүе белән горурланып:

*Әлбәттә! Мин шагыйрь,*
*мин бурычлы ил турында язарга!*
*Һәм начарлык, һәм яхшылык турысында язарга!* -

ди.

Икенче бер шигырендә:

*«Шакшыны шакшы, яхшыны, яхшы, дип яз!»* -

ди ...

*Фисәдчене мактама, тартын аның фисәденнән!*
*Булырмы алчаклык, начарлыкны яхшы*
*дип мактаудан!*

Сабирның мондый шигырь юллары Тукайның 1906 елда язган «И каләм» шигырендәге төп идея итеп куелган дөреслекне җырлау шагыйрь иҗатының баш бурычы икәнлеген ачык әйтү белән аваздаш. Тыштан карaганда гына, алар башка темаларны яктырткан кебек, бу мәсьәләдә дә турыдан-туры бер-берләрен кабатлаган кебек күренәләр. Күреп узганыбыз кебек, Сабир «Шакшыны шакшы, яхшыны яхшы, дип яз!» дигән булса, Тукай үзенең «И каләм» шигырендә:

*Караны яз кара дип һәм игътираф ит акны ак,*
*Җөпне җөп дип язмалый сән һәм ышандык такны так.*

*...*

*Бакма һич кәс хәтеренә, милләтнең дәртенә бак!*
*Бәддога-явыз догая һәр заман асма колак.*
*И каләм, синнән көлер һәм бәхетемез, икъбалемез,*
*Бәкләнер дүрт күз илә лотфында истикъбалемез.*

Шамил Туктаргазый:

*Шагыйрь булсаң, һәрвакытта яз дөреслекне*
*Булмагандай макта, дустым, җирне-күкне*
*Сөйләмә син һичбер вакыт ялан-фалан,*
*Шагыйрь түгел ялганнардан илһам алан.*

Бу шагыйрьләрнең һәр өчесе дә революцион – демократик позициядә торып, әдәбиятның реалистик нигездә үсүе өчен кискен көрәш алып бардылар. Шул ук вакытта алар әдәбиятны тормыштан, халык тормышыннан аеру өчен тырышып, реакцион көчләрнең куәтле икәнлеген дә бертавыштан ачык итеп әйтә белделәр. Ш.Туктаргазый үзенең 1909 елда язган «Сәрләүхасыз» дигән шигырендә:

*Бу дөньяда иң кадерле нәрсә булса, ул хакыйкатьтыр,*
*Калган барлык сөйләнүләр тик ялгандыр,*
*хорафәттер.*
*Димә, Шамил, димә болай!*
*Һәркем кебек сөйлә ялган,*
*Бу заманның хакыйкате сатирлә зелләттер.*
*Гафу кылың, укучылар, бу сүз өчен сезләр мине,*
*Мин бик беләм, һәр төшенчәне язып*
*куймак кабәхәттер.*

Шагыйрь – халкы, ватаны өчен иң актив көрәшүче, сугыш уты фронтының иң алдынгы сафларында баручы дигән бөек идея, якты идеал һәрвакытта бу шагыйрьләрнең төп диварлары булды.

Сабир:

*Мин шагыйрь! Чөнки вазифам будыр: шигырьләр язам*
*Күргәменә бәдигый кылып захарлар язам.*
*Куркам, ни өчен дисәгез, кисәрсез телемне*
*Мин шагыйрь –*
*Мин сөям дөреслекне, халыкны, илемне.*

Тукай, Сабир һәм Туктаргазый беренче рус революциясе, гомуми әдәби җанлану, культура революциясе елларында тормышка бер төркем модалы язучылар барлыкка килгәнлеген әйтмичә һәм аларга кискен көрәш ачмыйча кала алмадылар. Мондый язучыларны «гади такмакчы», әдипләкне югалтучылар дип тә карадылар. Мәсәлән, Тукайның ул чорда язылган «Мөтәшагыйрьгә» дигән шигыренә каршы язылган аерым шигырьләр, матбугатта бу юнәлештә булган аерым фикерләр моны ачык күрсәтеп торалар. Мондый хәлләрне, һөҗүмнәрне тик бер Тукайга карата түгел, Сабирга һәм Туктаргазыйга карата да булганлыгын күрсәтергә мөмкин. Моның кебек хәлләр үз вакытында Сабир, Тукай һәм Туктаргазый хакында «алар шагыйрьме, түгелме» дигән сорау куючыларны да барлыкка китерми калмады. Бу шагыйрьләр чын халык шагыйрьләре буларак, шигърият дөньясын бозучыларга, халык тормышы белән бер дә бәйләнеше булмыйча, гомуми «гүзәл сүзләр», буш җөмләләр белән тутырылган әдәби әсәрләргә каршы ачык көрәштеләр. Мәсәлән, Тукай: «Һөнәр күп җиһанда, син дә моннан башка сәнгать тап», – дигән булса, Сабир һәм Туктаргазый үз шигырьләрендә «Синең майгаең ай», «Кашларың ай», «Йөзең кояш» «Керфекләрең ук», «Иреннәрең бал», «Битләрең нар» кебек охшатулар, эпитетлар һәм метафоралар белән шигырьләр язып, үзләрен шагыйрь дип атаучы ялгансандугачлардан ачы рәвештә көлде. Моны Сабирның

«Шагыйрьләр белән серләшү» дигән шигырендә һ.б. да күрергә мөмкин.

Бу шагыйрьләрнең иҗатларында поэзиянең һәм шигърияттнең иҗтимагый тормышта уйнаган роле – аеруча өйрәнүне сораган бер тема. Бу теманың махсус тикшерелүе безнең бүгенге поэзия бурычларын тагын да ачыкларга хезмәт итәчәк.

***

Бу шагыйрьләрнең иҗатында яңа кешеләр образларының чагылышы һәм бу мәсьәләнең куелышы аеруча бер дикъкаткә ия. Бу шагыйрьләр, югарыда әйткәнебезчә, революцион чорның яңа тип көчле кешеләре, бөек рухлы ватанпәрвәрләр, халыклар дуслыгын ныгытучылар, дини хорафатларга каршы аяусыз рәвештә көрәш алып баручылар. Алар фәнни нигезләргә таянып эш итүче, белемле замана кешеләре кирәклеген тойдылар. Җәмгыятьне үзгәртеп төзү юлларын эзләделәр. Тулы мәгънәсе белән бөек гуманистлар булган бу шагыйрьләр бар көчләре белән кешеләрнең, хезмәт ияләренең җиңелмәс куәтенә чын күңелләре белән ышандылар.

Сабир үзенең философик шигъри юлларында:

*Кешеләр әмәле таулар куптарыр,*
*Кеше бул, таулар куптар, әһәмият кыл,*
*Ватан угрында. милләт гыйшкына, –*
ди.

Тукай исә «Үз үземә» дигән шигырендә халкына булган мәхәббәт дәрәҗәсенең бөеклеген әйтеп, чиксез гали инсан булырга һәм туктаусыз үсәргә теләгәнен җырлый:

*Телим булырга инсанә гали,*
*Тели күңлем тәгали биттәвали.*

Бөеклек Тукайга шәхес даны өчен түгел, халкына лаеклы, тугрылыклы хезмәт итә белү өчен кирәк:

*Татар бәхете өчен мин җан атармын:*

*Татар бит мин, үзем дә чын татармын.*

Тукай, чын милли татар шагыйре булу белән бергә, бөек интернационалист, ул, Сабир һәм Туктаргазый кебек үк, үз халкының бәхетен, хәятен башка халыклардан аерып алып карамады һәм аларны башкаларга каршы да куймады. Билгеле булганча, Тукай «Хөр Россия» өчен көрәште. Үз халкын рус халкы һәм башка халыклар белән дуслыкка чакырды. Аның:

*Рус белән тормыш кичердек сайрашып.*

*Тел, логать, гадәт вә әхлак алмашып...*

*Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?*

кебек юллары хәзерге шартларда да аеруча яңа бер көч белән яңгырыйлар. Рус халкы белән дуслык темасы Туктаргазый һәм Сабир иҗатларында да төп темалардан булды. Сабир, рус әдәбиятын, рус культурасын тирәннән үзләштерү максаты белән, 40 яшенә җиткәндә рус телен өйрәнде. Аны яхшы белүе аркасында Крыловның аерым мәсәлләрен үз ана теленә тәрҗемә итте. Пушкин, Лермонтов кебек шагыйрьләр аның даими яратып укыган шагыйрьләре булдылар. Туктаргазый Тукай кебек яшьтән рус телен яхшы үзләштерүе аркасында татар балаларына мәктәпләрдә ана теле белән беррәттән рус теле дә укытты. Ул балалар өчен язган шигырьләрендә балаларга мөрәҗәгать итеп:

*Соң сүзем шулдыр сиңа:*
*Руслар белән бер хуш яшә.*
*Мәктәпкә кит, русча укы,*
*Китмәсен гомерең буша*.*

* *буша – бушка*

Башка бер шигырендә:

*Укыган балаларны сәвәм,*
*Димәм бу рус яки татар.*

Моның кебек мотивлар тагын да ачык буларак аның 1911 елда язылган «Сәгъдәт утравы» исемле романында күренә. Романның баш герое яшь егет Диләвер халкына мөрәҗәгать итеп: «Гыйлем вә фәнне өйрәнмәгәннәр, рус телен өйрәнмәгә чалышыгыз, тырышыгыз, ватандашларыгъыз булган руслардан һичбер вакыт ераклашмагыз, киресенчә, алар белән дус яшәгез. Алар белән якынлашыгыз, аларда булган гыйлем, фән вә тәҗрибәдән гыйбрәт алмага гайрәт итегез. Болар арасында күрәчәгегез файда бик бөектер. Бөтен көч бу дуслыкта, бу якынлыктадыр» (...)

Туктаргазый Пушкин, Лермонтов иҗатларына зур хөрмәт белән карады. Аларны үз әдәби остазлары, укытучылары дип таныды. Үзенең бик күп шигырьләрен аларга ияреп язды. Ул Пушкинның «Балыкчы карт һәм балык турысында хикәят» кебек гүзәл әсәрен ирекле тәрҗемә итте. Моннан башка Пушкинның Кырым темасына багышланган шигырьләрен дә татарчага тәрҗемә итте. Туктаргазый Пушкинның Кырым белән бәйле булган иҗатын аеруча яратты. Ул үзенең «Кырым моңнары» дигән шигырендә «Бөек Пушкин гашыйк иде Кырымга» дип җырлады. Туктаргазыйның «Ай-Петри хатирәсе» кебек шигырьләре бөек Пушкинның Кырым табигатенең гүзәллегенә багышлап язылган шигырьләре йогынтысында иҗат ителгәннәр. Мәсәлән, бу шигырьдә Пушкинның:

*Погасло дневное светило;*
*На море синее вечерний пал туман.*
*Шуми, шуми, послушное ветрило,*
*Волнуйся подо мной, угрюмый океан.*
*Я вижу берег отдаленный,*
*С волнением и тоской туда стремлюся я, –*

дип башланып киткән «Элегия»сенең йогынтысы бик ачык күренеп тора.

Туктаргазый:

*Томан ташларга саргылган, ара тантымы очачак,*
*Һаман юк «Сырт» җиленнән,*
*мондый хәлдә ничек качачак!*
*Килдем мин диңгез кырыеннан,*
*болганалар күзем алдында*
*Утырдык без бераз, ләкин өмет юк һич ачылачак.*
*Баш өстендә сәма саф, аягың астында диңгез.*
*Ай-Петригә чыксаң әгәр ашфитегез, мөфтәдәгез*.*
*Шик юк, үз-үзен кулга алыр, хисият белән*
*Диерсең шунда «ишнә дөнья» бак,*
*ни гүзәл диңләсәгез.*

Туктаргазый Пушкинның Кырым гүзәллекләренә, татар хаятенә багышланып язылган башка шигырьләрен дә ирекле тәрҗемә итеп, үзенең дәфтәренә керткән. Балаларга рус телен тизрәк өйрәтү нияте белән Пушкин шигырьләренең русча текстларын да керткән. Мәсәлән, Пушкинның «Желание» шигыреннән түбәндәге юлларын:

*Я помню гор высокие вершины,*
*И беглых вод веселые струи,*
*И тень, и шум, и красные долины.*
*Где бедные простых татар семьи*
*Среди забот и с дружбою взаимной*
*Под кровлею живут гостеприимной.*

Шагыйрь түбәндәгечә тәрҗемә итеп бирә:

*Исемдәдер бер-береннән биек таулар,*
*Ашкынып шатлык белән аккан сулар.*
*Гүзәл күләгә, су шаулавы бу җирләрдә,*

* *хәсрәтегез, кайгыгыз, эч пошуыгыз бетәр.*

*Тирән һәйҗан тудыралар алар синдә.*
*Гомер итә фәкыйрь татар гаиләләре*
*Дусча үтә бу халыкларның көн-төннәре.*
*Сөендерә мин шагыйрьне мондый гомер*
*Булдым инде гади халыкта күп мосафир.*
*Кунак сөйгән фәкыйрь татар гаиләләре*
*Эш белән мәшгуль чүл-бакчада көн-төннәре.*

Дүрт мисрагъдан артып киткән бу тәрҗемәдә Туктаргазый Пушкин тарафыннан үз халкына бирелгән дөрес характеристиканың төп мәгънәсен тагын да ачыклар өчен, халыкның башка халыклар кебек эш-хезмәт сөючән, нигездә кырчылык, бакчачылык белән мәшгуль булганнарын өстәп бирә. Туктаргазый, Тукай һәм Сабир кебек үк, Лермонтов иҗатыннан да өйрәнеп эш итте. Пушкин һәм Лермонтов кебек олы шагыйрьләр Туктаргазыйны да политик һәм философик фикер йөртә белүгә өйрәттеләр. Бу шагыйрьләр аңа сүз белән күп фикерләр әйтү кирәклеген Тукай, Сабир һәм Туктаргазый үз иҗатларында Пушкин, Лермонтов кебек үк шәхес иреклеген төп тема итеп җырладылар. Бу мәсьәләдә алардан өйрәнергә тырыштылар. Мәсәлән, Туктаргазый үзенең бу темага багышлап язылган «Мәгъдәният» шигырендә:

*Мәгъдәният, бәхетлесеңез, күз алдында сез.*
*Ни үлемдән куркыңыз бар, ни хокүмәттән сезнең!*
*Гәрчә, кайбер хәлдә сез дә без кебек бар бәндәсез,*
*Ләкин куркыңыз булынмас һич тә, зәхмәттән сезнең!*
*Ни эсседән куркыңыз бар, ни суыктан мин кебек,*
*Хөкүме үтмәс ачлыкның мәгъдәннәргә инсан кебек*
*Хиссез булсам мин, бәхетле санар идем мәгъдән кебек*
*Һич кызармас йөзләрегезгә бер һаҗәрәттән сезнең.*

Мондый чагыштырулар, табигать һәм мәгъдәнләр белән параллель рәвештә кеше шәхесен куеп тирән

фикерләр әйтүләр үз-үзлегеннән Лермонтовның шул юлларын искә төшерәләр:

*Нет, вам наскучили нивы бесплодные,*
*Чужды вам страстность и чужды страдания:*
*Вечно – холодные, вечно – свободные,*
*Нет у вас родины, нет вам изгнания.*

Тукай әйткәнчә, бу шагыйрьләр Пушкин белән Лермонтовтан үрнәк алып, акрын гына югарыга үрләп баралар. Шуңа күрә дә аларга рус культурасы, рус әдәбияты, аның революцион рухы һәрвакытта да якын булып тоелды, туктаусыз көрәшкә рухландырды. Әгәр дә Тукай, Пушкин шикелле, «Яшәсен иркен акыл!», «Яшәсен тугры караш!», «Яшәсен мәңгегә кояш!» кебек зур мәгънәле лозунглар куйган һәм үзенең «Өмет» шигырендә:

*Чыкчы, и фикерем кояшы!*
*Китсен өстеңнән болыт,*
*Бу үлек вөҗданы җанландыр,*
*җылың берлән җылыт! –*

дип җырлаган булса, башка бер шигъри юлларында «караңгылыкка», «җиңел уйларга» һөҗүм ясап:

*Җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр,*
*сезгә мең ләгъ нәт, –*
*Яшә тугры караш, төпле акыл,*
*мең нәр яшә хезмәт! –*

дип чакырды. Тукайның каләмдәше булган Туктаргазый 1910 елда язган «Караңгылык» шигырендә Тукай кебек үк, караңгылыкка, җиңел акыллылыкка каршы һөҗүм итә:

*Әй, халыкның арасыннан тартыл!*
*Һәммәсе бозылды куркыннан, тартыл!*
*Теләсәң, якты да без йокларбыз*
*Биргән йокың һич кирәкми!*

*Йокыңа лəгънəт синең һəм үзеңə!*
*Бахтиярбыз, мохтаҗ булсак йөзеңə!*
*Без телибез айдынлык һəм зыя!*
*Йокы яхшы булса, булсын күзеңə!*

Моның кебек көчле философик-политик шигырьлəрдə чын мəгънəсе белəн яңа тип революцион-демократик шагыйрьлəрнең лирик образлары бирелгəн. Бу шагыйрьлəр килəчəкнең якты фикерле чын шəхеслəрен социаль-демократлардан күрергə тырыштылар. Моның ачык мисалын Тукайның «Хөрмəтле Хөсəен ядкəре» шигырендə ачык күргəнебез кебек, аның элементларын Сабирның «Ата нəсихəте» кебек шигырьлəрендə очратырга мөмкин. Сабир 1906 елда язылган бу шигырендə алдынгы фикерле демократик яшьлəрдə университетларга керү һəм социаль-демократларга теләктәшлек күрсәтергə тырышу омтылышы булганлыгы əйтелə, мондый яшьлəрнең реакцион көчлəргə, дин башлыкларына каршы көрəшергə тиешлеклəре тəгаенлəнə:

*Күптер адəм өчен гыйлем укымакның зарары,*
*син хисапла, мин əйтəем:*
*Башта шул мəктəптə ач булып тамагың,*
*əй күземнең нуры,*
*Бер дə күз нурың сүнеп, сукыр калачаксың,*
*җаның да сау булмас,*
*Төсең саргаер, сулар яңагың, йөрəгеңдə көч калмас.*
*Ахырда, исəн калып университетка киттең,*
*коткардың үз-үзеңне*
*Инсаф ит, əйт бу эшне яхшымы иттең?*
*Инде тор бу сүзеңдə!*
*(...) син дə диячəксең социалмын, яки демократ.*

Шагыйрь реакцион көчлəрнең моның кебек яшьлəрне яңа хəят төзүчелəр түгел, бəлки хəятне бозучылар, динне, милли гадəтлəрне җимерүчелəр итеп күрсəткəнлеклəрен

фаш итте. Күргәнебезчә, Сабир социаль-демократларга теләктәшлек күрсәткән яңа кешеләр – киләчәкнең яңа бер типлары дигән фикерне әйтергә омтылса, Тукай үзенең «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре» шигырендә мондый фикерләрне ачык игеп бирә, аның төп сыйфатларын тасвирларга тырыша. Тукай өчен замана һәм киләчәкнең иң яхшы сыйфатларын үзенә туплаган социал-демократ вәкилләре «җиңелмәс көч белән бергә гүзәлләрне үзләренә җыйган» кешеләр булып торалар.

*Әүлияләрнең барын бер-бер китерсәм каршыма,*
*Күрмәмен, дип уйлымын бер якты йөз ул йөз кеби.*
*Ул көрәште язда елмайган кояш төсле бәлә́нд:*
*Карны – бозны ул ничек эретә, колеп һәм нур коеп.*

Тукай, Сабир һәм Туктаргазый шигырьләрендә бирелгән заманның һәм киләчәкнең лирик яңа кеше образлары дингә, дин башлыкларына, капиталистик дөньяда кешеләрнең кешелек сыйфатларын җимерүче акчага, байлыкка аяусыз рәвештә һөҗүм итүче, шәхес иркенлеген, халыклар дуслыгын бар тавыш белән җырлаучы, көчле хисләргә бай бер образ булып гәүдәләнәләр. Тукай надан муллалардан, дин башлыкларыннан көчле ачу белән көлеп:

*Кибән чалма кибәк башта:*
*ишан булган, имеш, хайван!*
*Күзен йомган, муен бөккән,*
*башында чалма чорналган, –*

дип тасвирлаган булса, Сабир:

*Бичара, язык башы гөнаһы тулы мулла,*
*Инкарь итмә, расла гөман юлына мулла, –*

дип җырлый.

Туктаргазый:

*Халыкның авызына агуны, бал дип сөртер иде,*
*Көндә мең кысыр итәр дә, дин белән үртәр иде. –*

кебек шигъри юллары белән динче, кадимче муллалардан ачулы рәвештә көлә, аларны фаш итә. Бу шагыйрьләр капиталистик дөньяда кешеләрнең кешелек сыйфатларын җимерүче «акча, байлык» икәнлеген җырлаганда да бер-берләре белән киңәшеп язган шикелле эш итәләр. Мәсәлән, Сабир:

*Адәмне адәм иткән парадыр*
*Парасыз адәмнең йөзе карадыр.*

Туктаргазый:

*Бу дөньяда һәммә нәрсә пара**
*Баш та пара, соң бәхет ара*
*Рәхәт теләсәң, пара*
*Кирәк пара, пара, пара.*
*Ятсаң, пара, торсаң пара*
*Торсаң пара, үлсәң пара.*
*Кирәк пара, пара, –*

дип җырлады.

Тукай исә:

*Акча барда, бар да дус шул, бар да яр;*
*Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр! –*

дип акчага, байлыкка каршы һөҗүм итте. Шагыйрьләр иҗатында мондый охшашлыкларны, уртаклыкларны бик күп китерергә мөмкин. Ләкин безнең төп максат аларны табу яисә гади рәвештә аларны санап чыгу, аларның бер-берләреннән өстенлекләрен, яисә кимчелекләрен күрсәтеп үтүдә дә түгел. Безнең максат бу охшашлыклар, уртаклыкларның төп сәбәпләрен бераз гына булса да тулырак ачыклаудан гыйбарәт.

Югарыда әйтелгәнчә, бу шагыйрьләр иҗатындагы уртаклыкларның башлыча өч төп сәбәбе бар: аларның

---

** пара – (акча)*

беренчесе, иҗтимагый тормыш шартларының гомуми уртаклыгы һәм беренче рус революциясенең Россиядәге барлык халыклар алдына куйган төп бурычларында һәм аның характерында.

Икенчесе: бу өч шагыйрьнең бер үк культура, әдәби мирастан файдаланып эш итүләрендә, аларның бердәй эстетик карашларда, эстетик идеалларында һәм дөньяга карашларының бертигез булуында.

Билгеле булганча, аларның өчесе дә революцион-демократик караштa торган, үз халыкларының әдәби мирасларыннан оста файдаланган шагыйрьләр.

Тукай да, Сабир да, Туктаргазый да башлыча, рус классик әдәбиятыннан, Пушкин, Лермонтов, Крылов кебек иҗат ияләреннән һәм рус теле аркылы Европаның бөек классиклары Байроннан, Гейнедан, Шиллердан һәм Шекспирдан файдаланып эш иткәннәр. Бу мәсьәләдә алар арасында беренче урынны, һичшиксез, Тукай тоткан. Сабир һәм Туктаргазый исә югарыда исемнәре аталган Европа классиклары иҗатлары белән Тукай тәрҗемәләре аркылы гына таныша алганнар. Тукай, рус һәм Европа классикларын гүзәл тәрҗемә итә белү аркасында, көнчыгыш халыклары өчен дә бик мөһим эш башкарды. Моны җентекләп өйрәнү – хәзерге әдәбият белеменең төп бурычларыннан берсе. Шуның белән бергә бу өч шагыйрь Көнчыгышның бөек шагыйрьләре Сәгъди, Гомәр Хайям, Фирдәүси, Хафиз, Нәваи, Низами, Физули һәм башкаларның иҗатларыннан өйрәнеп эш иткәннәр, бала чакларыннан ук аларны оригиналдан укып үскәннәр, шуларның әсәрләре белән тәрбияләнгәннәр.

Өченчедән, бу өч шагыйрь бер-берсенең иҗаты белән якыннан таныш булганнар, матбугат аркылы даими рәвештә каләмдәшләренең иҗади эшчәнлекләрен күзәтеп

барганнар. Менә шушы өч төп сәбәп алар иҗат итүче тема, идея, стиль, эстетик караш һәм эстетик идеаллар уртаклыгын барлыкка китергән һәм охшашлыкларын тудырган.

Шул ук өч сәбәп һәрберләренә хас булган милли үзенчәлекләрне сакларга да мөмкинлек калдырган. Тукай да, Сабир да, Туктаргазый да – үз милли үзенчәлекләренә ия булган, милли халык шагыйрьләре. Аларның әдәби осталыгы бүгенгә чаклы тирән өйрәнелмәгән, бу мәсьәләне тикшерү тагын да күп проблемаларны хәл итәчәк.

Һичшиксез, мондый чагыштыру, әдәби каршылыклы элемтәләрне өйрәнү, безнең әдәбият белемен тагын да баетачак. Мондый тикшеренүләр дөнья өчен әһәмиятле булган беренче рус революциясенең, шул җөмләдән, русның прогрессив культурасының йогынтысында Россиядә яшәгән барлык халыкларның әдәбияты ничек итеп гомуми кешелек әдәбиятына – дөнья әдәбиятына аралашып киткәнлеген ачуга мөмкинлекләр тудыра.

Югарыда әйткәнебезчә, мондый тикшеренүләр бүгенге көндә күп милләтле совет социалистик әдәбиятыбыз үсешендә булган уртаклыклар һәм каршылыклы әдәби йогынтыларны да тулырак, ныграк өйрәнүгә юл ачачак.

Шамил Туктаргазый матбугатта чыккан һәрбер шигырьне диярлек үзенең кусн дәфтәренә күчерә барган. Мәктәпләр өчен үзе язган дәреслекләргә Тукай шигырьләрен тәрҗемә итеп керткән. Мәсәлән, «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Туган тел» һ.б.

## ТУКАЙ – ШИГЪРИЯТ ЙОЛДЫЗЫ УЛ

Сөекле Габдулла Тукай яшьлегеннән үк киләчәккә карый белгән, киң маңгайлы, шомырт кара чәчле, уйчан күзле, тәмле сүзле булган. Үзенең тәмле сүзләре, акыллы карашлары белән кешеләргә ярагаи бу бала, ата-анасыннан ятим калган.

Кырым татарлары, «Үксез үлмәс, газапланып көн күрер», дигәннәр. шуның шикелле Тукай да үлмәгән. Тик газапланып көн күргән. Аның күргәннәре иң авыр, иң мәшәкатьле көннәр булган. Шуңар күрә, «ятимнең күргәнен күрергә насыйп итмәсен» дигәннәр бабайлар. Ул ятимлектә җәфаланган, сыкранган. Башка балаларны әти-әниләре: «Балам-балам бал татыр, ташкан суны тук-татыр», дип яратканда, нәни Тукай, кем белән ничек моңайган, ничек аһлангандыр ... Әти-әни кочагын сагынгандыр, ләкин бу бәхет аңа иреммәгән. Ятим-ятим булып, газапланып үскән. Ялгызлыкта, ятимлектә эче пошкан бу баланың йөрәге җыр белән, тәмле шигырьләр белән тулган. Ул бала чагында ук, һәрбер кайгы-хәсрәткә җавап бирә белгән. Тормыш үзе аннан җыр сораган, җырлар исә, йөрәккә сыймыйча ташый барганнар. Алар үзләренә киң далалар, җылы йөрәкләр эзләгәннәр.

Шулай итеп, аның кадерле җырлары моңарчы ялгыз булган киң Иделгә көндәш булып киткәннәр. Идел шикелле тынып агарга яратканнар, Идел белән ярыша-ярыша арт-

каннар, ташыганнар. Алар тирә-якка дулкынланып җәелеп киткәннәр.

Идел үз юлы белән боргалана-боргалана һаман аккан, су аккан – ком калган. Ләкин, вакыт узган саен, Тукай ныгая барган, ул үскән. Аның җырлары да ныгайган, дулкыннары да көчәйгән.

Бу җырлар баштарак Кырлай авылының кырларында, кue карурманнарының яшел үләнле тугайларында тамчы булып тама башлаганнар.

Дөньяда бик сирәк, кадерле булган бу тамчылар, тама-тама күл булганнар. Күл киңәйгән – киң булган. Ул Кырлай кырларына, матур урманнарга сыймаган, авылларга, шәһәрләргә җәелгән.

Мәңге җуелмаслык булып, дулкынлана-дулкынлана Идел буена, «Тукай» дигән дан киткән. Ул китә-китә, моңлы сазы белән еракларга барып житкән.

Җыр яраткан халкы үз шагыйренең җырларында, үз моңнарында, үз хисләрен тапкан. Бик яшьләй тормыш тәмен белгән, нечкә күңелле, көчле Тукай, үз халкының моңыннан моң алган, гүзәл хисләр җыйган. Шулай итеп, халык рухы аның чишмәсе булып киткән. Шуңа күрә дә ул, халыкның үз җырчысы булып танылган. Ул юкка гына җырламаган. Җырлаганда «... Җырларымнан файда бармы халкыма?» дип сораган, халык өчен җырлаган.

Халык аңар кул изәп, кочак киереп, көр тавыш белән:

*Җырла, Тукай, җырчыбыз бит син безнең,*
*Һәрбересе мең алтынга тиң сүзең, –*

дигән. Шулай итеп Тукай халыкның бер сүзен мең алтынга торган җыр хәзинәсенә әйләндергән.

Тавыш-тынсыз тынып аккан Идел буе туфраклары халык җырларын үз бәгыренә сеңдергән. Ана туфракка

сеңгән бу җырлар язгы кояшлар аша пар булып күкләргә күтәрелгән. Җылы яңгырлар белән яңгыр булып та яуганнар. Күп чәчәкләргә, күп күлләргә шифа булган татлы хисләр яудырганнар.

Шулай итеп, Тукай җырлары, Татарстан дигән матур илнең күгенә һәм җиренә сеңгән. Миллионнарча татар балаларының бишекләре Тукай җырлары белән тирбәтелгән. Матур кызлар чын мәхәббәт хисләрен аның җырлары аша сизгәннәр. Шириннәр вә Ләйләләр шикелле, җырга мәхәббәт баглап, Тукай җырларына көйләр чыгарганнар.

«Җирнең колагы бар», дигән картлар, шуның шикелле, җыр яраткан Урал таулары да Тукайның тавышын ишеткәннәр. Алар Тукай җырларын үзләренә чакырганнар. Үрмәләп һаман югарыга үсәргә яраткан бу җырлар, Урал тауларына да менеп җиткәннәр. Татар эшчеләренең күңелләренә ошаган бу җырлар, бәхетле тормышка чакырганнар. Матур җырлар шәфкатьле җылылык биргәннәр. Алар, җилләр шикелле, бер урыннан икенче урынга, бер йөрәктән икенче йөрәккә сыешып күчеп йөргәннәр. Кеше җырсыз тора алмый. Җыр – кеше рухының җимеше ул!

Җимешне, бигрәк тә тәмле җимешне, һәркем ярата. Аны каян да булса табып алырга, үстерергә тырыша. Моңлы җырлар да җыр яраткан җылы йөрәкне эзлиләр. Алар дәрьялар һәм болытлар аша йөри бирәләр. Тукай җырлары, канатлы кошлар шикелле, Урал тауларыннан киң Себергә, Себер далаларына очканнар. Аларны салкын Себергә дә җылы җилләр алып килгәннәр.

«Җирнең колагы зур», дигәннәр картлар. Ул һәрнәрсәне, бигрәк тә үзенә файдалы булган хәлне, ишетә һәм аны яхшы иттереп беләсе килә. Бу яктан Донбассның

колагын да бик зур диләр, чөнки ул, җирнең астын һәм өстен тыңлый белә. Шуңа күрә, колагы зурдыр да шул.

Бу тирән шахталы, зур колаклы Донбасс, Казан урамнарында дәртле Тукайның, нык-нык басып, кулына җырлар тотып йөрүен дә, анын, аяк тавышларын да ишетә.

Җирнең колагы булса, җырның канаты бар. Җырлар канатланып шахталарга – күмер учакларына да очалар. Шахтерлар һәркемнән дә артык җыр яраткан, дөньяның тәмен белгән һәм авырлыкларын татыган халыклар алар. Алар яхшы белән начарны, дус белән дошманны аера торган кешеләр.

Тукай җырлары шахтерлар арасында зур дан һәм хөрмәт таба. Чонки ул аларга күңел юаныгчы, иркенлек дәрте бирә. Күңел юанычы һәм иркенлекне кем яратмаган соң? Шахтерлар, вакыт тапканда, озын төннәрдә «Шүрәлене укып шаккатканнар. Гомерләрендә иң сирәк көлә торган бу халык, бар күңелләре белән: «Былтыр кысканга бисл кычкыралармы?» дип шаяра-шаяра көлгәннәр. Үзләренә хөрмәт тапкан Тукай җырлары, шахтерлар белән үлмичә яши, алар белән сугышка фронтларга җитә. Илнең бәхете өчен көрәшергә, немец фашистларын Донбасстан куарга, илдән күтәреп атарга һәм бөтенләй юк итәргә хезмәт итәләр.

«Матурлар дөньяда үзләренә тиңдәш эзли», дигәннәр. Бу сүз дөрес. Тукай шигырьләре дә үз матурлыкларына тиңдәш эзләгән шикелле, дөньяда тиңдәше булмаган матур Кырымга, минем ана йортыма да килеп чыкканнар. Рәхмәт аларга! Алар анда күп бишекләр тирбәткән һәм җырчыларны җырлаткан!

Тукай җырлары белән олы Пушкинның шигырьләре, икесе ике игез бала шикелле, кулга-кул тотышып, якын дус булып, җыр яраткан болытларга, тауларга менеп,

башын куеп тыныч йоклаган Чатыр тауга үрләгәннәр. Һәм Кырым Тукай җырларын, Пушкинның Кара диңгез дулкыннарына карата җырлаган энҗе сүзле, балдай тәмле шигырьләрен тыңлаган. Аларны тик кенә түгел, бирелеп тыңлаганнар. Матур җырлар үз-үзләреннән: «Тукай бу җиргә килмәдеме икән?» – дип сораганнар. Алар тирән сулыш белән: «Килгән булса, ул да Кара диңгез турында. Кырым турында җырлар иде», – дип үкенгәннәр. Нишләтәсең, ул аңа насыйп булмаган. Матур җырларның матурлыгыннан башка да үзе табигый булып торган Кара диңгезнең үз матурлыгы бар. Шулай булса да, ул матур җырларны ярата шул. Ул, олы Пушкинның, көчле Горькийның үз турысында, ягъни, үзенең ак дулкыннары, куе зәңгәр күренеше турында әйткән тәмлежылы сүзләрен азмы тыңлаган, алардан азмы шатлангандыр? Моны кем белми, моны сөйкемле Кара диңгезгә караган кайсы күз сизми, кайсы йөрәк ишетми? Анда Пушкин һәм Горький сүзләре мәңгегә җырлап тора. Пушкиннарга, Горькийларга илһам почмагы булган җиңелмәс йортым Тукай җырларын да үз бәгъренә алган. Чөнки, Ватаныбызның башка халыклары шикелле, минем халкым да матурлыкны сөйгән, яраткан горур бер халык ул! Бу халыкка үз тавышын ишеттергән олы Тукайга, үлмәс шагыйрьгә мең рәхмәт!

Тукай Кырымга үз тавышын ишеттерү белән генә дә чикләнеп калмаган. Ул, үзе шикелле халык арасыннан күтәрелгән, кулына шигырь байрагы тотып чыккан, Кырым татар халык шагыйре булган – Шамиль Туктаргазыйның үсүенә дә ярдәм иткән һәм аңа булышкан.

Үз Кырымы турында:

*Уфаклы, ирше бир чук кая алар,*
*Тәрән дәрә, боек тупә уалар,*

*Яшил урман, ара-сыйра кубалар*
*Яраштыклыйк кәтирерләр Кырымга, –*

дип җырлаган бу шагыйрь Тукайны үзенә йолдыз иткән. Туктаргазый, Тукайдан биш кенә яшь олы булса да, ул Тукайга үз абыйсы һәм үз туганы итеп караган. Ул ничек тә булса, Тукай шигырьләрен кулга төшергән. Аларны аерым-аерым дәфтәрләргә яза барган. Бу шагыйрь үз кулъязмаларын, кадерле китапларын Николай жандармериясеннән ничек яшергән булса, Тукай шигырьләрен дә шулай яшергән, саклаган. Иркенлек сөйгән һәм үз халкын иркенлеккә чакырган бу шагыйрьне һаман каравыллап йөргәннәр. Шуңа күрә, ул бер урында тора алмаган. Авылдан авылга күчеп йөргән. Ахырында 1913 елда татар байлары аны пычак белән кадап үтергәннәр.

16 яшеннән үк шигырьләр язарга, балалар укытырга керешкән, халкына бәхет эзләп чыккан бу яшь шагыйрь аша, Тукайның:

*Әй туган тел, әй матур тел,*
*Әткәм-әнкәмнең теле.*
*Дөньяда күп нәрсә белдем,*
*Син туган тел аркылы, –*

дигән шигырьләре бөтен Кырымга яңгыраган. Матур тауларга, җимешле бакчаларга, йөземле бакчаларга җәелгән. Моңга ия булган көчле бу шагыйрь, үз шигырьләренә көйләр чыгарган шикелле, Тукай шигырьләренә дә көйләр тапкан.

Туктаргазый шигырьләрен гектограф аша бастырып үз халкы арасына тараткан шикелле, Тукай шигырьләрен дә гектограф аша бастырып халыкка тарата торган булган (...)

Тукайның балалар өчен язган лирик шигырьләре кайсы мәктәп баласына мәгълүм түгел соң? Туктаргазый

һәм аның шикелле укытучылардан дәрес алган балаларның кайсысы:

*Әйт әле, күбәләк,*
*Сөйләшик бергәләп,*
*Бу кадәр күп очып,*
*Армыйсың син ничек? –*

дип сабак башламаган һәм үз телен өйрәнмәгән?

Кырым үзәннәренең саф сулары шикелле чылтырап аккан, шома бу шигырьләр, 8 яшьләрендә мәктәпкә барган азмы сабыйның күңеленә ошамагандыр. Без Тукайның мондый шигырьләрен мәктәпкә чаклы да ишетеп беләдер идек. Әти-әниләребезгә шигырь беләбез дип, сабый күңелебез белән мактана идек. Тукайның бер-береннән матур булган шигырьләрен балалар күңелгә бикләгәннәр. Аның «Эш беткәч уйнарга ярый» дигән тиңсез матур язылган шигыре балаларны укуга-белемгә ашкындырган. Һәм Туктаргазыйның:

*Бүннан соң унсыз хаят улмаячак,*
*Уйның белән ачылган гөл сулмаячак,*
*Бу укудыр, балаларның малыдыр,*
*У гыйлемдер, инсаннарның кәмалидир, –*

дигән юллары азмы егетләргә, азмы кызларга уку, белем юлы күрсәтмәгәндер? Белемгә, гыйлемгә хөрмәт тудырмагандыр?!

Гомерләре буена бер-берсен күрмәгән шагыйрьләр бер береннән аерылмас дус булганнар.

Алар һәр икесе дә үз халкын иркенлеккә һәм олы рус халкы белән дус булырга чакырганнар. Олы Тукай:

*Рус белән тормыш кичердек сайрашып,*
*Тел, лөгать, гадәт, вә әхлак алмашып.*
*Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?*
*Без туган, бер җепкә бергә теркәлеп,*

дигән булса, Туктаргазый:

*Суң сүзем бу дир саңа,*
*Руслар белән бир хуш яша!*
*Мәктәпкә кәт, русча белең*
*Кәтмәсин гомериң буша,*

дип җырлаган. Чын күңел белән, иркенлек яраткан бу шагыйрьләр руслар белән генә дуслыкка түгел, Россиянең бөтен халыклары белән дә дус, кардәш булырга чакырганнар.

Менә Туктаргазый:

*Сән әрмәни, мән грузин,*
*Шай улса да кардәшмиз.*
*Дугган ил бир дая бизгә*
*Дулбәр Кавказ, даги буз,*

дигән.

*Җир яшәрмәс, гөл ачылмас*
*Тоимы яңгыр тамчысы,*
*Кайдан алсын шигыре шагыйрь?*
*Булмаса илһамчысы, --*

дип үлмәс һәм тәкрарланмас сүзләр аша бу ике игез шагыйрь илһамны үз халкыннан, үз туган йортларыннан алганнар. Туган ил аларның шигырьләрен бизәгән. Аларга җыр өйрәткән. Тукай, сөекле Татарстанының һәрберсе бер матур шигырь булган кара куе урманнарны һәм аларның яшәреп яфрак яруларын җырлаган булса, Тукайдан көй өйрәнгән Туктаргазый туган Кырым турысында:

*Кырым дәрләр ватанымның адина,*
*Туим улмаз ямишинең дадина,*
*Сәвәр күңлим ана кеби бу яри, –*

дип тирән бер хис, көчле бер хөрмәт белән үзенең һәм халкының ватаны булган Кырымга эчке тойгыларын әйткән.

Бу көндә суы ширбәт, бакчалары җәннәт булган Кырымның матурлыкларын, бәрәкәтле туфракларын үзләренең җирәнгеч һәм шакшы аяклары белән таптап йөргән, туган халкыма ачлык вә үлем китергән немец фашизмына каршы аяусыз көрәшкән кайсы Кырым партизаны, кайсы совет батыры Туктаргазыйның туган Кырым хакындагы:

*Буңа яшил ададәрләр. Бу җәмалый Чатирдаг,*
*Буниң бир тарафи чүлдер, бир тарафи багча-баг,*
*Аман, углум, сатма сакый тупрагый,*
*Анаң кеби сәни бәсләр бәрәкәтли кучагый,*
*Бак, сәниң бирчай ийриң бар, нә гүзәлдер чукрагый,*
*Ширил, ширил кәлә суи ярип кара тупрагый, –*

дигән матур юлларны искә алып сугышка китми соң?

Кайсы батырның көчле йөрәге мәңге җиңелмәс киң чатырга карап:

*Миллионнар ләшл саг син,*
*Гам аңламаз бир даг син,*
*Әй, Чатир! Сән бизләргә*
*Гөл багчасиң, бир баг син, –*

дип күңел ярсытмаган, Кырымның азатлыгы өчен көрәшмәгән?

Әлбәттә, Кырым тауларында фашистларга каршы, юлбарыслар шикелле көрәшкән партизаннар, матур шәһәрләрнең азатлыгы өчен батырларча сугышкан Кырым балалары, Советлар Союзының Герое һәм орденлы Н-чы полкның командиры булган Хөсәен Сөләйманов шикеллеләр, Туктаргазыйның һәм олы Тукайның ялкынлы шигырьләрен укып тәрбия алган егетләр алар. Аларның ватан өчен булган ашкынулары һәрнәрсәдән өстен һәм көчле.

Бу батырларның телләре, Пушкиннардан, Лермонтовлардан үрнәк алып шагыйрь булган шагыйрьләрнең шигырьләре белән тулган. Кайсы татар баласы элек мәктәпкә барган чагында ук Пушкиннар, Лермонтовларны Тукайдан яки Туктаргазыйдан өйрәнмәгән соң?

Кайсы Татарстан егетләре Лермонтовның «Тройка»сын Тукай каләме аша:

*Җиктереп пар ат Казанга,*
*туп-туры киттем карап.*
*Чаптыра атларны кучер суккалап та тарткалап,*

дип, үз ана телендә сөенә-сөенә укымаган?

Кайсы Кырым егете олы Пушкинның «Балык һәм балыкчы карт хикәясен» Туктаргазыйның тәрҗемәсе аша:

*Бир сашлдә бир анай вә бир бабай кырык ел кадәр,*
*Әттиләр балыкчылык кар чыкмадый*
*һич кюйи кадәр, –*

дип, укымаган һәм аның белән шатланмаган соң? Туктаргазый болай матур тәрҗемә итәргә олы Тукайдан өйрәнгән, аның шикелле Пушкин һәм Лермонтовның шигырьләрен тәрҗемә иткән. Бу шагыйрьләр халкыбызның шигъри культурасын һәм аның мәдәни үсешен, рус классиклары аша югары күтәргәннәр. Алар халыкның алдан күрүче культуралы кешеләре һәм үлмәс көчләре булганнар.

Тукайның мәңге үлмәс шигырьләре дөнья поэзиясенең алдынгы үрнәкләреннән бер дә ким түгелләр. Шуңа күрә дә Тукай – шигърият йолдызы ул! «Олы кешеләр үлмиләр, тик туалар», – дигән картлар. Шуның шикелле, Тукай да үлмәде. Ул нәселдән-нәселгә үсә, һәм үз халкын да үстерә бара. Шагыйрьләр өчен якты шигърият йолдызы булып яна.

Көчле Тукай, дәртле Тукай, Боек ватан сугышы фронтларында фашизмга каршы сугышкан татар батырларына, татар генералларына рух бирә. Һәм фронтка булышкан батырларны эшкә чакыра, ул:

*Без сугышта юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез,*

дип горур һәм батыр татар халкының, үлмәс улы булып ил өчен хезмәт итә. Ул җиңү байрагы булып дулкынлана.

Дошманга каршы юлбарыслар кебек сугышкан татар егетләре мөкаддәс ватан өчен үлгәндә дә Тукай сүзләре белән:

*Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,*
*Дәшми калмам газрәилне күргәндә дә:*
*Без китәбез, сез каласыз дип җырлармын,*
*Җәсидемне туфрак белән күмгәндә дә,*

дип җырлап сугышып үләләр.

Аның өчен, олы Тукайга хөрмәт итеп шушы сүзләрне җырлыйсы килә:

*Әй кадерле, моңлы сазлы, Җир чишмәсе яшь Тукай,*
*Син халыкка рух бирүче, шагыйрьләргә якты ай.*
*Каберецдә рәхәт йокла, шигърият йолдызы,*
*Каләмеңә юл күрсәтә шигъреңнең һәр сүзе.*

*Казан.*

## ТАРАС ШЕВЧЕНКО И ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА

Передовая татарская интеллигенция, революционно-демократические поэты, писатели и литературоведы с большой любовью изучали творчество Тараса Шевченко.

Его творческая и личная жизнь стали ярким примером подлинного борца за счастье и свободу своего народа.

Среди татарских литературоведов, ученых и писателей, изучавших творчество Тараса Шевченко до Октябрьской революции, особо выделяется Галимджан Ибрагимов. Он, как один из основоположников татарской советской литературы, научного литературоведения, много лет изучал, пропагандировал творчество Тараса Шевченко среди трудящейся молодежи татар, башкир и казахов.

Как известно, первые шаги литературоведческой деятельности Галимджана Ибрагимова начинаются тогда, когда он был преподавателем теории и истории литературы бывшего духовного училища «Галия» в городе Уфе. Студенты данного училища были разных национальностей: в нем обучались вместе с татарами, башкирами, казахами и представители других тюрко-татарских национальностей.

Галимджан Ибрагимов в своих лекциях и отдельных выступлениях перед студентами по вопросам языка и литературы очень часто говорил в качестве положительного при-

мера в поэзии о творчестве Тараса Шевченко, «как первого поэта малороссов, как кипучего родника, идущего из глубин народа». Об этом подробно и красочно говорит в своем весьма интересном и полезном воспоминании – «Памятные минуты» – классик башкирской советской поэзии и бывший студент духовного училища «Галия» Сейфи Кудаш[1].

Увлекательные и содержательные лекции Галимджана Ибрагимова всегда были насыщены примерами из творчества Пушкина, Лермонтова, Омара Хайяма, Физули, Тукая, Абая, Некрасова и Шевченко, что, несомненно, оказало большое положительное влияние на поэтическое творчество таких талантливых поэтов, как Шеих-Заде Бабич и Сейфи Кудаш. Эти поэты были студентами и остаются верными и лучшими учениками Галимджана Ибрагимова.

Для Галимджана Ибрагимова, и для всей татарской интеллигенции Тарас Шевченко особо был дорог тем, что его борьба с самодержавием сливалась с их борьбой. Выражая эту общую идею, Галимджан Ибрагимов в 1914 году в одной из своих статей в журнале «Анг» (Сознание) пишет: «Сколько старалась официальная Россия присоединить Малороссию к себе, столько страдал первый малороссийский поэт Тарас Шевченко за то, что писал на малоросском языке (украинском языке – К.Р.). Однако невозможно приостановить действие могучего родника, извергающегося из глубин жизни».

В 1912-1913 годах Галимджан Ибрагимов был направлен в Киев для ведения подпольной работы среди студенческой молодежи. В 1913 году 17 апреля из числа тайной студенческой организации шестнадцать человек

[1] *Сейфи Кудаш, Памятные минуты. – Казань, 1959. – С. 58*

были арестованы и брошены в тюрьмы. Среди арестованных был и Галимджан Ибрагимов.

Находясь в Киеве, Галимджан Ибрагимов особенно глубоко изучает творчество Тараса Шевченко и посещает те места, которые были связаны с жизнью и творчеством великого поэта. О своем впечатлении от пребывания в Киеве и на Украине Г.Ибрагимов пишет, что «этот город, вообще эта страна полны Тарасом Шевченко. Быть в этих местах и не писать о Шевченко невозможно».

В связи со столетием Тараса Шевченко Г.Ибрагимов выступает с большой статьей «Поэт-герой» на страницах газеты «Юлдыз» («Звезда»). Данная статья имеет исключительное значение для татарского литературоведения как подлинно научное начало шевченковедения в истории татарской литературы. Автор не только показывает, но одновременно подробно рисует характер тех литературоведческих споров и идейную борьбу, которые ведутся вокруг творчества Шевченко.

Ибрагимов, как ученый, как крупный литературовед и великолепный мастер художественного слова, от души призывает передовых татарских писателей, учится у Тараса Шевченко писательскому мастерству и быть таким же поэтом-героем, как украинский Кобзарь.

Ибрагимов, характеризуя Тараса Шевченко, пишет: «Он – поэт. художник, скульптор. Он – герой революции. Больше всего он является синтезом, где в лучшей форме отражаются исторические идеалы угнетенного народа, который так стремится выйти на широкую дорогу, в светлый мир. Он является символом всех национально-общественных стремлений и желаний малороссов»[1].

---

[1] *Г.Ибрагимов Вопросы литературы. Казань. 1960 г. С. 8*

Галимджан Ибрагимов в своей статье ставит вопрос о том, почему именно Шевченко так дорог и близок народам России и в том числе татарскому народу.

Автор, сам отвечая на поставленный вопрос, подчеркивает, что «Сироты друг друга быстро понимают. В судьбе шевченковского народа очень много общего с судьбой татарского народа»[2].

В большом плане изучение и распространение творчества Т. Шевченко среди татарского народа начинается после Великой Октябрьской социалистической революции, особенно в 30-х годах.

В эти годы очень часто появляются переводы произведений поэта на татарский язык в Крыму и в Татарии. В Крыму переводами произведений Т.Шевченко творчески занимаются такие видные татарские советские поэты, как Максут Сулейман, активные участники Великой Отечественной войны, героически отдавшие свою жизнь за Советскую Украину, за независимость нашей Родины Амди Алим, Осман Амит и многие другие.

В Татарии в 30-х годах самым активным популяризатором творчества Тараса Шевченко является легендарный поэт-герой, лауреат Ленинской премии Муса Джалиль. Он является организатором и инициатором большого количества переводов произведений Шевченко на татарский язык.

В 30-х годах Муса Джалиль несколько раз посетил Украину, город Киев с целью глубокого изучения жизни и творчества Тараса Григорьевича. Результатом этого являются его переводы и статья, зовущая татарских советских поэтов учиться у Тараса Шевченко. Муса Джалиль

---

[2] *Там же.*

сам учился у Тараса Шевченко писать в подлинно народной манере пламенные, волнующие, одновременно глубоко героические стихи, песни, поэмы; и призывал других к этому поучительному мастерству. В этом плане весьма характерна опубликованная на страницах газеты «Красная Татария» (1939 год, 9 марта) его статья «Учиться у Шевченко писать». В данной статье Муса Джалиль подробно рассказывает о своем переводческом опыте и о своей учебе у великого Кобзаря.

В 1939 году татарская общественность широко отмечала 125-летие со дня рождения Тараса Шевченко.

Орган Союза писателей Крыма, литературный и общественно-политический журнал «Совет эдэбияты» («Советская литература») свой мартовский номер 1939 года посвящает 125-летию со дня рождения Тараса Григорьевича Шевченко и публикует его произведения в переводе татарских поэтов. В этом же году в Казани орган Союза писателей Татарии «Совет эдэбияты» в своих 3-4 номерах уделяет большое место творчеству поэта, помещает его портрет, публикует статью известного татарского литературного критика Хасана Хайри. Автор в своей статье «Тарас Шевченко» подробно знакомит татарского читателя с жизнью и творчеством великого сына украинского народа. Журнал публикует также отрывок в переводе из дневника Тараса Шевченко под общим заглавием «Шевченко в Казани».

В 1857 году, 12 сентября Тарас Шевченко по пути из Астрахани в Нижний Новгород останавливается в Казани, посещает Кремль и Казанский университет.

В 1939 году под редакцией Мусы Джалиля выходит сборник стихов и поэм под названием «Кобзарь». Данный сборник является первым объемистым сборником



Кэрим Жаканов

поэта. В сборник включено более 40 произведений Тараса Шевченко в переводе таких мастеров художественного слова, как Муса Джалиль, Хасан Туфан, Ахмет Файзи, Шейхи Маннур, Нур Баян и др.

В 1953 году выходит еще один сборник стихов и поэм Тараса Шевченко под названием «Кобзарь» в переводе 10 известных татарских поэтов. Данный сборник вышел под редакцией поэта Энвара Давыдова. В сборник вошло 31 произведение Шевченко. Среди этих переводов отличаются своим качеством переводы таких известных мастеров художественного слова, как Ахмет Файзи, который великолепно перевел чудесную поэму «Катерина», где поэт-переводчик с большой теплотой и верностью оригиналу передает кристальную чистоту чувств, наивность и доверчивость украинской «чернобровой» крестьянской девушки.

Ахмет Файзи – большой поэт, глубоко чувствует и ясно видит в трагической судьбе Катерины и ее жестокой преждевременной смерти тяжкую судьбу, бесправие дореволюционной татарки-девушки, матери.

Поэтому его переводы становятся подлинными, творческими и весьма доходчивыми для требовательного и строгого татарского читателя. Среди переводчиков этого периода можно отметить Ахмета Исхака, переводившего знаменитое «Завещание» Тараса Шевченко, Салиха Баттала, как переводчика поэмы «Гайдамаки», Энвара Давыдова, Заки Нуриева и многих других. Эти переводы пользуются широкой популярностью среди татарских читателей. Как уже было отмечено, переводами произведений Шевченко много занимался знаменитый поэт-герой, лауреат Ленинской премии Муса Джалиль. Среди его переводов особое место занимает перевод поэмы «Работница».

Муса Джалиль, стараясь во всем остаться близким к оригиналу, дает поэме подзаголовок «Батрачка». Как известно, сам Тарас Шевченко именовал свою поэму в переводе на русский язык – «Наймичка».

Среди множества стихов и поэм Шевченко, отражающих женские образы, образы девушек-матерей, поэма «Работница» занимает особое место. Данная поэма отличается двумя особенностями.

Прежде всего в ней Шевченко выступает как глубокий лирик и как художник-живописец в создании чудесного образа женщины-работницы-матери. Поэт с большой теплотой и только лишь истинному художнику присущим мастерством и дарованием, рисует образ матери такими неповторимыми художественными эпитетами, метафорами, сравнениями, благодаря которым образ матери становится живым и сильно впечатляющим. В Прологе поэмы поэт пишет:

*В воскресенье ранним-рано*
*Поле крылося туманом,*
*И стояло в том тумане,*
*Словно тополь на кургане,*
*Молодица молодая,*
*Что-то к сердцу прижимает,*
*Горько плачет, причитает.*[1]

Сохраняя эту изумительную картину, М.Джалиль переводит в следующей форме:

*Якшәмбе көн иртә белән*
*Кырны япкан кук томан.*
*Бер яшь кенә кыз иелгән,*

---

[1] *Т. Шевченко. Стихи и поэмы. – М.: ОГИЗ. Госполитиздат, 1948. – С. 62.*

*Курганга тополь сыман.*
*Нәрсәнедер йөрәгендә*
*Кыскан. Җиргә иелеп,*
*Ул томанга нидер сөйли*
*Күз яшенә төелеп*[1].

В переводе нет слов «Горько плачет», они заменены словами «задушившись своими слезами плачет», – говорит Муса Джалиль. Это не вольность в переводе, а наоборот, еще более глубокая передача внутреннего смысла драматизма и заодно подчеркивание внешней стороны данного процесса.

Такой подход к переводу усиливает его творческий характер. Говоря об особенностях данной поэмы вообще, мы подчеркиваем как первую особенность – глубокий лиризм поэмы, яркость описываемых картин.

Вторая особенность данной поэмы заключается именно в том, что в этой поэме больше всего и лучше всего Шевченко показывает свое любовное отношение к честному труженику – простому народу и свою бесконечную любовь к национальным обычаям, правам своего народа. Очевидно, эти особенности и прежде всего сильный и более глубокий характер матери-работницы привлекает внимание Мусы Джалилия, поэта-переводчика.

Глубина, живость и могущество материнской любви волновали многих художников. Один из лучших наследников Тараса Шевченко – Иван Франко, сравнивает две великолепные поэмы своего учителя «Наймичка» и «Катерина» и пишет: «Выступают две героини, – говорит Франко, – относящиеся к друг другу как огонь и вода. Катерина –

---

[1] *М.Җәлил. Сайланма әсәрләр, өч томда. I том. – Казан: Татгосиздат, 1955. – 562 бит.*

натура простая, пылкая, впечатлительная, сангвиническая, обманутая офицером, покинутая в своем тяжелом горе, она думает только о себе, бросает ребенка на дороге, а сама ищет в своем горе, единственное оставшееся ей лекарство, – в воде, подо льдом. Наймичка – натура неизмеримо более глубокая, ее чувство не только живо, но сильно и высоко, любовь к ребенку настолько могучая, что побеждает все остальное, заслоняет перед нею весь мир, заставляет забыть о самой себе, отдать всю жизнь не мгновенному искуплению, но – долгой жертве на благо собственного ребенка»[2].

Нет сомнения, выше отмеченное свойство – сильный характер образа матери-работницы – привлекало внимание М.Джалиля. Образ матери и образ деда Трофима очень близкие сердцу переводчика. М.Джалиль с такой теплотой, с таким большим поэтическим сердцем передает глубокие общечеловеческие черты характера отмеченных образов:

*Вошел Марко к Ганне в хату*
*И стал у порога –*
*Испугался ... Ганна шепчет*
*– Слава, Слава Богу!*
*Иди сюда, не пугайся!*
*Ты, Катруся, выйди.*
*С Марком я хочу остаться,*
*Уж не будь в обиде ...*
*Вышла тихо Катерина,*
*А Марко убитый,*
*Наклонился к изголовью.*

---

[2] *Записки наукового творчества имени Т.Шевченко. – Львов, 1895, кн. 2. – С. 20.*

*– Марко, погляди ты,*
*На меня взгляни, голубчик, –*
*Что со мною стало!*
*Я не Ганна, не батрачка,*
*Я ... и замолчала.*
*Марко плакал ... а батрачка*
*Вновь очи открыла,*
*Долго, жалобно глядела*
*И заголосила:*
*– Прости меня! Я с тобою*
*Весь век как чужая ...*
*Прости меня, мой сыночек!*
*Я ... твоя ... родная ...*[1]

Особенно задушевно переведена выше отмеченная заключительная восьмая глава поэмы. Вот как звучит в переводе изумительная, вместе с тем глубоко трагическая картина прощания Ганны-работницы-матери с сыном Марко:

*Марко асрау хатынның*
*Баш очына килде. Ганна*
*Әйтә: «Марком», акыллым!..*
*Кара миңа, күрәсең мин*
*Нинди ябыктым инде.*
*Мин бит асрау хатын түгел,*
*Ганна түгел ... мин ...» – диде.*
*Сүзен әйтеп бетермәде,*
*Телдән калды бичара ...*
*Марко җылый һәм аптырый.*
*Ганна хәлсез булса да,*

[1] *Т. Шевченко. Стихи и поэмы – М.: ОГИЗ. Госполитиздат, 1948. – С. 77-78.*

*Күзләрен тагын ачты да,*
*Тутырып карады аңа.*
*Яңакларын юа-юа*
*Күзләреннән яшь ага.*
*– «Кичер ... бирдем мин гомеремне*
*Чит ой бусагасына.*
*Улым, бәгырем, кичер мине,*
*Мин бит ... мин ... ана ... сиңа ...»*[1]

В переводе данной заключительной восьмой главы поэмы, как и в других главах, много творческого усилия Мусы Джалиля как прекрасного переводчика классических произведений Кобзаря. В качестве примера возьмем следующие строки из отмеченного отрывка:

*Марко плакал ... а батрачка*
*Вновь очи открыла,*
*Долго, жалобно глядела ...*

Как видно, в этом отрывке нет слов о том, что «батрачка ослабевала» и «слезы, льющиеся из ее глаз, омывают ее лицо». Эти слова добавляет сам переводчик. Внимательно читая и понимая подтекст автора, он идет на такую «вольность», вполне оправданную. Если внимательно подойти к вопросу, то здесь нет и тени вольности в переводе. Как известно, вся заключительная глава посвящается предсмертной минуте жизни многострадальной батрачки и последней самой трагической, весьма волнующей встрече с ее любимым сыном. Поэтому эти отмеченные «добавления» переводчика замечательной поэмы не ухудшают ее качества, а наоборот, сохраняют ее богатое внутреннее содержание, делают ее ближе

---

[1] *М.Җәлил. Сайланма әсәрләр. өч томда. I том. – Казан, Татгосиздат, 1955. – 577 бит.*

татарскому читателю. Такого рода «добавления» потребовали и структурные особенности родного татарского языка. Например, в оригинале сказано, когда речь идет о самом последнем прощании батрачки с сыном: «Слезы покатились», а в переводе М.Джалиля, исходя из особенностей родного языка, следует повтор: «слезы обмывая и обмывая текут по ее лицу». Эти повторения более точно передают глубину грусти и печали любимой матери перед сыном в момент смерти. Благодаря такому чуткому и мастерскому переводу М.Джалиля, замечательное классическое произведение мировой литературы как «Батрачка» Тараса Шевченко вместе с другими произведениями поэта получили большую популярность среди татарского читателя.

Великий сын украинского народа вошел в татарскую литературу не только такими прекрасными переводами и литературоведческими статьями отдельных татарских литературоведов, но и бессмертный образ самого поэта отражался и отражается в татарской советской поэзии. В этом отношении очень характерна одна из лирико-философских поэм Гаделя Кутуя, автора популярной среди советского читателя повести «Неотосланные письма».

В данной поэме поэт ставит в большом философском плане проблему о классическом наследии двух противоположных миров – мира социализма, коммунизма и мира империализма, фашизма. Поэт в своей поэме дает с большой и глубоко любовной позиции образы классиков мировой литературы и культуры, начиная от Эсхилла, Гомера, Шекспира, Гейне, Байрона, Пушкина, Некрасова, Хайяма, Физули, Шота Руставели, Горького, Маяковского и Тараса Шевченко. Поэт подчеркивает: если реакционный

мир империализма, фашизма варварски сжигает прекрасные творения мировой литературы и культурные памятники прошлого, то, наоборот, в творениях гения человечества в стране Советов и в странах социализма, коммунизма они приобретают вечную светлую родину, они как-то начинают жить по-новому.

Среди этих счастливых и вечно живых гениев Тарас Шевченко – великий гуманист, сын украинского народа, революционный демократ поднимается на трибуну, пишет Гадел Кутуй. Тарас, как живой с живыми говоря, с присущим ему поэтическим голосом обращается к милой ему Украине, своему мудрому украинскому народу. Эта часть поэмы как-то сливается с содержанием знаменитого «Завещания» самого Тараса Шевченко. Тарас от души радуется тому, что его звонкие песни, стихи, поэмы стали бесконечно счастливыми. Они вместе со счастливым народом активно строят новую жизнь, где господствуют равенство, братство и нерушимая дружба народов великого Союза Советов. В поэме рисуется образ Тараса Шевченко так, что он чувствует себя особенно счастливым, именно тогда, когда он ярче всех видит, что молодежь, читая его произведения, узнает трудный исторический путь, пройденный его народом. Образ великого поэта-мыслителя, борца, революционера изображается в данной поэме именно так, чья поэзия является «для каждого человека чудесным пером искусства»[1], как писал Луначарский. В таком, весьма положительном плане входит образ Т. Шевченко в татарскую литературу. Многие татарские поэты воспевали и воспевают светлый образ Тараса Шевченко. Среди старшего поколения татарских советских писателей и поэтов

---

[1] *Луначарский. Статьи о литературе. – М., 1957, С. 439.*

особо отличается в этом отношении большой лирический поэт Хасан Туфан.

Хасан Туфан в 1939 году в своем волнующем лирическом стихотворении «В золотом доме», посвященном Тарасу Григорьевичу Шевченко, дает в оригинальном плане образ великого украинского поэта. Бессмертное народное сердце – это есть золотой дом Тараса Шевченко, говорит Х.Туфан. В этом золотом доме гордо сидит Тарас Шевченко, а молодое поколение поэтов находится в гостях у Тараса Григорьевича. Как-то Кобзарь принимает в своем родном доме гостей. Каждому народу близок, дорог и понятен язык гордого хозяина Золотого дома, говорит поэт. Дальше Хасан Туфан подчеркивает, что каждый совет Тараса дает много тепла и радости сердцам людей и ясность нашей жизни. Такими яркими, светлыми образами обогащает бессмертное творение и героическая жизнь Тараса Шевченко татарскую литературу.

Татарские писатели и татарское советское литературоведение очень часто и с большой любовью обращаются к бессмертному наследию Шевченко. Причину этой безграничной и постоянной любви к творчеству поэта, идя по пути своего учителя Г.Ибрагимова, известный татарский литературовед, кандидат филологических наук Гали Халит в своем труде, посвященном творчеству народного татарского поэта Габдуллы Тукая, раскрывает в следующем плане:

«Пламенным гуманистом и стойким защитником угнетенных предстал перед татарским народом Тарас Шевченко, поэзия которого была воспринята как воплощение горя и радости, как биение истерзанного сердца украинской нации. Тарас Шевченко был понятен татарской демократической интеллигенции как непреклонный борец

за национальную свободу, за беспрепятственное развитие национального языка и литературы»[2], – пишет Гали Халит.

Тарас Шевченко велик и близок всем народам нашей страны, вместе с тем и татарскому народу, как поэт глубоко революционный и по духу своему социалистический. Его поэзия постоянно зовет к борьбе, к светлому будущему.

Татарская общественность ныне, как и все другие народы страны, широко отмечает 150-летие со дня рождения Т.Г. Шевченко. Готовятся к изданию новые переводы, исследования творчества любимого поэта.

---

[2] *Гали Халит. Габдулла Тукай. – Казань. 1960. – С. 97.*

## ТУГАЙБӘЙ ХАКЫНДА ПОЭМА

**(XVII гасыр кырым татар әдәбиятына караган материаллардан)**

Тугайбәй хакында поэма Кырым татар классик әдәбиятының иң борынгы чорына карый. (*Поэманың авторы Җанмөхәммәд исемле шагыйрь. Бу турыда әсәрнең азагында хәбәр ителә. Поэманың исеме язылмаган. Төп каһарманы Тугайбәй булганга һәм халык арасында да әсәр аның исеме белән атап йөртелгәнгә күрә, без дә аны Тугайбәй хакында поэма дип атадык. Тугайбәй Ор капкасының коменданты булган – К.Р.*). Бу поэманың язылган вакыты, аның эчтәлегеннән күренгән тарихи фактларга караганда, XVII гасыр булырга тиеш. Әсәрнең үзендә дата күрсәтелмәгән. Ләкин әсәрнең эчтәлегенә игътибар итсәң, ул поход беткәч (1649 ел азакларында) язылган булырга кирәк.

Бу поэма Кырым татар әдәбияты тарихының борынгы дәвере эчендә иң кадерле классик үрнәкләреннән берсе санала ала. Борынгы чор язма әдәбият тарихында бүгенге көнгә кадәр үзенең тарихи һәм әдәби кыйммәте ягыннан бу поэма кебек кызыклы әсәрне очратканыбыз юк иде әле. Әсәрнең тарихи, сәяси һәм әдәби кыйммәте бик тә зур. Аны шундый дәрәҗәгә күтәргән җитди сәбәпләр бар. Башта бу әсәр XVII гасырда һәм аннан элекке чорларда безгә билгеле

булган диван һәм сарай шагыйрьләренең әсәрләре кебек, бары тик аерым ханнарны мактау белән генә чикләнмәгән, ул бер халыкны икенче халыкка каршы куярга тырышкан әсәрләрдән аерылып тора. Аерма эчтәлектә генә түгел, поэма теле, стиле һәм төзелеше белән дә шул дәвернең диван шагыйрьләренең әсәрләреннән аерыла. Поэманың теле диван теле саналган һәм ханнар өчен язылган әсәрләр теленнән мөһим дәрәҗәдә аерыла.

Әлбәттә, аның телендә һәм аерым образларны бирүдә үз дәверенең язма әдәбияты һәм дини әсәрләренең тәэсире юк түгел. Моны инкарь итеп булмый. Хәтта шагыйрь бу походны дини максатны күз алдында тоткан поход рәвешендә дә күрсәтә. Ләкин бу шагыйрьнең походка карата булган төп карашы түгел. Шагыйрь һәм аның укучылары, ягъни халык, походның дини максатлы булмавын, ә ватанны тышкы басып алучылардан саклау һәм ут күршеләре булган украиналыларга ярдәм походы булуын ачык аңлыйлар. Моны поэманың бөтен эчтәлеге тулысынча күрсәтеп тора.

Шагыйрь үз әсәрен (...) гади халык өчен язган, ягъни халык поэзиясенә якын формада язарга омтылган. Болар һәммәсе поэманы үз эпохасының оригиналь әсәре итә.

Поэманың нигезендә бер тарихи факт-вакыйга ята. Ул XVII гасырның уртасында Украина халкының Польша паннары золымыннан котылырга теләвен һәм милли азатлык хакында хыялларын чагылдыра. Һәм Кырым татар халкын ул тарихи һәм хәлиткеч көрәштә күршеләре украиналыларга союзниклык итүләре – тарихта дәлилләнгән факт. Тарихта билгеле булганча, XIII-XIV гасырлардан башлап, Украина Польша паннары кулында була, халыкның вәзгыяте коннәнкөн авырая бара. XVII гасыр уртасы – Польша паннарының украин авылларына һәм казакларга күрсәткән золым һәм

милли изүенең түзеп булмас дәрәҗәгә җиткән бер чоры. Шуңа күрә авылларда баш күтәрүләр арта, ул гомумхалык характеры ала һәм милли азатлык хәрәкәтенә әверелә. Тиз вакыт эчендә бу көрәшнең башына Богдан Хмельницкий килә. 1648 елның 22 апрелендә Богдан Хмельницкий Польша паннарына каршы поход игълан итә һәм ярдәмгә кырым татарларын чакыра.

Поэмада менә шушы вакыйга чагылыш таба. Польша паннары Украина белән генә чикләнмичә, Кырымны да үз кулларына алырга телиләр. Моны ачык аңлаган кырым татарлары стратегик кыйммәткә ия Ор капкасының коменданты Тугайбәй җитәкчелегендә Богдан Хмельницкийга ярдәмгә киләләр. 1648 елга походта поляклар җиңелә һәм Украина җирләреннән куып чыгарыла. 1649 елда поход дәвам иттерелә һәм бу вакытта Кырым ханы Ислам Гәрәй Польша паны Ян Казсмирга сатыла һәм Богдан Хмельницкий белән союздашлыгыннан ваз кичә. Ләкин татар халкының да, поэманың авторы да Украина халкына булган дуслыгын үзгәртми, аңа хыянәт итми.

Шагыйрь бу моментны поэмада бик дөрес күрсәтә. Ягъни әсәрдә Украина халкына зур хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре белдерелә. Бөтен ачу Польша паннарына юнәлтелә. Украина халкының азатлык юлбашчысы Богдан Хмельницкийга кайнар хисләр юллана. Украина халкы илбасарларга каршы көрәшүче каһарман халык итеп бирелә. Шул рәвешле поэманың әһәмияте иҗтимагый сәяси планда нык югары.

Безгә бу поэманың кульязма хәлендә Судак районында кулдан-кулга күчеп, авылдан-авылга укылып йөргәнлеге 1925 елында ук билгеле булса да, кульязманың асыл нөсхәсе табылмаган иде. Безнең кулыбызда бары тик 1925 елда чыгарылган копиясе генә бар иде. Быел, 1939 елның 15 апрелендә,

Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты поэманың төп кульязмасын, ягъни иң борынгы оригинал нөсхәсен Карасувбазар районы Җапар авылында колхоз бакчачысы 65 яшьлек Латиф Ибраһим дигән кешедән тапты. Бу кульязма 1916 елдан бирле Судак районы Капысхор авылында Куртибраһим Хөсәен дигән кешедә сакланып калган (ул исә аны үз чиратында Кортлакъ авылындагы Сәйдгали исемле кешедән укырга алган булган икән). Бу карт 1930 елда үлә. Поэма картның улы Хөсәен Куртибраһимда кала, аннан аны 1932 елда хәзер Җапар авылында яшәгән Латиф Ибраһим агай укырга ала. Инде менә поэма институтка күчкәнче бу картта саклана һәм аның өендә укыла. Картның һәм аның хатынының әйткәннәренә караганда, алар бу әсәрне кабат-кабат, бик күп мәртәбәләр укыганнар (...) Алар кульязманы кыймыйча гына бирделәр. Кульязма бик яхшы сакланган. Болар барысы халыкның үз классик мирасына ни кадәр югары бәя биргәнен, ни кадәр хөрмәт иткәнен күрсәтеп тора.

(...) 1916 елдан 1930 елга кадәр әсәрне үз кулында саклап килгән Куртибраһим Хөсәен агайның кульязманың бит кырында язып калдырган шул юлларын китереп кенә дә, әсәрнең халык арасында ничек яратылып укылганлыгын аңларга була:

«Мин, Куртибраһим Хосәен угълы, бу китапны биш ел укыдым, ул минем бәгыремне парча-парча итте, нишлисең, мин дә шул көннәрдә булсам икән, мин дә дошманга таш атар идем», – ди. Атарга теләгән ташы, һичшиксез, илбасарларга – Польша паннарына адресланган. Һичбер арттырусыз, поэманың авторы Җанмөхәммәд – зур әдәби тәҗрибә туплаган, халык тарафыннан соеп укылган һәм халык язмышын чагылдырып язган талант иясе.

Поэмада шул чорда яшәгән татар халкының гореф-гадәтләре дә чагылыш таба. Мәсәлән, Тугайбәй авырып

үлгәннән соң, бөтен халык баштанаяк кара кием киеп, матәм (яс) тоталар, бу йола бик борынгыдан килә, хәзер исә моны хәтта аксакалларыбыз да белми. Поэмада элеккеге тормышта һәм халык иҗатында булганча, мәет артыннан такмаклап җыр әйтүләр дә бар. Мәсәлән, Тугайбәй үлгәннән соң кыз кардәше һәм үз кызы Тугайбәйне характерлап такмаклап җыр җырлыйлар. Моннан кала татарларда элек-электән сакланып калган төш тәгъбирләре, төшкә ышану кебек йола-гадәт моментлары да очрый.

Болар барысы да шагыйрьнең халык тормышы һәм гореф-гадәтләре белән якыннан таныш булуын күрсәтеп тора. Һич шөбһәсез, шагыйрьнең башка әсәрләре дә булырга тиеш. Аларны табарга, өйрәнергә, шагыйрьнең биографиясен ачыкларга кирәк. Шагыйрьнең осталыгы – боек тарихи фактны реалистик планда дөрес итеп бирә белүдә һәм дәвернең тарихи һәм сәяси рухын дөрес аңлатуда.

Поэманың әдәби җәһәттән кимчелекләре дә юк түгел. Бу, иң әүвәл, шигырь техникасының бераз аксавында күренә. Мәсәлән, күпчелек рифмалар бик гади, нигездә, фигыльләрдән ясалганнар. Ләкин бу кимчелекләр әсәрнең тарихи һәм әдәби әһәмиятен киметми. Шагыйрь ачык рәвештә Польша паннарының, кырымлыларның күршесе булган украиннарга һәм казакларга каршы оештырган походының төп максатын дөрес итеп күрсәтә алган. Менә поэмада Потоцкий авызыннан әйттерелгән шул юллар җанлы мисал булып тора:

*Потоцкий чыкты мәйданга ул заман*
*Малы, хәзинәсе аның бихисап.*
*Озу* казагын бөтенләй кыру өчен,*
*Максаты – Кырым халкын алу өчен.*

* *Днепр елгасын татарлар шулай атаганнар – К.Р.*

*Бу вакыт эчендә Потоцкий һәм китте,*
*Сиксән мең гаскәрне туплады.*
*Бер угылы бар иде аның тагы,*
*Кырык иргә башлык итте, әй сакый.*
*Диде аңа: бар, Озуда утырыгыз,*
*Озу казагының эшен бетерегез,*
*Озу илен һәм авылын йыкмалы,*
*Бар барлыгын җыеп утка якмалы.*
*Моннан соң Кырымга да бармак кирәк*
*Барысын интикам алмак кирәк, – ди.*

Тарихта билгеле факт буенча поэмада Польша паннарының басып алу өметләре һәм теләкләре тар-мар ителә.

Поэма 11 иҗекле 1920 шигырь юлыннан гыйбарәт, шагыйрь юлларының һәрберсен икешәр-икешәр рифмалаштыра. Бу форма Кырым татар халык поэзиясенә якын тора. Поэмада 17 бүлек бар, һәрберсенә аерым исем бирелә.

(...) Әсәрнең төп өлешен Тугайбәйнең, Богдан Хмельницкийның каһарманлыклары, дуслыклары турында урыннар тәшкил итә. Тугайбәйне Кырым ханы Ислам Гәрәйдән Богдан Хмельницкий үзе сорап ала, аның батырлыгы хакында электән үк ишеткәне була. Хәтта украиннар Тугайбәйнең рәсемен дә ясыйлар (бу момент поэмада әйтелә).

Шуны да искәртергә кирәк: поэмадагы персонажларының бөтенесе – тарихта билгеле булган һәм походта катнашкан конкрет шәхесләр. Мәсәлән: Тугайбәй, Богдан Хмельницкий, Ислам Гәрәй, Кадыгаскәр әфәнде, Сәфәргази ага, Тугайбәйнең кардәше Кырым Гәрәй Солтан, Солтан Кәлди һәм башкалар. Поляклардан исә: Потоцкий һәм аның улы, Таганский, Полянский һ.б.

күрсәтелә. Шагыйрь бу явыз илбасарлардан көлә һәм аларның әсирлеккә төшүләрен түбәндәгечә тасвирлый:

*Потоцкий мәлгуньне һәм таптылар.*
*Хурлык итеп муенына җеп тактылар.*
*Таганский, Полянский һәрбере,*
*Алар иде полякларның баш ире;*
*Ботенесен анда әсир кылдылар*
*Һәм газилар морадына ирештеләр.*

Шулай итеп дошман белән аның үз җирендә батырларча хисаплашалар. (...) XVII гасырның уртасында алган тарихи сабакны, 1918 елда немец интервентларының, 1919-1920 елларда Польша паннарының Украинадан, ягъни Совет җиреннән, куып чыгарылуын онытмасыннар (...)

Тарихи фактларга караганда, походның кызган ноктасы Бар кальгасе һәм Албав суы (Желтые воды) кальгасе янында була. Поэмада Б.Хмельницкий һәм Тугайбәйнең батырлыгы бу кальгане алу, пан ордасын тар-мар итү, Потоцкийның улын, кызын әсиргә алу мисалында күрсәтелә. Әсирлеккә шулай ук Таганский, Полянский кебек поляк воеводалары да төшә.

Поэмада бу кальгаләр янында булган тарихи вакыйгалар аеруча күтәренке һәм патриотик рухта бирелгәннәр.

Укучыга поэманың эчтәлеген якынанрак аңлату өчен аның кайбер бүлекләренә махсус тукталырга кирәк таптык.

IV бүлектә, мәсәлән, Тугәйбәйнең походы, кыскача тәрҗемәи хәле, аның ничек итеп запорожецлар белән берлектә Польшага каршы булачак поход юлбашчысы сайлаулары турында сөйләнә. Польша короленең ничек итеп һәм нинди максат белән сугышка хәзерләнүе, Украинаның кулда иткәннән соң, Кырымны алырга җыенып план төзүе күрсәтелә. Планын конкретлаштырыр өчен хәрби

совет чакыра. Киңәшкә килгән гаскәр башлыклары паннарга немец һәм французлар ярдәм итәчәген әйтәләр. Корольнең планнарын вельможалар, паннар кабул итә. Советта катнашканнарның берсе Бар кальгасының коменданты Потоцкий (поэмада Ботавский) походны бер елга кичектерергә һәм аңа кадәр запорожецларны кулга төшерергә киңәш итә. Король бу киңәшне кабул итә һәм Потоцкийны 40 мең гаскәр белән запорожецларга каршы җибәрә. Потоцкий исә 80 мең гаскәр туплап, кече улын полк командиры итеп билгели.

Запорожецларның атаманы Мәләскә (Хмельницкий) полякларның үзләренә хәзерләнгән һөҗүме турында белеп ала һәм җыен җыя. Нәкъ менә шул җыенда Кырым ханына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә дигән карар бирелә.

Запорожецларның вәкиле Фәрах Кәрман Тугайбәйгә килә. Алар бергәләп барып ханга запорожецларның хәлен сөйлиләр. Хан аларның теләкләрен кабул кыла һәм ярдәм итәргә сүз бирә. Тугайбәйне ул полякларга каршы хәзерләнгән гаскәр башына куя. Тугайбәй гаскәр туплап, бер атнадан соң походка китә. Татар гаскәре Днепр (Озу) янында Хмельницкий полкына кушыла. Бу вакытта Потоцкийның улы 40 мең гаскәр белән һөҗүм итә һәм җиңелә.

V бүлектә Потоцкийның походы хакында языла. Ул улының нинди афәткә очраганын белмичә, кырымлылар һәм запорожецлар өстенә килә.

Гаскәрләр Днепрдә капма-каршы киләләр. Потоцкийга улының җиңелүен һәм әсир төшүен хәбәр итәләр. Ул татар гаскәрнең Тугайбәй идарәсендә полякларга каршы килүен белеп гаҗәпләнә. Һөҗүм башлый. Бу сугышта Потоцкий һәм аның угыл-кызлары, Таганский, Полянскийлар әсир төшә. Татарлар бик күп крепость һәм

авылларны алалар, күп мал кулга төшерәләр. Җиңгәч, оч көн буенча бәйрәм итәләр. Менә ике бүлекнең кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт.

Сөекле Украина җирләрен тышкы интервентлардан чистартканнан соң, халык бәйрәм итә. Шулай кырым татарлары украин халкын Польша паннары золымыннан коткаруда (...) тарихи һәм сәяси роль уйныйлар.

(...) Кырым татар халкы иҗатында Богдан Хмельницкийның, Тугайбәйнең Польшага ясаган походына багышланган «Сәфәрнамә» исемле (авторы билгесез) тагын бер поэма бар. Алар һәммәсе – бездән үзләренә карата игътибар һәм дөрес анализ бирүне сорый торган әсәрләр.

*«Кызыл Кырым», 1939 ел, № 94.*

## ГОМӘР ИПЧИ
## (АЛКЕДАЙ)

Ипчи – кырым татар әдәбияты тарихында бик тә үзенчәлекле урын тотучы язучы. Ул үзенең 20 еллык иҗат юлында төп жанрлардан поэзия, проза һәм драматургия өлкәсендә кырым татар совет әдәбиятына тырышып хезмәт итте, итә һәм тагын да хезмәт итәр ...

Гомәр Ипчи 1897 елда Бакчасарайда һөнәрче гаиләсендә туа. 6-7 яшендә башлангыч мәктәпкә керә һәм шул ук вакытта һөнәр өйрәнү өчен оста янында да эшли башлый. Ике ел эчендә башлангыч мәктәпне бетереп чыга. 1905 елга кадәр бакчаларда ялланып эшли һәм Тавдаер мәдрәсәсендә укый. 18 яше тулганда Ипчи, империалист армиясенә бармас өчен, Кырымнан Уфага кача. Уфада «Галия» мәдрәсәсенә ирекле тыңлаучы булып керә. Ул анда әдәбияттан билгеле бер дәрәҗәдә белем ала, бу белем исә аның әдәбиятка булган һәвәсен уята. Бу хакта язучы үзе: «Мин аеруча әдәбият дәресен ярата идем, ул вакыт безнең әдәбият укытучыбыз хәзерге Казан татар әдәбиятының алгы сафында булган Галимҗан Ибраһимов иде», – ди.

1917 ел февраль революциясенә кадәр Ипчи Уфада укый һәм азмы-күпме язгалый. Аның ул вакыттагы әсәрләре тема ягыннан әле тар планда кала һәм пассив характерда була. Бу чорда ул «Мәдрәсә» дигән шигырь һәм шигъри

пьеса иҗат итә, үзе үк уйнаучысы була (бу әсәр басылып чыкмаган). Шулай итеп Ипчи яшьтән үк сәхнәгә чыга башлый. Ул язучылык эшен башлаганда, һәр яшь язучы кебек, тәкълид, ияреп язу белән шөгыльләнә, аеруча Казан вак буржуаз татар демократик шагыйре Г.Тукайга ияру көчле сизелә, аның кебек шигырь язарга тырыша.

Моңа мисал буларак, аның зур күләмле һәм әдәби җәһәттән яхшы гына эшләнгән «Газый-Мансур» поэмасын күрсәтергә мөмкин (Бу әсәр бер яктан дини миф рухы белән сугарылган булса, икенче яктан «Кисекбаш» кебек легендага нигезләнгән һәм буржуаз реакцион романтизмга корылган әсәр) (...)

Шулай итеп, Ипчи буржуаз революцияне, аны турыдан-туры аңлый алмыйча, милли буржуазиянең тәэсире астында, аннан рухланган хәлдә каршы алды. 1921-1922 елларга кадәр милләтчеләрдән һәм аларның тәэсиреннән аерыла алмады. Моны Ипчи иптәш «Яңа дөнья» газетасына язган мәкаләсендә үзе дә әйтә (1935, декабрь). Ләкин Ипчи иптәш бу милләтчелек баткаклыгыннан чыга, 1923 елның башында ул, Кырым Дәүләт татар театры төзелү уңаеннан, анда артист сыйфатында чакырыла. 1924 елда исә «Яңа дөнья» газетасы идарәсенә хезмәткәр булып урнаша, 1928 елга кадәр шунда эшли. Ул инде бөтенләй башка бер обстановкада милләтчелек һәм аның тәэсиренә каршы көрәшә башлый. Пролетар революция белән бергә үсәргә омтыла, үз ялгышларын төзәтергә, искелеккә, хансарайга, милләтчелеккә нәфрәт итеп әсәрләр яза.

Мәсәлән, 1923 ел милли фиркачыларның аерым язучыларын сатира шәкелендә шигырьләрендә тәнкыйть итте. Ул үзенең 1923 елгы «Егеткә» дигән шигырендә «егетлек» даның сатып йөрүче милләтче «Дон-Кихотлар»га болай ди:

*Куптәнме милләт өчен кайгырыр,*
*Моңаер, һайкырыр елап?*
*... Мәрхүм Дон-Кихот агай да*
*Бу дәрт белән дәртләнеп таныйды.*
*Җил тегермәннәре корып, аларга*
*Каршы егетләрдәй сугышты, –*

дип контрреволюцион милләтчеләрнең аерым язучыларына каршы каләм күтәрә. Бу шигырь милли фирканең актив шагыйрьләреннән берсенә карата язылган булса да, бөтен милләтче «Дон-Кихот»ны үзенчә тәнкыйть иткән сатира шәкелендәге бер шигырь. Шул рәвешле Ипчи аз гына вакыт эчендә милләтчеләрдән ераклаша, аларга «Дон-Кихот» дип, үз әдәби иҗатында иҗтимагый, сәяси характеристика бирүчеләрдән берсе була, алга таба бу юлны тагын дәвам иттерә.

Бу момент Ипчинең пролетариат революциясенә таба ничек үсүен һәм милләтчеләргә каршы көрәшен күрсәтүче характерлы бер нокта гына. Ләкин Ипчи моның белән бергә бу шигырьләреннән соң үзенең әдәби иҗатында һич кенә дә милләтчелек күрсәтмәде, андагы милләтчелек тәэсире бөтенләй бетеп китте дисәк, дөрес булмас. Ипчинең әдәби иҗатының беренче һәм икенче (1929-1930 елларга кадәр) этапларында революциянең бөтен мәгънәсен аңлап бетерә алмаганлыгы һәм милләтчелек тәэсиреннән әле тулысынча чистармаганлыгы, бер төркем шигырьләрендә милләтчелек юшкыны калганлыгы ачык күренә. Бу аның аеруча проза һәм драма әсәрләрендә күзгә ташлана. Моңа мисал итеп аның «Ачлык хатирәләре» хикәясендә ачлыкның иҗтимагый сәбәпләрен күрсәтүдән бигрәк, татарларның ачлыктан үлгәннәрен һәм башка милләтләрнең (румлыларның) ачлыктан котылу юлларын таба алуын күрсәтү кебек хәл өстенлек алган. Икенче

яктан бу хикәядә сыйныфлар бер-берсенә каршы куелмаганнар. Шундый ук формада «Кайлык базары» (1925) дигән хикәясе язылган. «Шаһингәрәй» (1929) кебек тарихи пьесаларында милләтчелек тәэсире ачык күренеп тора. Бу исә Ипчинең әдәби үсеш юлы шактый катлаулы һәм авыр булганлыгын күрсәтүче билге. Ипчинең әсәрләрендә милләтчелек тәэсиренең аерым-аерым этапларда баш күтәреп алуының төп сәбәпләре, Ипчинең үзенә тема итеп алган мәсьәләләрне бөтен тулылыгы белән аңлый алмавы һәм ул дәвердә әле әһәмиятен җуймаган буржуаз милләтчеләрнең тәэсиреннән тәмам котылып бетә алмавыннандыр.

Ипчинең югарыда аталган һәм аталмаган башка кимчелекләре соңгы вакытка кадәр һичбер тәнкыйтьче тарафыннан этрафлы итеп күрсәтелмәде. Аңа бу җәһәттән аз ярдәм ителде. Әдәбият башында Мусенниф һәм Гафуровлар булган вакытта, аның милләтчеләргә каршы (зәгыйфь булса да) язган «Кем юл адашты» («Ким йол шашырды») дигән шигыренә һәм башкаларына нигезләнеп, Ипчи үзе адашты дип, аны совет әдәбиятыннан ераклаштырырга тырыштылар.

Ипчи иҗатының икенче этабында 1923 елдан соң булган төп темалар һәм күтәреп чыккан мәсьәләләре турында түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Беренчедән, төп тема булып, Кырым авылларында барган үзгәрешләр, һәм урта хәлле крестьяннарның артель тирәсенә туплануларын һәм тупланырга кирәклеген яктыртырга тырышу тора. Мәсәлән, «Трактор» (1925) хикәясе һәм «Азат халык» пьесалары.

Икенчедән, беренче темага бәйле буларак, эксплуататорлар, морзаларның ерткычлыгын, аларның бозык тормышын һәм изүче сыйфатларын күрсәтү. Мәсәлән,

«Морзаның хатирә дәфтәреннән» (1926) дигән хикәясендә Бөек Октябрьдан соң эксплуататор морзаның Кырымның бәрәкәтле туфракларыннан, Петербургның «Ренессанс» ресторанынннан куылуы, Истанбулда «сөрлекчеләр» башлыгы буларак җанландырылган образы; «Хатип агай» (1927) хикәясендәге хатипның хәйләкәр образы әлеге фикерләрнең җанлы мисалы булып тора. Монда шуны да әйтергә кирәк, Ипчи иҗатының беренче һәм, кирәк булса, икенче этабында уңай типлар кирәгенчә эшләнмәгән һәм тулысынча җанландырылмаганнар. Моның төп сәбәбе ул вакытларда язучының илебездә зур темплар белән дәвам иткән үзгәрешләрне, алар тудырган яңа кешене тулысынча аңлап бетерә алмавы һәм аның белән якыннан таныш булмавы белән бәйле. Ләкин Ипчинең 1930 елда һәм аеруча партия өлкә комитетының 1932 елгы әдәбият турындагы тарихи карарларыннан соңгы иҗатында югары әйтелгән хәл бөтенләй башка якка үзгәрә. Ул әсәрләрендә тормышыбыздагы яңа обстановканы җанлы һәм куәтле итеп сурәтләргә омтыла. Ипчи әсәрләрендә яшьләр генә түгел, картлар да, татар хатын-кызлары да оптимист һәм перспективалы итеп биреләләр. Мәсәлән, «Очрашу» («Раст келиш») хикәясендә авылдан Акмәчеткә тегү фабрикасына килгән, анда яхшы эше өчен макталган Хәдичә образы – безнең татар эшче хатын-кызлары арасындагы үсеп килүче яңа социалистик пролетар кадрларның җанлы образы.

Янә дә Ипчи иптәшнең «Дошман» дигән пьесасындагы Асия образы бу 15 ел эчендә татар кызлары арасыннан үсеп чыккан яңа совет белгечләренең - докторларның төп сыйфатларын үзенә туплаган җанлы бер образ булып тора. Асия үз эшен яратучы һәм авырулар турында кайгыртучы көчле образ итеп бирелә.

Ипчи иптәш, әйткәнсбезчә, татар картларын да перспективалы, алдынгы карашлы, сыйнфый яктан ачык фикерле һәм большевистик оптимизмга ия итеп сурәтли. Мәсәлән, «Дошман»дагы Әмир Әхмәт ага һәм аның кебек «Ата» дагы Әмир Госман акай һәм башкалар моның матур үрнәге булып тора. Ипчинең әсәрләрендәге төп уңай типлар һәрвакыт перспективалы һәм сыйнфый яктан ышанычлы итеп күрсәтеләләр. Бу аның «Дошман» пьесасындагы Әмир Әхмәт образында аеруча ачык күренә. Колхозга кереп, колхозны эчтән бозарга теләгән сыйнфый дошманнарга каршы көрәш алып барган һәм дәрвишләрнең чын йөзен ачуда төп рольне уйнаган колхозчы Әмир Әхмәт карт, башка колхозчыларны уяу булырга һәм сыйнфый көрәшкә чакырып: «Хәзер кешенең күзе дә, колагы да үткер булырга тиеш, дошман йокламый», – ди. Язучы безгә колхоз эшенә тугрылыклы, сыйнфый дошманга каршы аяусыз көрәшкә һәрвакыт әзер булган колхозчыларның тормышчан образын бирә. Моннан башка Ипчи иптәш колхозчы картларның җанлы һәм тормышчан портретларын чынбарлыкка якын итеп сурәтли. Бу хәлне бик ачык итеп «Ата» («Ато») хикәясендәге Әмир Госман агай образында һәм «Картлар» дигән хикәясендә 78 яшьлек колхоз бакчасын каравыллаучы карт образында да күрәбез ...

Ипчинең әсәрләрендәге без күрсәткән уңышлы яклар белән бәрабәр аерым әсәрләрендә тиешле дәрәҗәдә эшләнеп бетмәгән нокталар да бар. Хосусан, аның хикәяләрендә кайбер типларны сурәтләү, аларның берберләреннән аерымлыклары, характер үзенчәлекләре йомшак эшләнгән. Кайбер хикәяләрендәге аерым типларны икенче бер хикәядәге образлардан аеру бик читен.

Ләкин Ипчинең пьесаларында, хосусан, «Дошман»ында аерым образлар үзләренә генә хас харак-

терлы итеп бирелгән. Шуңа күрә «Дошман»дагы типлар, хикәяләрендәге образлардан аермалы буларак, шактый конкрет һәм тормышчан. Бу җәһәттән Ипчи иптәш яшь язучыларга үрнәк була ала.

Ипчи иптәш бу пьесасында, башка мәсьәләләр белән бәйле рәвештә, мәдәни тормышыбызның иң актуаль мәсьәләләреннән берсе булган гаилә проблемасын күтәрә һәм аны дөрес хәл итәргә тырыша. Ул үлемгә дучар ителгән хаким сыйныфлар арасында мораль бозыклыкны һәм хатын-кызга карата булган кыргый (...) мөнәсәбәтнең һәм гаиләдәге суыклыкның нәрсәгә китерүен күрсәтә. Моның белән бергә Ипчи хатын-кызлар арасында моральэтик бозыклыкны таратучы Ләйләләрнең, ягъни яңа тормышка иске мещанкалар кебек караган, үзе турында гына уйлаган хатыннарның җанлы образларын да бирә.

*Ләйлә.* Чынлап әйтәсеңме,

*Асия.* Әйс, чынлап әйтәм.

*Ләйлә.* Син аны ярата белмисеңдер (*Асиянең күлмәген тотып карый*). Күлмәгең бик килешә! Ничә күлмәгең бар, әйт әле?

*Асия.* Өч күлмәгем бар.

*Ләйлә.* Барлыгы өчәү генәмени? Ә костюмың?

*Асия.* Берәү.

*Ләйлә.* Бары тик бер генә? Минем уникс күлмәгем, дүрт костюмым бар. Бер гардероб тулы. Хәтта гардеробка да сыймыйча, әрәм булып җирдә яталар. Кисәң, сиңа бармак белән төртеп күрсәтәләр. Коммунистларга каршы дип, белмим, артыңнан мыскыллап әллә ниләр сөйләнәләр. Күлмәкләремне нишләтергә дә белмим. Барысын да җыеп толчокка чыгарып сатыйм микән дим. Уникс пар аяк киемем бар. Әле дүртесен беркая да кием чыкканым юк. Бигрәк кызганыч.

*Асия*. Каян җыйдың ул кадәр аларны?

*Ләйлә*. Әллә син белмисеңме? Хәлил минем өченче ирем бит.

*Асия*. Ә тегеләренә ни булды?

*Ләйлә*. Тегеләреме? Аердым. Яши белмиләр. Тагын да дөрессрәге, (*әкрен тавыш белән*) балалары булмады. Бала телим мин.

*Асия*. Я, ул баланың сиңа ни кирәге бар?

*Ләйлә*. Менә телим шул, шул кадәр әвәс иттем ...

*Асия*. Булмаганы яхшы.

*Ләйлә*. Нигә алай дисең?

*Асия*. Нигә ул сиңа бала-чага?

*Ләйлә*. Анысы шулай да шул, эмма ...

*Асия*. Күрдеңме менә, мин ялгышмаганмын. Син баладан да, ирдән бизгән кебек, бизәчәксең ...

*Ләйлә*. Син ни сөйлисең? Югыйсә, өенә алып килеп, минем җанымны көйдерергә теләүче синме? («Дошман», 24 бит).

Менә бу өзектә хәзерге көн гаиләсендәге актуаль мәсьәләләрнең берсен куеп, безнең партия сафларында тәрбия алган һәм бөтенләй башка, социализм кешесе булып җитешүче Асия тормышка «кулындагы кошчык»ка караган кебек караучыларны тәнкыйть итә. Ипчи шул рәвешле мондый мәсьәләләр төп максат итеп куелмаган үз пьесасын тагын да тормышчанрак итә, геройларны характерларына карап хәрәкәт иттерә. Аларга хас булган мәсьәләләр турында сүз кузгата. Әгәр Ләйләнең Асия белән көрәшендә аның сүзләренә һәм үз-үзен тотышына карасаң, тормышка Ләйлә кебек мөнәсәбәттә торучыларның типик образы җанлана.

Кыскасы, Ипчинең «Дошман» пьесасы безнең үсеп килүче драматургиябезгә һәм эчтәлеге, һәм дә формасы

ягыннан яңалык алып килде. Бу яңалык, беренчедән, сыйнфый дошманга каршы яңа көрәш ысулларын сәхнәдә оста итеп җанландыру һәм аның тирәсендә, төп темага зарар китермичә, бер төркем мәсьәләләрне җыеп, чынбарлыкка нигезләнеп чишәргә омтылу. Ипчинең бу пьесасы драматургиябез үсеше өчен әһәмиятле. Персонажларның сүзләре кыска һәм ачык булуы, вакыйгаларның бер-беренә бәйле рәвештә бер сюжет линиясендә дәвам иттерелүе бу пьесаны аның башка пьесаларында һәм прозасында булган кимчелекләреннән коткара һәм язучының бүгенге совет драматургиясе алга сөргән төп сыйфатларны үзләштерергә омтылуын күрсәтә. Югыйсә, аның моңа кадәр язылган пьесаларының күпчелеге драматургиянең иң әһәмиятле сыйфатларына ия булып җитә алмаган иде. Мәсәлән, «Азат халык» тагы Җафәрнең ярты сәгать буена дәвам иткән эчпошыргыч доклады пьесаны прозага яки публицистикага әйләндерә башлый.

Моннан кала, Ипчинең «Дошман» һәм «Фахишә»дән тыш башка пьесаларындагы персонажларның бөтенесе диярлек бертөсле сөйләшәләр.

(...) Бу хәл исә пьесаларның сәнгатьчәлеген пык төшерә. Алда әйткәнебезчә, Ипчи акрынлап бу сыйфатлардан котыла башлады. Аңа бу юнәлештә эшне дәвам иттерергә һәм югары дәрәҗәгә күтәрелергә, Шекспир кебек бөек классик драматургларны һәм рус совет драматургиясенең иң яхшы үрнәкләрен өйрәнергә кирәк.

Инде Ипчи иптәшнең әсәрләренең теле һәм пейзаж тасвирлары мәсьәләсенә күчәбез, чөнки матур әдәбиятта образларны бирүдәге төп чараларның берсе шулдыр. Ипчи, гомумән, үзенең образларына туры килердәй сүзләр сайлый. Ул сүзләр ярдәмендә үз образларын характер һәм тип итеп бирә ала. Ләкин безнең әдәбиятыбызда бу мәсьәлә (әдәби

әсәренең теле) ни теоретик җәһәттән, ни дә практик җәһәттән эшләнмәгән. Болар – совет әдәбияты теоретикларының һәм гыйльми-тикшеренү институтларының алдында торган, якын арада өйрәнелергә тиешле мәсьәләләр. Ипчи иптәшнең теле, югарыда әйтелгәнчә, төзек һәм ачык аңлаешлы булса да, аның моңа кадәр язган әсәрләренең теле әле тиешенчә, образларның чын йөзенә туры китереп эшләнмәгән иде. Аның элекке әсәрләрендә һәр образга туры килерлек сүзләр сайлау мәсьәләсе күпмедер дәрәҗәдә зәгыйфь, образларның индивидуальлеге тел байлыгында, хәтта җөмлә төзелешендә күренми. Укучы образның сүзләренә карап, аның кем булуын, нинди иҗтимагый тип булуын аңлый. Һәр образ бер тел белән, автор теле белән генә сөйләшсә, образларның җанлылыгы, индивидуальлеге җуела.

Образларның һәрберсенең үз теле булганда әсәрнең никадәр тасвирлы икәнлеген Ипчи күпмедер дәрәҗәдә «Хатип агай» хикәясендәге һәм «Фахишә» пьесасындагы персонажларның һәм дә «Дошман» пьесасындагы типларның телләрендәге характерлы моментлар белән аңлатып бирә. (...) Мәсәлән, «Дошман» пьесасында кулак тибы Сәрвәрнең теленә игътибар итсәк, бу контрреволюцион типның сүзләрендә, интонациясендә аның колхоз хәрәкәтенә каршы булган ачуы күренеп тора: «Ни эшлим соң, кардәшем, йөрәгемә тулган ачу бугазыма тыгыла! Әгәр бу колхозда син булмасаң, мин хәзер үк бу колхозны ягар идем. Мине хозяйствомнан, сездән, бар нәрсәдән аердылар. Ни эшлим соң, син барсың, син булмасаң, күземә берни дә күренмәс иде. Баласын-чагасын, малын-мөлкәтен – барысын ягар идем». Шулай итеп Ипчи иптәш сыйнфый дошманга конкрет обстановкада, сүзләрне үтемле итеп кулландырып, дөньяга карашын ачып салырга

мөмкинлек бирә. Дошман ачуының тирәнлеген аңлатыр өчен, фикеренә куәт бирер өчен, язучы «баласын-чагасын, малын-мөлкәтен» кебек парлы сүзләр дә куллана.

(...) Ипчи иптәш моның кебек сыйнфый дошманнарга каршы аяусыз көрәшкән колхозчыларның телен сыйнфый яктан тотанаклы һәм көчле итеп эшли. Ул телне чыннан да әдәби образларны характерлы һәм типик формада бирү өчен кирәкле бер чара итеп куллана. Менә Сәрвәрнең һәм аның кебекләрнең ерткычлыгын фаш иткән, аларны капканга эләктергән Әмир Әхмәт ака: «Сынган сөягеңне таптыңмы? Инде ятарсың, туйганчы йокларсың. (*Сәрвәргә*) Нәрсә суга баткан мәче кебек карыйсың? Әйдә, сикер ... йөр ... Йөри алмыйсыңмы? Бәлки башка күрешмәбез. Барсаң, мәрхүм атаңнарга сәлам әйтерсең (...) – дип мыскыл итә.

(...) Шул рәвешле Ипчи тизлек белән формалашып килүче әдәби телебезнең ачык һәм матур булуы өчен хезмәт итә.

Әдәби иҗатының башлангыч этапларында аңа милләтчеләрнең тел сәясәтенең тәэсире булмады дип әйтеп булмый. Ипчинең беренче этап әсәрләрендә торекчелек үзен күрсәтә әле. Ул вакытларда татар буржуазиясенең тел сәясәте шундый иде. Партия юлбашчылыгы астында телебез мондый тәэсирләрдән котыла бара. Хәзер барлык хезмәт иясе халкына аңлаешлы чын, матур, уңайлы кырым татар әдәби теле формалаша. Менә бу процесска Ипчи иптәш тә актив катнаша. Пейзаж Ипчинең әдәби иҗатында беренче һәм икенче этапларда бөтенләй юк дәрәҗәсендә, булганнары да бик йомшак эшләнгән иде. Ләкин аның соңгы еллардагы иҗатында орденлы Кырымыбызның бай пейзажы бик оста итеп эшләнгән һәм образларны ачуда зур роль уйныйлар. Мәсәлән, «Амо» хикәясендә Кырым пейзажының колхозлашкан авылның перспективасын, опти-

мист карт образларын күрсәтү өчен хезмәт итүен күрергә була: «Һавада диңгезнең сулышын, җам агачларының исен тоясың, хәтта ташларның да исе бар. Йөзем, тотен (тәмәке – Ә.С.) яфраклары хуш исләрен тарата. Диңгез, җам, бакча, төтен чәчәге, таш, кипарис – бөтенесенең исе бер урынга җыелып, гаҗәеп бер хуш ис хасил итә. Бу гүзәл ис борыннарга үтеп кереп, кан тамырларына тарала, сине бердән рәхәтләндереп, исертеп җибәрә. Моннан да татлы тагын нәрсә бар? Бу матурлык, бу рәхәтлек, бу байлыкны «Амо» машинасына утырып, бормалы, әйләнмәле юлларда тамаша кылудан да шәбрәк нәрсә булырга мөмкин?» (Өмир Госман аганың сүзләре). Ипчи революциягә кадәр фәкыйрь авылларга, гомумән, эшче сыйныфка төрмә һәм хезмәт зинданы булган яр буеның бүгенге матурлыгын хакыйкый бер әдип каләме белән күрсәтә алган. Өмир Госман агай мисалында миллионнарның бу матурлыктан зәвык алуын, Кырымның хуш исле һавасыннан, кояшыннан рәхәтләнгәнен (...) белдерә.

(...) «Диңгез инсанның күзен үзенә тарта, әйтерсең, сихерли. Аның зәңгәр төсеннән күзне алып булмый. Гел аңа гына карап торасы килә.

Диңгез бик киң һәм тыныч. Ул ярдан алып офыкка кадәр дәвам итә, күк белән кушылган җирдә аз гына сизерлерлек бер сызык буйдан-буйга сузылган. Диңгезнең төсе күк төсеннән бераз куерак, әгәр аларның төсе дә туры килсә, күкне диңгездән аерып та алып булмас иде», – ди.

Аның бу картинасы әсәрнең гомуми фоны һәм идеясе белән тыгыз рәвештә бәйләнеп килә. Ипчинең Кырым пейзажларын оста тасвир итүендә бу иң әһәмиятле момент булып тора.

(...) Ипчи иптәш үзенең егерме еллык әдәби хезмәте белән кырым татар теленә дөнья классикасын һәм совет

пролетар язучыларының кыйммәтле әсәрләрен тәрҗемә итү ягыннан да зур эш башкарды. Бүген дә киң масса хезмәт ияләре Ипчинең тәрҗемәсе булган дөнья классикларыннан Шекспирның «Гамлет»ын, Шиллерның «Юлбасарлар»ын, Мольерның «Дворянлыкта мещанин»ын, Островскийның «Гроза»сын яратып укыйлар. Икенче яктан Гогольнең үлемсез «Үле җаннар»ын һәм бөек совет пролетар классигы М.Горькийның кыйммәтле әсәрләрен аның тәрҗемәсендә уку мөмкинлеге бар. Ипчи иптәшнең бу хезмәте яшь әдәбиятыбызның үсешенә һәм хезмәт иясе халкының мәдәни күтәрелешенә керткән зур өлеше дип санала ала.

Ипчи, язучылык һәм тәрҗемәчелектән башка, тагын безнең кинематографиябезгә «Галим» кебек киң халык массасы арасыннан чыккан герой образын биргән сценаристыбыз да. «Галим» картинасы, аның сәхнәгә куелган пьесалары кебек үк, халык тарафыннан яратып карала.

Ләкин бүгенге совет җәмәгатьчелеге үз әдәби хезмәтенең егерме еллыгын бәйрәм итүче әдипкә яңа һәм зур таләпләр куя. Ул җәмәгатьчелеккә тагын да якынаерга һәм аңа тирән эчтәлекле әдәби әсәрләр бирергә тиеш (...)

# ХАТИРӘЛӘРЕ

## КЫРЫМ АНЫҢ ӘДӘБИ ВАТАНЫ БУЛДЫ

1936 елның көз айлары ... Без Галимҗан агай янында. Күрешеп исәнлек-саулык сорашкач, сүз Кырымның табигате турында башланып китте. Галимҗан ага сабыр гына үзенә хас булган тыйнаклык белән шаяртып әйтте: «Кырым дөньяның иң матур, иң мәгънәле, иң тирән тойгылар уяткан бер почмагы ул. Ул минем яңа әдәби ватаным булып китте. Мин моннан 9 ел элек булган хәлемдә идем. Халәт кулдан төшкән, көч беткән иде. Шифалы саф һава, диңгез, сөекле кояш йөрәккә дәрт, көч бирде. Бер елдан соң яңадан каләм кулга кайтты. Акрынлап булса да, яңадан эшкә тотындым», – дип куйды. Чыннан да, 1929 елдан алып Галимҗан ага иҗатында яңа бер гомер башланып китте. Ул монда (Ялтада) үзенең барлык иҗат юлын карап чыкты, гыйльми, әдәби хезмәтләренә кирәкле төзәтмәләр, үзгәрешләр кертә барды. Аның үзе әйтмешли, «Безнең көннәр»е дә яңадан туды. Яңа бер характер алды һәм композицион һәм мәгънә тирәнлеге ягыннан матурланды, көчәйде. Бу соңгы елларда, гомумән, Совстлар Союзы күләмендә әдәби, гыйльми фронт бик алга китте. «Мондый шартларда, егетләр, безгә дә артта калмаска кирәк», – дип куйды Галимҗан ага сүзләрен дәвам иттереп, – көч-дәрт барда узганнарны тәнкыйть күзлегеннән уздырып чыгып, киләчәккә зур этаплар белән кереп китәсе иде», - диде. Очрашулар дәвамында ул күбесенчә әдәби-

гыйльми гомернең бәхетле киләчәге турында сөйләде. Миңа аның янында ун кат булырга туры килде. Күренекле галим, тәнкыйтьче профессор Г.Нигъмәти, зур драматург К.Тинчурин һәм көчле әдип Шәриф ага белән Галимҗан ага янына бергә йөрдек. Алар миннән соң да Ялтада калдылар.

## КАВИ НӘҖМИ ТЕЛЕГРАММАСЫ

Шул ук 1936 елның көзге айлары иде. Кырым язучылар союзына К.Нәҗминең Казаннан биргән бер телеграммасы килгән. Ул телеграммасында: «Татарның күренекле ике зур язучысы профессор Г.Нигъмәти белән К.Тинчурин Кырымга киттеләр. Аларны каршы алуыгызны үтенәм. Татарстан Язучылар правлениесенең башлыгы К.Нәҗми». Телеграмма Казаннан сугылган, аларның Мәскәүдән кайчан, нинди поездга утыруларын белү һич тә мөмкин түгел иде. Шулай булуга карамастан, без Мәскәүдән килгән поездларның барысын да диярлек каршы алып торсак та, Казаннан беркем дә килеп чыкмады. Берничә көн узгач, минем исемгә Ялтадан бер хат килеп төште. Бу хатны Г.Нигъмәти язган булган. Ул үзенең хатында К.Тинчурин белән бергә махсус Г.Ибраһимов янына килеп чыгуын, Ялтада бер ай булырга тиешлеген яза, мөмкинлек табып алар янына килеп чыгуын үтенә иде. «Кәрим. Без Ялтада язучыларның ял йортында. Син килеп чыксаң, синең хезмәтең турында да конкрет сөйләшер, бергәләп фикер алышыр идек». (Сүз минем Кырым халык шагыйре Ш.Туктаргазый һәм аның Тукай белән бәйләнеше турында язган хезмәтем турында бара иде). Мин ул вакытларда Симферопольда Тел-әдәбият гыйльми тикшеренү институтында эшли идем. Тизрәк рөхсәт алып Ялтага юнәлдем. Монда Нигъмәти, Тинчурин дә бар иде. Мин аларга К.Нәҗми

телеграммасын, шул телеграмма нигезендә Симферополь вокзалында кунакларны ничек көткәнебезне әйткәч, алар барысы да көлеп җибәрделәр. Нигъмәти борынын тирән тарта-тарта: «Әй сине Кави, Кави, нәрсәләр буташтырган, аның мондый гадәтләре була торган иде шул, ул безгә бернәрсә дә әйтмәде. Без Мәскәүдән Симферопольгә юл тотып, Ялтага килеп төштек. Симферопольдә тукталырга уйламаган идек». Бераз гына утыргач, хәлләр белешкәч, Г.Нигъмәти үзенең Ялтага килүенең төп максатын сөйләп бирде: «Татарстан партия өлкә комитетының кушуы буенча мин Г.Ибраһимовның әдәби, гыйльми үсеш юлларын чагылдырган бер хезмәт язарга тиеш. Әгәр дә мөмкинлек була икән, әдипнең сәламәтлеге рөхсәт итә икән, киләсе, ягъни 1937 елны, Ибраһимовның юбилеен уздырырга, аны вакытлыча Казанга кайтарырга да ният бар. Ул сүзләрен дәвам иттереп, бу җитди хезмәтне язар өчен, язучының үзе белән килешеп эшләргә кирәк. Менә без К.Тинчурин, Шәриф ага һәр көнне иртә белән 9-10 нарга Ибраһимов янына барып чыгабыз. Аның белән очрашабыз, сөйләшәбез, иртәгә сине дә алып барабыз», – диде. Вакыт килеп җитте. Дүртәүләшеп без дә Галимҗан ага янына киттек. Ул безне зур, киң баскычлардан басып кергәндә зур бер залның урта җирендә, киң өстәл янында, үз креслосында киләсе кунакларны шатлык белән көтеп тора иде. Профессор Нигъмәти залга кереп җитәр-җитмәс: «Исән-саумы, без бүген дүртәүләшеп килдек, – дип мине тәкъдим итте. Галимҗан ага: «Бик шәп булган, без аның белән күптән диярлек таныш булсак кирәк. 1933 елның август айларының кызу көннәре булса кирәк иде. Сез яшь комсомол шагыйрь (...) белән килеп чыккан идегез бугай. Аларның килүләре бигрәк тә шуның белән истә калган. Алар миңа тик Кырымның әдәби халәте турында түгел

дә, Казандагы Бишбалтадагы кайбер хәбәрләрне дә әйткән иделәр. «Сезнең иптәшегез безнең Казанның Бишбалта кызы бугай. Ул Бишбалтадагы Абдрахман Рәшитовлар, алар квартирасына һаман килеп торган шагыйрьләр, әдипләр турында да сөйләделәр. Шулай булгач, Кырым безгә ике яклы кунак», – дип шаяртып көлеп куйды.

## ИКЕ ГАЛИМ АРАСЫНДА БЕСЕДА БАШЛАНЫП КИТТЕ

– Узган көнне әйткәнемчә, әдәби-гыйльми иҗатымны аерым чорларга бүлү турында озак сөйләшергә кирәкмәс дип уйлыйм. Ул хәзер сиңа да, миңа да бик ачык, – диде Галимҗан ага. Ниләр күз уңыннан төшеп калган, нинди проблемалар безнең алда торырга тиеш, – менә, минемчә, төп тема шул булырга тиеш. Андый китап язганда урыны-урыны белән иҗат юлымны кирәгенчә чагылдырырсың, синдә моңа көч тә, марксистик белем дә җитәрлек, хәтта артып китәрлек дип әйтергә була, – диде Галимҗан ага сүзне дәвам иттереп, – безгә, гомумән, әдәби тәнкыйтьнең характеры, син язарга уйлаган китапларның төрләре турында сөйләшәсе иде. Бу өлкәдә безнең бик күп кимчелекләр бар шул. Әдәби тәнкыйть әсәрләре киң массага җитми калалар. Алар бик аз укыйлар. Моның берничә төп сәбәпләре шулар булса кирәк. Беренчедән, аларның язылу стиле бик фәкыйрь, җансыз, көчсез. Менә Белинский, бигрәк тә Добролюбов иҗатларын алыйк, аларда тирән художестволы публицистика, тирән гыйльми нигезләр бар (...). Шулай булгач, болар укучыны үзенә тарта, аны тәрбияләүгә зур хезмәт итә. Бездә исә, фәнни нигезсез булган социологизм, шаблонга әйләнеп киткән карашлар өстенлек алса кирәк.. Болардан башка кирәкле дәрәҗәдә объектив карашларның булмавы, художестволы сәнгатьнең табигатен тирәннән белеп җитмәү әдәби тәнкыйть, рецензия язучылар арасында группачылык тудыра булса кирәк. Хәзерге

көндә марксистик-ленинизм тәгълиматларын тирәннән аңлап, әдәби тәнкыйтькә тотынучылар кирәкле дәрәҗәдә өлгереп җитмәгән шул (...). Рус галимнәре, тәнкыйтьчеләр бу хәлләрдән арынып баралар. Безгә алардан үрнәк алырга өйрәнергә кирәк. Бездә бүгенгә чаклы мемуарлар, аерым әдип һәм шагыйрьләребез турында тулы монографияләр юк. Тукай турында барыбызның язганнарыбыз әле шагыйрьнең зурлыгын, талант киңлеген бер дә күрсәтә алмый. Безгә Тукай турында зур мемуарлар язар заман җитте дип уйлыйм. Сәламәтлек рөхсәт итә икән, бу турыда нәрсәләрдер язу уе да юк түгел, – диде Галимҗан ага.

– Сүз уңаеннан, синең турыда язам дигән китапның формасы, стиле турында бер-ике сүз әйтәсе килә, – диде профессор Нигъмәти, сүзен дәвам иттереп: «Минем усмча, китап М.Горький тарафыннан башланган «Иң яхшы кешеләр тормышы» дигән китаплар сериясе формасында, һич югы, аңа туры килә торган бер формада булса иде, дип уйлыйм. Бездә бу бер башлангыч булыр иде дип ометләнәм. Чыннан да, әдәби тәнкыйть өлкәсендә зур галимнәребез, язучыларыбыз турында язылган хезмәтләрдә тирән художестволы публицистика булмавы, аларны бик фәкыйрь, аз укылучан итә шул», – дип, Г.Ибраһимовның сүзләрен раслады. Галимҗан ага, үзенең арганлыгын сиздермәс очен һәм аларны тыңлап торучыларны да ардырмау нияте белән, сүзне бераз читкә алып китте. Кешеләрнең ничек ял иткәнлеген, әдәби иҗат эшенең ничек барганлыгын сорарга кереште. Без, ике Галимҗан, фән, әдәби тәнкыйть турында кызып киттек тә, иптәшләрне бөтенләй оныттык, – диде. К.Тинчуринның ялы, дәвалануы турында сораштырып алды. Нинди ысуллар белән дәваланасың, дип сорады. Борынын тирән тарта-тарта җавапны Г.Нигъмәти бирде. Аны велосипед белән айга, күккә үрмәләтәләр. Ул үзенең «Зәңгәр шәл»ендәге Галәветдине кебек айга менмәкче була. Тинчурин, син кайда, әллә менденме айга,

– дип көлеп җибәрде. Утырганнарның барысы да елмаешып алдылар. Галимҗан ага: «Моңысы ярый. Корсак маен бераз киметергә кирәк, ул йөрәккә зарар китерә, аның өчен айга түгел, әллә кайларга менәрсез шул, Кәрим», – дип, көлде. Шулай да бик аз сүзле булган Шәриф ага: «Бу көннәрдә эшләр тукталып тора, «Матур туганда» романы язылмый. Сәбәбе – кәгазь бетте. Кәгазь өчен Казанга кайтырга дип торганда, Нигъмәтиләр килеп чыктылар да минс юлдан калдырдылар», – дип, моңаеп алды. Галимҗан ага бик сабыр гына Шәриф агага текәлеп карап торды-торды да: «Әй, син Шәриф, Шәриф, бер дә үзгәрмәгәнсең, шул кадәрле йомыкыйлык, хатын-кыз кебек оялчанлык буламы соң, кәгазь кытлыгы бар икән, ул бит бөтенләй табып бирә алмаслык түгел, кирәк икән аннан да зуррак эшләр эшлиләр, безгә бик күп булышалар. Миңа күптән әйтәсең калган.

Әйтсәң, егетләр сиңа кәгазь түгел, әллә нәрсә дә табып бирерләр иде. Алар белән мин хәзер сөйләшермен, бар да булыр. Тизлек белән «Матур туганда»ң матур булып дөнья күрсен иде.

Чыннан да, икенче көнне иртүк Ялтадагы китап магазинының мөдире, элеккс «Яшь куәт» («Яшь көч») газетасында диспетчер булып эшләгән Кадыйр иптәш Шәриф агага дип берничә зур конгора дәфтәрләрс алып килде. Ләкин ак кәгазь хәзергә юк, озакламый булыр, аларын да китерербез. Без һәм Кырым укучылары сезнең романны көтәбез. Эшләрегез уңай булсын дип, дәфтәрләрне Шәриф агага тәкъдим итте. Шулай итеп, Галимҗан ага ярдәмендә «Матур туганда»ның язылуы дәвам итте. Шәриф ага иртәгесе көнне: «Галимҗан, сиңа күп рәхмәт, кәгазь булды, шатлыктан тон буена яздым, эш җайланды», – дип, үз рәхмәтен белдерде.

## БЕЗГӘ ГЫЙЛЬМИ ҮЗӘК КИРӘК

– Хәзерге чорда гыйльми үзәксез алда торган зур бурычларны үтәү мөмкин түгел. Аның өчен безгә берничә гыйльми үзәк кирәк булыр, – дип, сүзен башлап җибәрде Галимҗан ага. Заманында Татарстан халык мәгариф комиссариаты янында барлыкка килгән Гыйльми үзәк, ничек тә булса, үз бурычларын күптән үтәде. Бу инде узганның эше булып калды. Безнең әдәби, мәдәни байлыкларыбызны дөньяга чыгару өчен тырышырга кирәк. Моның өчен башта иҗади кадрлар әзерләү, булганнарын бер үзәккә берләштерү эше тора. Синең бу хактагы фикерләрең ничек? – дип, Галимҗан Нигъмәтидән сорады.

– Монысы бик дөрес. Хәзерге вакытта начармы, яхшымы, гыйльми кадрларның, әдәбиятчы – телчеләрнең күбесе techинститутының тел-әдәбият бүлегендә җыйналган. Аспирантура да бездә. Ләкин безнең төп бурыч – гыйльми кадрлар әзерләү түгел, ә укытучылар әзерләү. Шунлыктан бездәге көчләр киң күләмдә гыйльми эшләр белән шөгыльләнә алмыйлар, – диде профессор Нигъмәти.

Галимҗан ага:

– Дөресен әйттең, шуның өчен безгә Казан дәүләт университеты янында махсус татар теле, татар әдәбияты кафедраларын оештырырга кирәк. Яшьләргә университет күләмендә гыйлем биреп, алардан аспирантлар, гыйльми работниклар чыгаруны хәл итәргә кирәк. Монысы бер

гыйльми үзәк булса, икенчесе, иң яхшысы – безгә тел, әдәбият һәм тарих буенча гыйльми-тикшеренү институты төзергә күптән вакыт җитте. Моны барлык чаралар белән эшләргә кирәк, югыйсә, бу яктан без күп кенә республикалардан арттарак калабыз. Күпчелек милли республикаларның институтлары күптән эшли, уңай нәтиҗәләр бирә. Мисал өчен, Кырым институтын алу да җитә. Бу институт, гыйльми работникларга бай булмаса да, аның барлыкка китергән гыйльми хезмәтләре миңа билгеле. Бер-бер артлы фольклор җыентыклары, барлык фәннәр буенча диярлек терминология сүзлекләре чыгарып яталар. Кырым татар теленең ике томлык аңлатмалы сүзлеген, русча-татарча сүзлекләрне әзерләп бетерәләр. Аннан кала, борынгы әдәби байлыкны, күлъязмаларны җыйнап тәртипкә салалар. Болар барысы да бик зур, кирәкле эшләр. Алар мондый зур гыйльми эшләргә рус галимнәрен тарталар. Моннан ике ел элек тел һәм фольклор экспедицияләре оештырдылар. Бу мөһим эшкә академик Самойлович, күренекле телче профессор Дмитриевлар гыйльми җитәкчелек иттеләр. Моннан башка алар систематик рәвештә академик Гордлевскийдан, Бертельстан һ.б. дан гыйльми консультацияләр алалар. Безгә ни өчен болардан да яхшырак эшләргә момкин түгел? Хәзергә чаклы безнең бай фольклорыбызны җыйнау, өйрәнү, әдәбиятыбызның борынгы тарихын һәм хәзерге чорын язу кебек эшләр, дөресен әйткәндә, ярым кустарьчылык юлы белән бара. Мин бу уңайда хөрмәтле профессор Бәдигыйны мисал итеп алам. Ул бер үзе генә диярлек фольклорның аерым тармагын җыйнап баста килде. Шул ук Газиз Рәхимнәр борынгы чор әдәбияты тарихын бернинди марксистик карашлары булмаган хәлдә яздылар. Габдрахман Сәгъди исә бер ялгыз татар әдәбиятының хәзерге тарихын язды.

Хәзерге чорда мондый юллар белән эшләү зур гыйльми мәсьәләләрне хәл итү өчен мөмкинлек бирми. Аның өчен зур коллектив көчләр кирәк. Менә боларның барысы югарыда әйтелгән институтның һичшиксез кирәклеген әйтеп торалар. Минем фикеремчә, буласы институтның түбәндәге бүлекләре булса иде:

1) фольклор һәм борынгы әдәбият;
2) революциягә чаклы булган әдәбиятны өйрәнү;
3) аерым совет әдәбияты бүлеге;
4) тел бүлегенең диалектология, орфография, тел тарихы кебек бүлекчәләре булырга тиеш.

Шулай ук киң тармаклы тарих бүлеге дә булсын иде, бәлки театрыбыз тарихын, музыкабызны өйрәнү буенча да бүлекләр оешса, бары тик файда гына булыр иде. Бу бүлекләрнең барысы да бер юнәлештә марксистик күзлектән чыгып алга куйган бурычларны үтәргә тиешләр. Галимҗан ага сүзләрен дәвам иттереп:

– Аерым галимнәр, аспирантлар, борынгы бай тарихи кулъязмаларны җентекләп өйрәнсеннәр иде. Нигъмәти исә хәзер үк үзенең гыйльми кадрларына яисә аспирантларга, менә шушы кулъязмаларга тикшерүне тәкъдим итсә, бик шәп булыр иде, дип куйды. Мисал өчен, Кырым галимнәреннән Якуп Камалның 1930 елда Симферопольдә академик Самойловичның сүз башы белән чыккан шушы китабын алып күрсәтте. «Тюрко-татарская рукопись XIV века» («Нехдж-уль-фарадис»), «Нәһҗел-фәрадис» – безнең телебез, әдәбиятыбыз өчен дә бик кирәкле, гыйльми әһәмияткә ия булган бер зур кулъязма. Үз вакытында бу кульязма турында безнең Шиһабетдин Мәрҗани кайбер фикерләр әйткән булып, академик Самойлович әйтмешли, бу өлкәдәге эш шуннан алга китмәде. Безгә моның кебек һәм моңа охшашлы тарихи байлыкларны хәзерге

гыйльми күзлектән чыгып эшләргә кирәк. Г.Нигъмәти, татар әдәбияты кафедрасының мөдире буларак, моның кебек эшләрне киләчәктә туачак институтка калдырмыйча, бердәнбер гыйльми работнигына зур гыйльми эш итеп тапшырачак, һичшиксез, аның уңай нәтиҗәсе килеп чыгачак. Чыннан да, озакламый Казанда бу эш буенча аерым чаралар күрелә башлады. (Нәтиҗәдә, Яфаров Бәкернең X-XIV йөзләрдә Волга-Каспий болгарлары әдәбияты һәм «Нәһҗел -фәрадис» кулъязмасы турында хезмәте барлыкка килде). Профессор Нигъмәти Галимҗан аганың барлык тәкъдимнәренең, уртага куйган гаять зур проблеманың тулысынча дөреслеген белдереп, түбәндәгеләрне өстәде:

– Бик дөрес, татар әдәбияты, фольклоры, теле һәм тарихы мәсьәләләре кебек гыйльми эшләр хәзерге көндә, бигрәк тә, совет язучыларының I Бөтенсоюз съездыннан соң, партиянең әдәбият-сәнгать һәм тарих мәсьәләләре буенча махсус карарларыннан соң, тик бер безнең пединститутгагы татар теле һәм әдәбияты бүлеге кебек бүлекләрдә генә тулысынча хәл ителерлек эшләр түгел. Чыннан да, университетта татар теле, татар әдәбияты кафедрасын оештыру, Тел, әдәбият һәм тарих гыйльми институты булдыру заманасы күптән килеп җитте. Безгә, башка халыклар кебек, бай поэзиянең антологиясен эшләргә, тизлек белән үсә барган совет чоры әдәбиятының төрле үсеш этапларын, бигрәк тә әдәбиятның төрле кардәш халыклар әдәбиятлары, беренче чиратта, рус әдәбияты белән булган каршылыклы нәрсәләрен тулы өйрәнергә кирәк. Кадрлар мәсьәләсенә килгәндә, бездә, ягъни безнең кафедра каршында аспирантура булса да, ул тулысынча гыйльми эшләр өчен әзерлекле кешеләр бирә алмый.

Без Оренбург, Төмән һ.б. шуның кебек институтларда булган татар теле һәм әдәбияты кафедраларына укы-

тучылар әзерлибез, – диде Галимҗан ага, гомуми йомгак ясаган кебек: – әйтелгән бу эшләрнең реаль булып тормышка ашачагына өметләр шиксез. Язучыларны, барлык интеллегенцияне бу планны тормышка ашыру өчен көрәшкә әзерләргә кирәк. Бу яктан хәзергә чаклы безнең Язучылар союзы җитәрлек күләмдә инициатива күрсәтә алмый. Башка кардәш республикаларда тел, әдәбият буенча булган институтларның башында язучылар тора, гыйльми эшләрнең үтәлешен тәэмин итәләр, бездә дә шулай булса иде.

## ГЫЙЛЕМСЕЗ, БЕЛЕМСЕЗ ТИК БЕР ТАЛАНТ КЫНА ҖИТӘРЛЕК ТҮГЕЛ

Кырымның көзге көннәре җәй көннәреннән бик аз аерылалар. Тирән көз булуына карамастан, агачлар яшәреп, төрле чәчәк атып торалар. Без килгәнче, Галимҗан ага бу матурлыкларны күзәтеп, диңгез кырыена барып, иртәнге саф һавада сулыш алып кайткан. Без кереп барганда: «Бүген күңел бик шат, сез килгәнче саф дингез һавасын сулап кайттым. Егетләр, сез дә иртә белән, яисә моннан бушагач, диңгез кырыенда саф һава сулагыз. Ялтаның матур җирләрен карагыз. Моннан ерак түгел, Әмир-Бохар сарае дигән зур сарай бар. Анда крайны өйрәнү музее урнашкан. Анда бик кирәкле кулъязмалар бар. Алар арасында искә алынган «Нәһҗел-фәрадис»ның моңача билгеле булмаган варианты, Бакча-Сарай кустарьларының тулысынча татарча язылган уставлары бар. Соңгысы тел-термины ягыннан һәм кустарьчылыкның үзенчәлеген өйрәнү ягыннан бик кызыклы. Ялтага килеп тә Антон Павлович музеена бармау хата булыр. Әгәр бармаган булсагыз, вакыт табып, бу җирләрне күрергә кирәк, – дип куйды Галимҗан ага.

Профессор Нигъмәти, чалбарының уң балагын өскә тарта-тарта, шаяру сыйфатында:

– Без Ялтаны икенче бер ягыннан өйрәнә башладык, Галимҗан ага, – дип көлеп алды, һәм борынын тирән тартып куйды. Бу аның гадәтләреннән берсе иде.

Кәрим ага Тинчурин сүз аның турында барасын сизде дә: – Әйдә, барысын да әйтмәсәң дә ярар, житәр, шаяруыңны бетер, – дип куйды.

Чыннан да эш шулайрак булган иде. Без Галимжан агадан чыккач, урамда Ялтадагы спецкультура техникумының директоры очрады.

– Әйдәгез, кадерле кунакларны безнең техникумга алып барабыз, аз булса да, безнең байлык белән аларны таныштырабыз, – диде. Нигъмәти сүзен дәвам иткән булса, Кәрим ага Тинчуринның шәраб подволында бераз «шаярып алуы» турында барачак иде. Профессор Нигъмәти түзеп тормады:

– Безнең Тинчурин иптәш яңа сорт йөзем ижат итте, – диде.

Петрохим исемле кара йөземнең шәрабе аңа бик ошап киткәч, безгә:

– Егетләр, бу бер дә Петрохим түгел лә, бу Абдрахим бу, – диде.

Менә шушы көннән бу йөземгә Абдрахим исеме бирергә дип тәкъдим кертте. Без дә бу тәкъдимне кабул иттек, – дип көлеп җибәрде. Үз гомерендә бик аз көлә торган Шәрәфи ага да мыеклары астыннан елмаеп көлде, залда бер җанлылык барлыкка килде, Кәрим ага, сүз туктасын дигән сыман:

– Картлар, сүз бозау имезә, дигәннәр, сез эш кешеләре, без – сезне тыңлаучылар, эшкә башларга кирәк, – дип куйды.

Чыннан да, зур ике галим арасында булган беседалар һәммәбез өчен кирәкле, бик яраклы иде. Без аларны хозур, бер кызыксыну белән тыңлыйбыз, үзебезгә тиешле нәтиҗәне ясыйбыз. Профессор Нигъмәти аганың әйткәннәрен истә калдыру өчен, Г.Ибраһимов дәфтәр кон-

спектлап барды. Шулай итеп, тузган китапның кирәкле җирләренә каралама ясый иде.

– Бүген язучыларның гыйльми дәрәҗәләрен, дөньяны танып белүләрен арттыру турында сөйлисе килә. Бу турыда да киң күләмдә сөйләшергә вакыт күптән җитте, дип уйлыйм, – ди Галимҗан ага.

Галимҗан ага, һәрвакытта кешеләр белән сөйләшкәндә, аның үзенә хас булган сабыр ашыкмаучанлык, йомшак тавыш белән сөйли иде. Аның сөйләүләре һаман тыңлаучыны үзенә тарта, аны тыңлаган саен тыңлыйсы килә. Без аның сүзләрен бик кызыксынып дикъкать белән тыңлый идек. Профессор Нигъмәти, Галимҗан аганың әйткәннәренә өстәмә ясаган сыман:

– Хәзерге әдип һәм шагыйрьләребез иҗатларындагы төп кимчелек бернәрсәгә кайтып кала. Ул да булса язылган әсәрләр, алынган темалар күпчелек хәлендә җитди гыйльми тикшерену күзлегеннән чыгып эшләнмәгәннәр. Аның өчен алар аз гомерле, фикергә ярлы булалар. Укучыга тормышның катлаулылыгын, характерларның үзенчәлеген тулысынча ачып бирә алмыйлар. Хәзергә кемдер бездә тарихи зур романнарның аерым бер очрак булуы, шулай ук тарихи-драмаларның, поэмаларның бер-бер артлы туа килмәүләренең сәбәпләре дә шунда булса кирәк. Тормышка җитди карар өчен тәгаен белем кирәк шул. Галимҗан ага, Нигъмәтинең сүзен бүлгән кебек, ашыга-ашыга:

– Монысын бик дөрес әйттең: менә, мисал өчен, мин үземне алыйм. Әгәр дә бүгенге гыйльми дәрәҗәм, марксизм-ленинизм тәгълиматларын белү һәм үзләштерү көчем «Безнең көннәр»нең беренче вариантын язган чорда булса иде, бәлки аның икенче вариантын өр-яңадан үзгәртеп эшләргә кирәкмәс тә иде. Ул вакытларда минем тарихи фактларны тулысынча белмәвем, аларга марк-

систик анализ ясый алмавын, романның эчтәлегендә җитешмәүләр, ул образларның характерларына тулырак бирә алмаулар һәм башкаларны роман өчен зур кимчелек итеп китерделәр. Хәтта гыйльми-фәнни яктан уйлап эш итә белмәү гаять мөһим булган мәсьәләләрне дөрес куя белмәүгә дә алып бара. Мин бу очракта үземнең «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» дигән хезмәтемне алам. Менә монда сорауның үзе бөтенләй дөрес куелмаган. Социализм чорында пролетариат диктатурасы шартларында барлык милли культуралар һәм, шул җөмләдән, татар сәнгате өчен дә тик бер генә юл бар. Ул да булса социализм юлы. Шулай булганда, нинди юл белән баруны сорауның уртага куелышы бөтенләй дөрес түгел. Менә иң дөресе – «Социализм шартларында милли мәдәниятләрнең, шул җөмләдән, татар мәдәниятенең үсеше» дип мәсьәләне кую; һәм аңа Ленин милли сәясәте күзлегеннән чыгып анализ ясау, һичшиксез, дөреслеккә алып барыр иде. Үз вакытында минем мәсьәләне дорес куя алмавым аңа тулы дөрес җавап бирүдә дә җитди хаталарга алып китте. Шуңа күрә мин моның кебек гыйльми хезмәтләрне дә бөтенләй үзгәртеп эшләү өстендә утырырга уйлыйм. Гыйльми дәрәҗә, фәнне үзләштерү, фактларга марксизм күзлегеннән чыгып анализ ясый алу сәләтең арткан саен дөнья киңрәк, тирәнрәк, якты перспективалы булып күренә шул. Менә тормышка якын килү, тормышны белеп язуның төп мәгънәсе дә шунда. Син әйтмешли, бу безнең бик күп язучыларыбызга җитмәгән. Шуңа күрә дә алар тарафыннан язылган әсәрләрнең күпчелеге бик аз гомерле булалар. Гыйлемсез, белемсез кешегә тик бер талант кына җитәрлек түгел. Әдәби осталык фактларны бер-берләреннән дорес аера белер өчен кирәк. Белемне арттыруның төрле юллары бар.

Безнең язучыларның күпчелеге бер урында гына эшләп, шул ук вакытта язучылыкны дәвам иттерүгә кырын күз белән карыйлар. Менә болар да алар эшенә комачаулый, – диде профессор Нигъмәти.

Галимҗан ага: «Бик дөрес. Бездә соңгы вакытлар «профессиональ язучылар» бик күбәеп киттеләр шул. Бу хәлнең кимчелекләре дә күп, иртәрәк профессиональ булу, теләсәң-теләмәсәң дә көндәлек яшәр өчен кирәк булган акча хөрмәтенә язарга да мәҗбүр итә. Мондый хәлдә аларның озак утырып, гыйльми күзлектән тикшереп язарга вакытлары бик аз була. Кайчакларда ботенләй мөмкин булмый. Без бөтен гомеребез буена эшләдек, тик бер урында гына түгел, хәтта берничә урында эшләргә туры килде. Азмы-күпме без җәмәгать, партия эшләренә катнаша килдек. Хәзер дә сәламәтлекнең нығып җитмәвенә карамастан, Ялтадагы партия эшләренә катнашырга туры килә. Менә безгә яшь язучыларны да конкрет эштә тәрбияләргә кирәк булыр иде. Бик яшьли «профессиональ» булганнар арасында тизлек белән «мин беләм» дигән буш горурлык һаман арта, хәтта ул бер авыруга әйләнә. Андыйлар үзеннән башкаларны түбән күрергә тырышып яши башлыйлар. Шулай итеп, «минчелек», индивидуальчылык башланып китә. Язучы өчен боларның һәммәсе бик начар бер авыру. Мондый авыру белән авырган язучылар дөньяның киңлеген, матурлыгын, катлаулыгын ачык күрә алмыйлар. Үз өсләрендә җитәрлек эшләмиләр, эшли дә алмыйлар. Үз өстендә эшли белмәү бу инде хәят белән бергә бара алмау дигән сүз. Хәлбуки, язучы хәят белән бергә түгел, анннан алдарак барырга тиеш. Киң һәм дөрес романтика белән яшәргә кирәк. Менә Татар совет язучыларының төп бурычларыннан берсе – язучыларны (...) коллективизм рухында тәрбияләү юлына юнәлдерергә кирәк.

Партия бу турыда бик күп чаралар күрә. Моның бер ачык мисалы итеп, 1929 елның август аенда бер төркем язучыларны милли республикаларга экскурсиягә юллау фактын алырга була. Бу экскурсия кардәш халыклар язучылары арасында җанлы бәйләнеш, халыкларны милли әдәбият үрнәкләре белән таныштыруга да күп ярдәм итеп, Кырым җәмәгатьчелеге татар язучыларының Кырымга килүләренә аеруча әһәмият бирде. Зур күләмдә төрле очрашулар оештырудан башка, «Иләри» («Алга») дигән ике мәртәбә чыга килгән иҗтимагый һәм политик әдәби журнал махсус сәхифәләр бирде, – диде һәм (...) үз китап шкафыннан «Иләри» журналының 1929 елның 14 августында чыккан санын күрсәтте. Ул сүзләрен дәвам итеп:

– «Безнең юл» журналы да артта калмады, Азәрбайҗан, Украина һәм Кырым әдәбиятларыннан аерым үрнәкләр бирә барды. Шунысы әһәмиятле, безнең «Галия» мәдрәсәсе шәкерте булган Кырымлы Гомәр Ипчинең иҗатыннан үрнәкләр һәм аның үзенчәлеге турында мәгълүматлар бирелде. Бу язучы – үзенчәлекле, талантлы бер язучы, хикәяче, драматург. «Мондый язучыларның әсәрләре белән безнең язучыларны да таныштыру, барыбызга да файда гына иде. Безгә мөмкин кадәр башка халыкларның журналлары, газеталары битләрендә дә катнашырга кирәк. Кырымлы иптәшләр мине үз матбугатларында актив катнашырга берничә мәртәбә чакырдылар. Менә аларга хәзергә шундый гына җавап бирергә мәҗбүр булдым, – дип, профессор Нигъмәти үзенең 1932 елны аена ике мәртәбә чыгып килгән «Большевик юлы» журналына язган хатын, журналның шул номерын күрсәтте.

## БЕЗ КАЗАНДА

1937 елның март ае. Мине Казан пединститутына диссертация якларга чакырдылар. Бу хәбәрне алгач та, тиз генә әзерләнеп юлга чыгарга булдым. Вакыт бик тыгыз булганлыктан, Ялтага Галимҗан ага янына бара алмадым. Шуңа күрә аның хәле турында берниндн яңа хәбәр алып килә алмадым. Беренче булып Казан пединститутының озын һәм бик караңгы коридорында мине очратучы профессор Г.Нигъмәти ага булды. Хәлләр белешә-белешә, ул бик ныклап Г.Ибраһимов турында сорый башлады. Сүзләрен дәвам итеп: «Кәрим, монда эшләр бик шәптән түгел. Узган төнне мине партиядән чыгардылар. Бу хәл синең диссертация яклау эшенә зыян китермәсә ярар иде. Мондагы бу хәлләр нәтиҗәсендә Ибраһимовка да зарар килмәсә ярар иде» – дип, тирән кайгы белдерде. Шунда ук күңел тынычландырыр өчен: «Зыян юк, бу эшләр болай калмас, җайланыр. Партия һәрвакыт үзенең дөрес сүзен нык әйтер», – дип куйды. Мин аны Большая Красная урамының азагына чаклы озата бардым. Ул вакытларны Нигъмәти ага, хәзерге обком йортыннан ерак түгел, түбәнгәрәк бер урамда (исеме истә калмаган) ике катлы агач йортның икенче катында тора иде. Миңа төрле сәбәпләр белән шатлыклы май бәйрәменә чаклы Казанда калырга туры килде. Иртәгә май бәйрәме дигән көнне Татарстан совет язучылары һәм аның иң күренеклеләре өчен бик тирән фаҗигале бер көн

булды. Күптән төзелеп, Хисаметдинов дигән кеше тарафыннан җитәкчелек ителгән комиссия үз йомгагын ясады. Үзенчә, бу комиссия Татарстан язучыларының эшенә бәя бирә, имеш. Матбугат йортында уздырылган бу җыелыш, ябык җыелыш дип игълан ителсә дә, мин рөхсәт алып җыелышка бардым. Җыелышта урыннарыбыз Нигъмәти ага, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш белән бергә туры килде. Җыелыш башланып киткәнче, без Ялтадагы Галимҗан ага Ибраһимов белән очрашуларны, сөйләшүләрне искә алып утырдык. Җыелыш башланып китү белән барлык мәсьәләләр төп бер ноктага бәйләнеп китте. Ул да булса, юк-бар гаепләр белән түбәндәге иптәшләрне гаепләргә тотындылар. Беренче чиратта К.Нәҗми, Г.Нигъмәти, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Г.Толымбайский һ.б. тора иде. Шунысы характерлы, чыгып сүз әйтүчеләрнең күпчелеге турыдан-туры дөреслекне әйтергә тартына, гаепләнүчеләрне яклый, дип әйтмәсеннәр дигән кебек әйләнчек юллар белән чыгыш ясыйлар иде. Хәтта үзенең белем дәрәҗәсе, дөньяны күреп белүе ягыннан, иң фәкыйрьләрдән берсе булган Ханҗәмил кебекләр профессор Нигъмәтине татар әдәбиятында Переверзевчылыкны беренче булып таратучы дигән иң түбән гаепләүләр белән дә чыкты. Шәхес культының каты кысулары аркасында юк-бар гаепләүләр белән Татарстанның иң күренекле язучыларны шул ук җыелышта Совет язучылары союзыннан чыгарып ташладылар. Җыелыш барышында Кәрим ага Тинчурин түзеп тора алмыйча, тирән ачу һәм нәфрәт белән: «Кара син бу юк сүзләрне ачыктан-ачык әйтүчеләргә, безнең өскә яла ягалар, булмаганны әйтәләр. Әгәр дә Галимҗан ага Ибраһимов мондый трагедик җыелышларны ишетә калса, аның сәламәтлеге яңадан какшар иде, – дип кайгырып алды. Миңа мөрәҗәгать итеп: «Кәрим, зинһар өчен,

Кырымга баргач та мөмкинлек табып, Галимҗан ага янына бар. Мондагы хәлләрне аңлатып бир. Югыйсә, ул аны читтән ишетергә дә бик мөмкин. Зинһар өчен, шуны эшлә әле, – дип куйды. Без җыелыштан чыгарга ишеккә юнәлгәндә, профессор Нигъмәти: «Кәрим, син монда Казанда ялгызың гына, иртәгә бәйрәмгә безгә килеп чык, бергәләп сөйләшеп утырырбыз. Бу хәрәкәтләр озакка бармас, аңа партия чик куяр, – диде. – Онытма, иртәгә 9-10 нарда көтәм, рәхим ит». Иртәгс көн бик матур булды. Быел нигәдер Татарстанда яз бик иртә килде. Пароходлар, паровозлар, төрле баржалар, бар көчләре белән кайнашып йөриләр, киң Волганы яңгыратып торалар иде. Анда-монда яшеренеп яткан карлар, бозлар күптән күздән югалганнар.

Мин күрсәтелгән вакытка барып чыктым. Галимҗан ага йортның икенче катында, баскыч башында көтеп тора иде.

– Әйдә, рәхим ит. Бездә, сездәге кебек, өстәлләр дә, төрле-төрле җимешләр һәм башка төрле азыклар белән бизәлмәгән. Өстәлең фәкыйрь, дип көлеп китмә. Җитәр, булганы белән дип, – борынын тартып көлде. Залга кертәч тә безне шатлык белән бер кызчык белән малай каршы алдылар. Галимҗан ага: менә бусы – кызыбыз Йолдыз, улыбыз Иңгел, дип таныштырды. Шул арада Галимҗан аганың гомер иптәше Җиһан ханым килеп чыгып, безне өстәл янына утыртты. Өстәлдә киң, матур булып күренгән төрле-төрле коробкалы конфетлар иде. Галимҗан ага шаярып сөйләшергә бик ярата иде: – Мин мондый конфетларны яратам. Мәскәүдән күчтәнәчкә шушы конфетларны алып кайтам. Боларны сездән кайтканда Мәскәүдән алып кайттым. Тәмәке тартмагач, аракы эчмәгәч, конфет суыруы бик рәхәт, – дип көлде. Аш, чәйләрдән соң, кызу йөрәкле Җиһан ханым гармуның алды да матур татар-башкорт

көйләрен уйнап җибәрде. Йолдыз түзеп тора алмады, биеп китте. Галимҗан ага кулларын чабып, кызының биюснә шатланып, горур гына утыра, чалбарының уң балагын өскә тартып елмая иде. Шатланганда, кызу сөйләшкәндә чалбар балагын югары тарту аның гадәте иде. Биюләр озак дәвам итте. Шунысы кызык, ул вакытта идән типтереп биегән бәләкәй Йолдызның вакыт җитәр дә университетның алдынгы доценты, күренекле гыйльми работнигы булып китәр дип һич беркем дә уйлый алмый иде. Вакытында әтисе алдында биеп йөргән сабый бала – Йолдыз ханым әтисенең юлыннан барып, бүген Казан университетында рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасының актив члены. Ул укыту эшләре белән генә чикләнми, кафедрада зур һәм катлаулы гыйльми эшләр дә алып бара. Менә аның турында кафедра мөдире профессор Гумчев нәрсә ди: «Йолдыз ханым безнең кафедрада хәзергә бер генә диярлек. Ул хәзерге көндә иң кирәкле, иң мөһим проблемалар өстендә эшли, уңышлы рәвештә Тургенев белән Ф.Әмирхан арасында булган әдәби мөнәсәбәтләр буенча кандидатлык диссертациясе язды һәм яклады. Хәзерге көндә гомумән, татар әдәбиятының рус әдәбияты белән булган каршылыклы мөнәсәбәтләре кебек мөһим проблемаларны хәл итеп ята. Бу аның докторлык диссертациясе булыр», – ди.

Балаларның биюләре беткәч, бераз күңел ачкач, Галимҗан ага мине үзенең эш кабинетына алып керде. Анда гади такталардан киң иттереп ясалган стеллажлар. Аларда газета-журналлар, чит ил һәм рус классиклары әсәрләре, бик күп гыйльми, тәнкыйди хезмәтләр, төрле кулъязмалар бар иде. Болар инде профессорның студентлары, аспирантлары укыган лекцияләрнең фәнни хезмәтләрнең оригиналлары. Галимҗан ага минем дикъкатемне икс кулъязмага тартты: «Менә бу Галимҗан Ибраһимовның «Безнең

көннәр»е турында. Мин монда чагыштырмалы бер формада романның һәр ике варианты турында да анализ ясадым. Кайбер иптәшләр минем беренче вариантка карата язганнарымнан төп кимчелекләрем итеп түбәндәгеләрне күрсәткәннәр иде. Алардан беренчесе, мин аңлы рәвештә, романдагы геройларны арттырып мактап һәм уңай итеп биргәнмен, имеш. Бәлки мондый хәлләр, аз-маз булгандыр да. Менә боларны барысын да исәпкә алып һәм икенче вариантның тирәнлеген идея һәм художество ягыннан матуррак, җыйнаграк булганнарын бер кат күздән үткәрергә тырыштым. Чыннан да романның беренче юлларында ук Кара диңгезнең матурлыгы шулкадәр тасвир ителгән, аны икенче төрле тасвирлау һич тә мөмкин түгел. Аны тик бер олы М.Горький гына тасвирлый алды. Мәсьәлә монда да түгел. Беренче варианттагы тасвирлауда берниндн пунктуация таләпләре сакланмаган. Бу исә юлларның музыкальлегенә, көчлелегенә комачау ясый. Мондый хәл романның гомумән композициясенә зыян китерә. Икенче вариантта эш бөтенләй башка, анда бик нык җыйнаклык бар. Кара диңгезнең матурлыгында тирән бер ритмлылык, көчлелек булганын тагын да сизәсең. Моны романдагы детальләрдән алып, калган барлык художество матурлыкларын укучылары алдында ачып саласы килә. Бу хезмәттә моңа кадәр язганнардагы кимчелекләрне бетерергә исәп бар. Бу эш белән Галимҗан Ибраһимов үзе дә таныш. Аның белән Ялтада бу соңгы баруда сөйләшеп тә алдык. Ул башта өч тәнкыйтьченең тәнкыйть итүе белән генә чикләнмәскә тиеш. Аның алдында өйрәнү бурычы да торырга тиеш дип куйды. Бу хезмәтне озакламый матбугатка әзерләп бирәсе булыр.

Сүз икенче кулъязмага күчте. Бусы, – диде профессор Нигъмәти, – «Тукайның шигырь техникасы»

дигән китапның соңгысы корректурасы. Китап чыккач, сиңа җибәрермен. Моңача без беребез дә җитди рәвештә Тукайның шигырь техникасы байлыгына, аны иҗтимагый-политик таләпләренә җавап бирү юлында үзгәрә, катлаулана баруын, шул ук вакытта шигырьләрдәге тирән идеяләрнең ачык булып төрле иҗтимагый катлауларның демократик катламына тиз барып җитүгә хезмәт иткәнлеген тирәнтен күрә алмадык. Менә мин ул яктан чыгып, чорның бик күп шагыйрьләреннән аерылып торганлыгын һәм идея политикасын ачып бирергә тырыштым. Үземә калса, бу татар әдәбияты белемендә беренче оригинал хезмәтләрдән булыр дип уйлыйм. Галимҗан Ибраһимов белән бу турыда сөйләшкәндә, ул минем барлык тезисларны яклады, һәм өстәп шуларны әйтте: «Без Тукайның шигъри талантын тиз генә аңлый алмыйча, андагы музыкаль байлыкны, фикери тирәнлекне ачык итеп күрә алмыйча, үз вакытында Тукай шагыйрьме, түгелме? дигән сорауларда саташтык шул. Бу безнең ул вакытларда эстетик карашларыбызның җитәрлек булмавын, поэзиядәге художестволылыкны, аның үзенчәлекләрен хәзерге дәрәҗәдән чыгып карый алмавыбызны күрсәтә: «Нигъмәти, син бу өлкәдә бик зур борылыш ясагансың, хәзерге поэзиябезгә дә кирәкле йомгаклар биргәнсең», – дигән иде. Г.Ибраһимов кульязмага кайбер үзенең төзәтмәләрен дә ясады.

Мондый файдалы, кирәкле бәседәлардән соң, профессор Нигъмәти сүзләрне кисте дә:

– Нигә соң без мондый шатлыклы бәйрәм көнендә өйдә кабинетларда гына утырабыз. Әйдә, Кәрим, мин сиңа Ослан тауларын да күрсәтеп алыйм. Үземнең дә күптәннән Казан кырыйларына чыкканым юк, дигән тәкъдимне ясады да сүзне дәвам иттереп, безнең казанлыларның иң яраткан урыннарыннан берсе – Ослан тауларына чыгу һәм Казанга

сокланып карау. Г.Ибраһимов та анда ял итәргә бик ярата иде. Безнең аның белән булган сөйләшүләребез шунда була иде, – диде. Без кузгалып, элекке пристаньга киттек тә, перевозга утырып, Ослан тауларына күтәрелдек, көнне шунда уздырдык. Галимҗан ага: – Нигъмәти дөресен әйтә, мондагы гүзәллек – үзенә хас булган бер гүзәллек. Ләкин һич тә Кырым гүзәллегенә ошамый, – диде.

Нигәдер бу соңгы мәртәбә Ялтага барганда анда озак калып, Ибраһимов янында берничә айлар булып, аның турында яза башлаган китапның зур бер өлешен аның белән берлектә бетерү теләге туды. Кырымның матурлыгы һаман да иҗатка омтылдыра: гүзәл табигать, Кырымның матурлыгы турында сүз чыктымы, нигәдер Ибраһимов С.Кудашның «Кырым эскизлары» дигән поэмасыннан алынган юлларын яттан укый иде.

*Кырым! Аның кипарис матурлыгын*
*Җырлаучы шагыйрьләр җитәрлек,*
*Ә ул -әле һаман җырчы көтеп,*
*Җырланып бетмәгән чибәрлек.*

Кояш баерга якынлашканда Кремльнең аклыгы тагын да матур күренә. Осланда ял итүчеләрнең гармун тавышлары белән көймәләргә юнәлүләре бер матурлык бирәләр. Бертуктаусыз узып торган пароходларның тавышлары, шат күңелле пассажирларның яулык болгап, гүзәллекләрне сәламләп үтүләре йөрәкне шатландыра. Без бик шәп кенә ял иткәч, Казанга кайтып җиттек. Галимҗан ага белән саубуллаштым. Мин иртәгә юлга чыгасы кеше, соңгы тапкыр Галимҗан агага миңа күрсәткән гыйльми ярдәмнәре, кадерле киңәшләре өчен зур рәхмәт белдердем. Мондый иҗади, гыйльми элемтәләрнең соңгысы булмасын иде, дип Галимҗан аганың кулын кыстым.

## ШАМИЛ УСМАНОВ БЕЗНЕҢ ЯНДА

Яшьтәш һәм каләмдәш, яисә икебез дә бер үк вакытта комсомол шагыйрьләр булып, бергәләшеп татар совет поэзиясенә нигез салып килүчеләрдән булганыбыз өченме, монысын бер дә әйтә алмыйм, ләкин нинди сәбәптән булмасын, Зыяэддин Җаутүбәле белән минем ял итү бик күп очракларда бергә туры килә торган иде.

Без икәүләшеп Ялтада Язучылар союзының иҗат йортында. 1937 елның сентябрь башлары. Нигәдер көннәрнең берендә үзара сөйләштек тә өйлә вакытында булган тыныч сәгатьне тынгысыз итәргә уйладык. Иҗат йортының ишек алдында матур агачлар күләгәсендә утырып, сентябрь аеның гүзәллегенә соклана-соклана, узганнарны искә алып киттек.

Күбесенчә сүз үз вакытында Ялтада партия эшләрендә эшләгән вакытта Галимҗан Ибраһимов белән нык очрашкан, аның белән бергәләп Ялта партия комитеты ревизия комиссиясендә эшләгән, Галимҗан ага белән якыннан таныш булган, сүзгә чибәр һәм безне икебезне дә әдәбият мәйданына тарткан Бәкер Гомәрев турында барды. Ул 17 ел утырып чыкканнан соң яңадан партия, җәмгать эшләренә кайтты. Хәзер Сәмаркандта персональ пенсионер.

Безнең сөйләшүләр кинәт тукталды. Ял йортында күтәрелгән баскычлардан ашыгып-ашыгып безгә туры

кемдер килә. Ашыгып килүче Совет Армиясенең сугышчан комиссары, үткен каләм иясе Шамил ага Усманов булып чыкты. Кызу табигатьле, күзләре ерак-еракларга карый торган Шамил ага:

– Сәлам, егетләр. Менә ничек яхшы туры килдегез. Мин махсус сезнең янга килдем, – диде. Аның күзләрендә ниндидер тирән борчылу, тынычсызлык сизелеп тора. Без аны хөрмәтләп уртага утырттык. Гадәтенчә, без аңа Казан ничек, нинди санаторийга урнаштыгыз, монда иҗат йортына ник килдегез, дигән сораулар белән мөрәҗәгать иттек. Шамил ага бик ризасызлык күрсәткән сыман: – Егетләр, сез миннән бернәрсә дә сорамагыз. Минем берниндн билгеле маршрутым юк, бары әдәбият һәм культурабызның олы даһие булган Галимҗан ага Ибраһимов белән саубуллашырга килдем, – диде. Аннан соң берничә минут сүзсез торды. Шамил ага бик тынычсыз иде. – Әйдәгез, егетләр, иҗат йорты артына, тау башындагы даплы беседкага чыгыйк. Аннан Ялтага, Кара диңгезгә тагын бер кат карыйк, – диде. Күтәрелеп, беседкага таба юнәлдек. Мин сүзне икенчегә борыр өчен, үзем белән 1934 елның апрель аенда булган бер кызыклы хәлне сөйли башладым. Кырым, тик бер Галимҗан ага Ибраһимовның икенче әдәби ватаны түгел лә, башка олы татар язучыларының да әдәби ватаны булган ул. Менә тыңлагыз, егетләр, мин ул вакытта нинди кызык бер хәлгә очрадым. Мин бервакытны мөһим эшләр белән Судак районындагы иң зур татар авылларыннан В.Утызавылы дигән авылга барып төштем. Техникумда бергә укыган иптәшләрнең берсе мине кунакка алып китте. Аерым бер бүлмә тәкъдим итте. Шунда ук, Кәрим, бу бүлмәнең ике исеме бар. Аның беренчесе гади кунак бүлмәсе, икенчесе шагыйрь Ф.Бурнаш бүлмәсе дип көлеп куйды. Менә

бүген син ике исемле бүлмәнең кунагы. Бүлмә, иске татар гадәте буенча, бик матур итеп бизәлгән. Идәннәрдә ковер-лар, стена буйлап түшәкләр түшәлгән, стеналарга мах-сус багышланып эшләнгән мендәрләр куелган. Кыскасы, рәхәтләнеп ял итәргә генә калган. Чөйләргә кызлар чиккән сөлгеләр аеруча матурлык биреп торалар. Бу матурлы-кларны тагын да җанландырган, бик кызык хәл күзгә бәрелде. Стенада шагыйрь Ф.Бурнаш портреты, китап эта-жеркаларында аның китаплары, мин бу хәлгә гаҗәпләнеп калдым. Чыннан да бу аның бүлмәсе икән, дидем. Йорт хуҗасы миңа: «Менә, Кәрим дус, безнең Утызавылы нинди авыл. Кайлардан, кемнәр генә монда килеп тормый-лар. Ф.Бурнаш безнең авылның үз кешесе булып китте. Ун елдан артык, ел саен, бөтен җәй бездә тора. Ул безнең семья члены булып китте. Иҗатына материал җыйный, яза. Ул Кырым минем икенче әдәби ватаным булды инде, – ди. Ул моңа хаклы да. Озакламый без аның «Кырым» дигән шигырьләр җыентыгын көтәбез. Фәтхи аганы тик бер безнең авыл кешеләре генә түгел, якын-тирә авыл-лар да безнең Фәтхи ага Бурнаш дип йөртәләр, – диде. (...) Минем сүзләрне дәвам иттергән сыман Шамил ага Усманов «Памирдан радио» дигән хезмәтенең Кырымда таралганлыгын һәм аның талантлы шагыйрь Хәмди Халит тарафыннан яхшы тәрҗемә ителгәнен тасвирлап бирде. Шамил аганы болар кызыксындырса да, ул һаман да илдә барган хаксызлыклар турында әйтә. Нигә безгә үз иленең комиссарларына, партия членнарына, мондый ышанмаучанлык туды соң?- дигән сораулар бирә. Нигә безнең арттан күзәтәләр? «Халык дошманы» дигән сүз белән гаеплиләр соң? Мин моңа җавап эзлим, ләкин таба алмыйм. Дуслар, сез бу көннәрдә Галимҗан ага янына бара күрмәгез, ул бик борчулы. Аны ике нәрсә борчый:

1. Ни өчен аның Казанга чакырылуын кичектерәләр?
2. Илдә барган хаксызлыклар, хокуксызлыклар аны коне-төне борчыйлар. Ул һаман да Казанга үз аягы белән кайтып, дус-ишләре белән бергәләп утыру ниятендә.

Без өчәүләшеп беседкадан тордык та көнчыгышка таба, тагын да биеккә күтәрелдек. Биек тау башында Дорекой, Айвасыл дигән авылларның матурлыгына, кояш батар алдыннан тыныч сулыш алган Кара диңгезгә карап, тагын бер кат сокландык.

– Әйдәгез, дуслар, монысы ахыргысы булыр бугай, исән-сау булыгыз. Сезнең исемнән Галимҗан агага самими сәламнәрне мин үзем әйтермен. Үзегез барып, аны борчымагыз, – дип, Галимҗан ага безнең соңгы кайнар сәламебезне алып китте. Галимҗан ага үз аягы белән шатланып туган Казанына барып чыга алмады. Аны шәхес культының кара көчләре икенче канлы бер юл белән алып киттеләр. Казан төрмәләрендә, хаксызга юк иттеләр.

Аның һәм аның кебекләрнең мәңге үлмәс әдәби мираслары гына калды. Бу мирасны асруча тирәнтен өйрәнү – хәзерге яшьләрнебезнең гомуми бурычы. Кайбер иптәшләр Г.Ибраһимовтан өйрәнү, аның әдәби осталыгыннан файдаланып язу заманасы күптән узды, дигән ялгыш фикерләрне хәтта матбугатта да күтәреп чыга башладылар. Моңа охшашлы ят фикерләр фаш ителергә тиеш. Дөресен әйткәндә, Галимҗан аганың әдәби художество мастерлыгы бар тирәнлеге белән ойрәнелмәгән. Аны тирән бер хөрмәт белән өйрәнү, аның осталыкларын ачып бирү – хәзерге тәнкыйтьчеләребезнең, әдәбиятчыларыбызның төп бурычларыннан берсе. Тиңдәшсез каләм остасы булган, көчле әдип, зур галимгә мәңге дан, мәңге хөрмәт!

*Симферополь-Алабуга, 1937-1965.*

## ӘДИПЛӘР ҺӘМ ГАЛИМНӘР ДӨНЬЯСЫНДА

Минем исемгә Ялтадан бер хат килеп төште. Бу хатны Галимҗан ага Нигъмәти язган иде. Ул үзенең хатында К.Тинчурин белән бергә язучыларның иҗат йортында торуын, Ялтада бер ай чамасы булачагын яза һәм, вакыт табып, алар янына килеп чыгарга киңәш итә.

Мин ул вакытта Симферополь Тел, әдәбият гыйльми-тикшеренү институтында эшли идем. Озакка сузмыйча, рөхсәт алып, Ялтага юнәлдем. Анда Г.Нигъмәти белән К.Тинчуриннан башка Шәриф Камал да бар икән. Мин аларга Кави Нәҗминең Казаннан биргән телеграммасын күрсәттем, шул телеграмма нигезендә Симферополь вокзалында аларны ничек көткәнлегебезне әйткәч, алар кычкырып көлеп җибәрделәр. Г.Нигъмәти, борынын тарта-тарта (аның шундый гадәте бар иде):

– Әй, Кави, Кави, ниләр буташтырган бит, – диде. – Ләкин бу турыда ул безгә бернәрсә дә әйтмәде. Без Севастополь аркылы килдек. Симферопольдә туктарга уйламадык.

Бераз утыргач, хәлләр белешкәч, Г.Нигъмәти үзенең Ялтага килүенең төп максатын сөйләп бирде:

– Партиянең Татарстан өлкә комитеты кушуы буенча мин Галимҗан Ибраһимов турында бер хезмәт язарга тиеш. Киләсе, ягъни 1937 елны, Галимҗан Ибраһимовка илле яшь тула. Шул уңай белән аның юбилеен уздырырга

исәп юк түгел. Әгәр сәламәтлеге мөмкинлек бирсә, аны вакытлыча Казанга кайтарырга уйлыйбыз.

Бу хезмәтенә материал туплау һәм аның планын бергәләшеп төзү өчен иртәнге сәгатьләрдә ул һәр көнне диярлек Г.Ибраһимов янына бара икән. Аның белән бергә кай көннәрдә К.Тинчурин да, Ш.Камал да баргалый икән. Иртәгә мине дә үзе белән алып барырга, Г.Ибраһимов белән таныштырырга вәгъдә бирде.

Моннан берничә еллар элек минем Г.Ибраһимов янында булганым бар иде, үземчә аның белән таныш идем. Ләкин бу әле ул да мине белә, минем белән таныш дигән сүз түгел иде, әлбәттә. Аның янында Кырым язучылары еш була. Аларны ул, бигрәк тә, безнең кебек яшьләрне каян белеп, танып бетерсен. Аның янында элек булуыма карамастан, шулай да мин бу визитны бик кызыксынып һәм беркадәр дулкынланып көттем.

Иртәгесен иртә белән без дүртәүләшеп Галимҗан ага янына киттек. Безнең килүебезне ул тәрәзәдән яисә верандадан күреп торган булса кирәк, чөнки безне ишек төбендә каршы алды.

Г.Нигъмәти аңа, мине тәкъдим итеп:

– Без бүген, Галимҗан ага, үзебез белән бергә яңа бер иптәш алып килдек, – диде һәм исем-фамилиямне әйтте.

Галимҗан ага, моны ишетеп, сизелер-сизелмәс елмайды.

– Бик шәп булган, без аның белән күптән таныш шикелле, – диде. – 1933 елны сез шагыйрь Җаутүбәле белән бергә килгән идегез бугай? Шулаймы? Сезнең килүегез шуңа исемдә сакланып калган. Сез миңа Кырымның әдәби хәяте турында гына түгел, Казандагы Бишбалта хәбәрләрен дә алып килгән идегез. Сез Бишбалта кызына өйләнгән

бит әле? Шулай булгач, сез – безгә икеләтә кунак, – дип, шаярып көлеп куйды.

Мин аның хәтеренең яхшылыгына, килүебезне онытмавына, хәтта Җаутүбәлене исеме белән телгә алуына гаҗәпләндем.

Бераз хәл-әхвәлләрне сорашып, иҗат йортындагы кайбер яңалыклар турында сөйләшеп утырганнан соң, сүз татар әдәби тәнкыйтенең торышына күчте. Бу мәсьәлә аларның барысын да борчый иде булса кирәк. Чөнки алар бик бирелеп, тирә-юньдәге бөтен нәрсәне онытып, хәтта кайбер минутларда бер-берләрен бүлеп сөйләшергә керештеләр.

Ул көннән бирле инде күп еллар үткән, күп сулар аккан һәм, табигый, аларның сүзләрен бүген мин, никадәр теләсәм дә, тулысынча кабатлап әйтеп бирә алмыйм, әмма аларның төп фикерләре, татар әдәби тәнкыйте алдына куйган яисә куярга теләгән бурычлары күңелемдә яхшы урнашып калган. Мин аларны хәзер дә гәрчә аларның үз сүзләре белән булмаса да, укучыларга беркадәр чама белән сөйләп бирә алам.

– Безгә, гомумән, әдәби тәнкыйтьнең сыйфаты һәм характеры турында бик нык лап сөйләшергә кирәк иде, – диде Галимҗан ага. – Бу өлкәдә безнең кимчелекләребез күп. Әдәби тәнкыйть әсәрләре аз басыла, аз тарала һәм бик аз укыла. Моның берничә төп сәбәбе бар. Беренчедән, күп кенә тәнкыйть мәкаләләренең язылу стильләре бик фәкыйрь, җансыз, көчсез. Әдәби тәнкыйть әсәрләре дә, нәкъ хикәяләр, романнар кебек үк, талантлы каләм белән язылырга тиеш дип саныйм мин. Халык аны кызыксынып, яратып укырлык булсын. рус әдәби тәнкыйте тарихында моның матур мисаллары күп. Мәсәлән, Белинский, Добролюбов хезмәтләрен алып карыйк. Алар, тирән

мәгънәле булу белән бергә, зур художестволы публицистик әсәрләр. Шуңа күрә алар укучыны үзләренә җәлеп итәләр, аны тәрбиялиләр. Бездә исә, фәнни нигезе булмаган социологизм, шаблонга әверелгән схематизм өстенлек алып килә. Аннары кайбер мәкаләләрдә тиешле дәрәҗәдә объектив караш та җитми дип әйтер идем мин.

Галимҗан ага фикеренең бу соңгы өлешен К.Тинчурин белән Ш.Камал да яклап, берничә сүз әйтеп алдылар.

Г.Нигъмәти исә, әдәби тәнкыйтьләр генә түгел, әдәби мемуарларның да кирәклеге, аларны иҗат итәргә бик вакыт икәнлеге турында сөйләгәннән соң, сүзне үзенең язарга ниятләнгән китабына күчерде.

– Сүз уңае туры килгәндә, сезнең турыда язасы китабымның формасы, стиле турында да бер-ике сүз әйтәсем килә, – диде ул. – Бу турыда мин күптән уйлап йөрим. Аны, билгеле, бары иҗатыгызга гына багышланган китап итеп язарга була. Ул чакта китапта сезнең иҗтимагый эшчәнлегегезгә җитәрлек урын бирелмәячәк, ул беркадәр күләгәдә калачак. Минемчә, аны сезнең әдәби хезмәтләрегезне дә һәм иҗтимагый эшчәнлегегезне дә эченә алган китап итү дөрес булыр. Мәсәлән, рус телендә М.Горькийның тәкъдиме һәм аның турыдан-туры ярдәме белән чыгарыла башлаган «Жизнь замечательных людей» дигән серия бар. Бу серия миңа бик ошый. Вакытым сыйдырса, көчем мөмкинлек бирсә, мин дә сезнең турыдагы китабымны шул серия формасындарак язарга ният итәм. Әгәр моны эшли алсам, бездә бу бер башлангыч булыр иде дип уйлыйм. Сез моңа ничек карыйсыз?

Галимҗан ага моны хуп күрде. Алар татар әдәбияты һәм культурасы тарихындагы берничә зур исемне телгә

алдылар. Аларның эшчәнлекләре турында да шундый китапларның кирәклеген әйтеп үттеләр. Бу уңай белән сүз, үзеннән-үзе билгеле, бу китапларны язарлык авторларга һәм аларны әзерләү мәсьәләсенә күчте.

– Безгә менә шушы эшләрне оештыручы һәм әйдәп баручы бер гыйльми үзәк кирәк, – диде Галимҗан ага һәм басым ясап кабатлап әйтте. – Бик кирәк! Үзең беләсең, заманында Татарстан Халык Мәгариф Комиссариаты янында Гыйльми үзәк бар иде. Ул үз бурычын үтәде. Бу инде үткән эш. Хәзер безгә киңрәк күләмдәге Гыйльми үзәк кирәк. Бу турыда синең фикерең ничек? – дип, Г.Нигъмәтидән сорады.

– Бу бик дөрес, – диде Г.Нигъмәти. – Хәзергә гыйльми кадрларның күбесе пединститутның тел-әдәбият бүлегендә әзерләнә. Бездә аспирантура да бар. Ләкин безнең төп бурыч – гыйльми кадрлар әзерләү түгел, ә укытучылар әзерләү. Шунлыктан бездәге көчләр киң күләмдә гыйльми эшләр белән шөгыльләнә алмыйлар.

Галимҗан ага, бераз уйланып, шактый ябык һәм озын булып агарып торган бармаклары белән өстәл өстен шакылдатып алды.

– Дөрес әйтәсең, – диде ул. – Педагогия институты гына җитеп бетми. Безгә хәзер Казан дәүләт университеты янында махсус татар теле һәм әдәбияты кафедрасын оештырырга кирәк. Яшьләр университет күләмендә белем алсыннар. Менә шулардан, билгеле, талантлыларыннан аспирантлар, гыйльми работниклар чыгаруны хәл итәргә кирәк. Монысы бер гыйльми үзәк булса, икенчесе, иң яхшысы, безгә тел, әдәбият һәм тарих гыйльми тикшеренү институты оештырырга да бик вакыт. Бу яктан без кайбер милли республикалардан артта калдык. Аларда инде мондый институтлар бар.

Шунда алар, мисал итеп, Кырым татарларының Тел, әдәбият институтын һәм башка республикалардагы институтларны телгә алдылар, алар тарафыннан эзерләнеп чыгарылган гыйльми хезмәтләр турында үзләренең фикерләрен әйттеләр. Галимҗан агага Симферополь тел, әдәбият гыйльми тикшерену институты тарафыннан чыгарылган «Тюрко-татарская рукопись XIV века («Нехдж-уль-фарадис»)» исемле китап ошаган булса кирәк. Бу гыйльми әсәрне 1930 елда Кырым галимнәреннән Якуб Камал әзерләп чыгарган һәм аңа академик Самойлович сүз башы язган иде.

– Бу хезмәт безнең әдәбиятыбызны һәм телебезне өйрәнү өчен бик әһәмиятле, – диде Галимҗан ага. – «Нәһҗел-фәрадис» турында заманында Шиһап Мәрҗани да кайбер бик әһәмиятле фикерләр әйткән иде. Ләкин безнең әле, академик Самойлович әйтмешли, шуннан артык киткәнебез юк. Безгә, яңа әсәрләр иҗат итү белән бергә, борынгы әдәби байлыгыбызның җәүһәрләрен өйрәнеп, бер тәртипкә салып, киң катлау укучыларга бирә башларга бик вакыт ...

Галимҗан ага, сөйләшеп утыра торгач, бераз арыды булса кирәк. Кергәннән бирле сүзгә кушылмыйча тын гына утырган Ш.Камалга карап алды да:

– Без, икс Галимҗан, әдәбият һәм фән турында кызышып китеп, кунакларны бөтенләй истән чыгардык, – диде һәм сүзне икенче темага күчерде. Кемнәрнең ничек ял итүләрен, ничек эшләүләрен сорашты. – Я, Шәриф, синең эшләр ничек бара?

– Бу көннәрдә әле эшләр бераз тукталып тора, язылмый, – диде Шәриф Камал. – Кәгазь бетте. Бер каян табып булмый. Кәгазь өчен Казанга кайтырлык булдым.

Галимҗан ага аңа бераз текәлеп карап торды да:

– Әй, Шәриф, Шәриф, бер дә үзгәрмәгәнсең икән, – диде. – Ул кадәр йомшак, хатын-кыз кебек оялчан булма, зинһар. Кәгазь кытлыгы зур нәрсә түгел ул. Горком егетләре сиңа кәгазь генә түгел, әллә нәрсә табып бирерләр. Миңа күптән әйтәсең калган.

Шулай сөйләшеп утырганнан соң без өчәү – Ш.Камал, К.Тинчурин һәм мин – саубуллашып чыгып киттек. Г.Нигъмәти Галимҗан ага янында калды. Аларның әлеге китап турында сөйләшәселәре, фикер алышасылары бар иде.

Иртәгесен иртә белән, иҗат йортында язучылар йокыларыннан торып кына килгәндә, минем бүлмәгә Ялтадагы китап магазины мөдире, электә газета редакцияләрендә эшләгән, хәзер китап сәүдәсенә күчкән Кадыйр исемле иптәш килеп керде һәм миннән:

– Шәриф Камал аганы ничек табарга икән? – дип сорады.

Мин аның култыгындагы төргәккә күз төшереп алдым.

– Нигә кирәк булды ул сиңа?

– Аның кәгазе юк икән. Дәфтәрләр китергән идем. Шуны бирәсе иде, – диде иптәшем.

Шунда мин Галимҗан аганың Ш.Камалга кәгазь турында әйткән сүзләрен исемә төшердем. Галимҗан ага аны әйтү белән генә чикләнмәгән, ә чарасын да күргән иде.

Без, Ш.Камалны табып, аңа дәфтәрләрне бирдек. Шәриф ага моңа бик гаҗәпләнде:

– Әй, бу Галимҗан, авыру булуына карамастан, һаман шулай икән әле, – диде. – Бер нәрсәне әйтсә, шунда ук эшли. Яратам аның шул гадәтен.

Ялтага бу баруымда мин әдипләр, галимнәр арасында ун көнләп тордым һәм шул вакыт алар белән

бергә Галимҗан ага янында берничә мәртәбә булдым. Мине үзләренә юлдаш итеп алган бу язучылар иртә белән йөрергә чыккан вакытларда, һәр көнне булмаса да, еш кына Г.Ибраһимов янына кагылып китәләр иде. Әдипне без кай көннәрдә ишек алдында, зур булып үсеп торган агачлар арасындагы эскәмиядә утырган хәлдә очрата идек. Бер баруыбызда ул үзенең каләмдәш дусларына Кырымның матурлыгыннан, аның һавасыннан файдаланып калырга киңәш итте.

– Кырым ул – дөньяның иң матур бер почмагы, – диде. – Шуның белән бергә ул шифалы да. Ялтага килгәндә, мин үлем хәлендә идем. Кулдан каләм төшкән, көч беткән иде. Аның табигате, шифалы һавасы, диңгезе мине аякка бастырды. Сез дә бу байлыктан файдаланып калыгыз. Әле хәзер генә мин, сез килгәнче, диңгез буена барып, аның саф һавасын сулап кайттым. Сез дә шулай итегез. Аннары монда, Ялтада, тарихи урыннар да күп. Аларны да карагыз. Карамыйча калмагыз. Моннан ерак түгел Әмир-Бохар сарае дигән бер сарай бар. Анда крайны өйрәнү музее урнашкан. Бик кадерле кулъязмалар бар анда. Алар арасында «Нәһҗел-фәрадис»ның моңарчы билгеле булмаган варианты саклана. Чехов музеенда булгансыздыр инде. Монда килеп, аның музеена бармау хата булыр иде.

Галимҗан аганың Кырымны яратканлыгы бөтен сүзеннән, бу сүзләрне әйтешеннән күренеп тора иде. Бу минутларда мин аның 1932 елда «Большевик юлы» журналы редколлегиясе члены Якуп Мусанныйф иптәшкә язган хатын хәтерләдем. Бу хат үз вакытында журналда басылып та чыкты. Ул анда: «Мин Кырымны бик артык яраттым. Кырым минем өчен дөньяның иң матур, иң мәгънәле, иң тирән хисләр уяткан яңа әдәби Ватаным булды», – дигән иде. Аның мондый фикерләрен мин соңыннан Мәҗит

Гафурига һәм туганы Мохтар Ибраһимовка язган хатлардан да укыдым.

Чыннан да, Кырым аның өчен яңа әдәби Ватан булды. «Тирән тамырлар»ны ул шунда төгәлләде. «Татар хатыны ниләр күрми»не һәм «Безнең көннәр»не шунда, Ялтада, яңабаштан язып чыкты. Безнең белүебезгә караганда, ул «Безнең көннәр» романының икенче томын да Кырымда иҗат иткән, нәшриятка бирер өчен әзерләгән иде. Кызганычка каршы, билгеле дәһшәтле сәбәпләр аркасында, романның бу өлеше матбугатка чыга алмады, кайдадыр югалды. Мин аның «югалган» кулъязмасы турында уйлыйм да үз-үземә сорау бирәм: «Югалдымы икән ул? Әллә кайда булса да, берәр архивта ятамы икән?» – дим.

Г.Ибраһимов Кырым хезмәт ияләре тормышыннан алынган әсәр язу өметс белән дә яши иде. Кырым язучылары белән очрашкан чакларда ул моны безнең исебезгә төшергәләп куйгалый һәм шуның белән безне шатландыра иде. Нинди кызганыч, художникның бу матур хыялы тормышка ашмый калды.

*1965 ел.*

## АЛАБУГАДА ЯШӘП ЭШЛӘДЕ

**(Кәрим Җаманаклының 100 еллыгына)**

Әтием Кәрим Рәшидов-Җаманаклының тормыш юлы, аның яшендәге кешеләрнең хәятләре кебек, ике дәвергә бүленгән иде: сугышка кадәрге Кырымдагы тормышы һәм сугыштан соң ватаннан еракта уздырган гомере ...

Әтиемне тәкъдир Татарстанның ул заманнарда кечкенә бер шәһәрчегә булган Алабугага китереп ташлый. Электән Вятка губернасына караган бу шәһәр атаклы рус рәссамы И.И. Шишкин, 1812 елгы сугышта катнашкан һәм М.И. Кутузовның сугышчан дусты, язучы Н.А. Дурова белән мәшһүр. Бай рус сәүдәгәрләре бертуган Стахеевларның таштан салган бинадары, чиркәүләр, таш түшәлгән урамнар шәһәрне бизәп торалар.

Совет власте урнашканнан соң элек хатын-кызлар өчен епархиаль училище булган бинада Укытучылар институты ачыла. Кызыл кирпечтән салынган һәм кечкенә гөмбәзле бу бина шәһәрнең бөтен архитектурасына һәм табигать манзарасына бик туры килеп тора иде. Институт Кама буеннан килеп пристаньга якынлашкан пароходлардагы юлчыларга ерактан ук күренеп тора. Филология фәннәре кандидаты К.Рәшидов менә шул Укытучылар институтына килә.

1945 ел. Фашизмны җиңү сөенечен Кырымнан аерылу ачысы күләгәли. Тик ни кыласың, яшәргә, яңа

тормышка ияләшергә, балаларны тәрбияләп үстерергә кирәк ...

Әтием башта укытучы булып эшләде. Соңрак доцент булып, әдәбият кафедрасы мөдире итеп билгеләнде. Шул вазифада һәм укытучы булып гомеренең азагына кадәр эшләде.

Ул еллар бик авыр еллар иде: Кырым кешесе ияләшмәгән 30-35 дәрәҗә суык кышлар, сугыштан соңгы юклык, ачлык, югары хәзерлекле белгечләрнең булмавы ...

Кафедраның төп максаты – татар һәм рус телләре, әдәбиятлары мөгаллимнәрен җитештерү. Татарстанның ерак авылларыннан институтка укырга килгән шәкертләрнең хәле җиңел булмый. Чөнки рус телен бик йомшак беләләр. Укытучылар мондый студентларга махсус курслар оештырып, туган тел һәм әдәбият белән бергә рус телен тагын да тирәнрәк, яхшырак өйрәнергә, рус теле аша донья әдәбияты, мәдәнияте белән танышырга ярдәм итәләр. Табигый ки, кафедраның эшчәнлеге шул заманның «социалистик чынбарлыгыннан» аерылып тора алмый. Әтиемнең «Марксистик-ленинчыл этика» һәм әдәбият теориясе буенча кульязма лекцияләре сакланып калган. Бу лекцияләрдә идеология мәсьәләләре, яшьләрне коммунистик рухта тәрбияләү белән бәйле фикерләр зур урын алып тора. Хәзерге заман күзлегеннән караганда бу хәл бик гаҗәп һәм сәер күренә. Фәкать ап-ачыктыр ки, совет режимының милләтләргә каршы, бик күп акыл һәм сәләт ияләренә карата эшләгән коточкыч хаксызлыкларын, рухи изүнең елдан-ел арта баруын күргән әтием бик борчыла һәм күңелсезләнә торган иде.

Ничек кенә булмасын, әтием исән чакта сугышка кадәрге дусларын күрү бәхетенә ирешә алды. 1960 елларда Урта Азиягә сәфәрләре вакытында «Ленин байрагы» газе-

тасын укуы, Язучылар Берлегенең кырым татар бүлеге эшчәнлегенә катнашуы аны рухландыра, җанландыра, халкының бу фаҗигаләре бер көн килеп бетәчәк, милләткә сугылган «хаин» тамгасы ниһаять юылачак, ватанга кайтырга рөхсәт биреләчәк дип өметләнергә көч бирә торган иде. Әтиемнең Ташкенттан алып кайткан кырым татар пластинкаларын сәгатьләр буе тыңлаганын бик яхшы хәтерлим. Аларны безгә килгән кунаклар да тыңлыйлар иде. Шул рәвешле ерак Алабугада кырым татар музыкасы һәм мәдәнияте белән танышу мөмкинлеге туа иде.

Әтием 1965 елда вафат булды. Әмма хатирәсе шәһәрдә яши, үлми. Университет музеенда әтиемнең тәрҗемәи хәле һәм иҗаты белән бәйле материаллар тупланган, әдәбиятчы буларак хезмәтләре өйрәнелә. Шәһәрдә төзелгән яңа урамнарның берсе аның исемен йөртә.

Бу елның июнь аенда Алабуганы яңадан зыярәт иттем. ЮНЕСКО карамагы астында булган бу заповедник-шәһәрнең үсүен, матурлануын күрдем. Ботен музей һәм тарихи урыннар тәртипкә китерелгән, урамнарга асфальт салына, яңа микрорайоннар төзелә. 1941 елның август аенда Алабугада вафат иткән Марина Цветаева рухына мемориал һәм мәркәз ачылган. Татар телендә язылган белдерү һәм рекламалар, колакка хуш килгән татар сүзләре – алга китеш галәмәтләре. Хәзер инде университетта Кәрим Рәшидовның шәкертләре могаллим һәм галим буларак хезмәт итәләр. Татар әдәбияты кафедрасы мөдире Н.Н. Лаисов, доцент Ф.А. Мурадимова, Казан университеты профессоры Т.Н. Галиуллиннар кайчандыр карьераларын К.Р. Рәшидов җитәкчелегендә башлаган иделәр. Инде үзләре чал чәчле булган бу галимнәр остазлары хакындагы истәлекләре белән бүлешкәндә, Кәрим Җаманаклының мәрхәмәтлелеге, түбәнчелекле булуы турында кайтып-

кайтып сөйләделәр. 1966 елда үткәрелгән К.Рәшидовның юбилеен да хәтерләделәр. Ул елны пединститут залында остазларын искә алыр өчен дуслары, мәсләктәшләре белән бергә бик күп укучылары да җыелган иде. Юбиляр адресына кырым татар талэбәләреннән килгән хат һәм телеграммалар К.Җаманаклы эшчәнлегенә булган мөнәсәбәтне күрсәтеп тора иде.

Кырым татар галимнәре арасында беренчеләрдән булган филология фәннәре кандидаты, әдәбият белгече, фольклорчы, укытучы, шагыйрь Кәрим Җаманаклының туууна 2005 елның гыйнварында 100 ел тула. Кырымның кечкенә бер авылында туган егет, галим булып җитешеп, зур тырышлык һәм гайрәт белән үз халкының мәдәни мирасын өйрәнүгә үзеннән өлеш кертте, кырым татар шагыйре һәм мәгърифәтчесе Шамил Туктаргазыйны дөньяга таныттм, кырым татар фольклорын җыеп системага салды: әкият, эпик дастаннар, кече жанрлар буенча җыентыклар хәзерләде. А.С. Пушкин исемендәге Кырым тел һәм әдәбият институтының җитәкчесе булып эшләгәндә халык авыз иҗатын өйрәнүне гыйльми нигезгә кую өчен көрәште. Халыкның сүз хәзинәсен псевдостимуляциядән коткарып, бу хәзинәнең бөтен милли хосусиятләрен күреп, жанрлар буенча системалаштырып яшәтергә тырышты. Бу эшләр 1930-1940 елларда башланган иде. Без – хәзерге филологлар, аның башлаган эшләренә рәхмәтле булып, бу өлкәдәге эзләнүләрне дәвам итәргә тиешбез.

Алабуга кырыенда бер татар зираты бар. Төрле милләттән педагоглар хәзерләү өчен көч түккән, гомеренең соңгы көннәренә кадәр ватанын сагынып яшәгән Кәрим Җаманаклы шул мазарстанда күмелде. Кара мәрмәрдән ясалган кабер ташына «Сөйгән балаларыңнан» дип язылган.

Әмма тормыш дәвам итә. Аның исемен йорткән урамда яңа йортлар салына, балалар туа. Университет музеенда бер стенд өстендә кырым татар бию көйләре һәм җырлары язылган пластинкалар ята, саргайган фоторәсемнәрдән исә күзләренең тирәнлегендә сагыш һәм кайгы чагылган чал чәчле мәгъруур Кеше безгә карап көлемсери ...

*Нурия Кәримовна Эмирсуинова*
*(«Кырым тавышы» газетасы.*
*2004 ел, 15 октябрь, № 42 (568)*

# ЭЧТӘЛЕК

*Әлфинә Сибгатуллина. Кырым бакчасыннан өзелгән гөл* ........... 6

***Шигырьләр***

*Алабуга-Җаманак* ........................................ 31
*Телим, әлбәттә!* ........................................ 32
*Дусларыма* ........................................ 34
*Егетлек даны* ........................................ 35
*Нинди тын* ........................................ 36
*Болгарлар* ........................................ 37
*Хөрмәтем зур Казанга* ........................................ 39
*«Тукай» поэмасыннан* ........................................ 40
*Кара диңгез кырыенда* ........................................ 42
*Кипарис турында баллада* ........................................ 43
*Кем уйлаган* ........................................ 45
*Баллада о кипарисе* ........................................ 47
*Море* ........................................ 48
*Первое радио в ауле* ........................................ 49
*Стой, паровоз!* ........................................ 50

***Фәнни язмалар***

*Кырым татар әкиятләре* ........................................ 53
*Тукай, Сабир һәм Туктаргазый* ........................................ 79
*Тукай шигърият йолдызы ул* ........................................ 113
*Тарас Шевченко и татарская литература* ........................................ 124
*Тугайбәй хакында поэма* ........................................ 139
*Гомәр Ипчи (Алкедай)* ........................................ 148

***Хатирәләр***

*Кырым аның әдәби ватаны булды* ........................................ 163
*Кави Нәҗми телеграммасы* ........................................ 165
*Ике галим арасында беседа башланып китте* ........................................ 168
*Безгә гыйльми үзәк кирәк* ........................................ 171
*Гыйлемсез, белемсез тик бер талант кына җитәрлек түгел.* 176
*Без Казанда* ........................................ 182
*Шамил Усманов безнең янда* ........................................ 189
*Әдипләр һәм галимнәр дөньясында* ........................................ 193
*Нурия Эмирсуинова. Алабугада яшәп эшләде* ........................................ 202

Җаманаклы Кәрим.
Әсәрләр
(төзүчесе Әлфинә Сибгатуллина)

Верстка - В.Бобков. Дизайн - А.Савенко.
Художник - Р.Саляхов
Издательство ЕГПУ.
Лиц. №0317 от 20.10.2000
Сдано в набор 3.01.2005 г. Подписано к печати 5.2.2005 г.
Формат 60x90 1/16. Усл. п.л. 13,0. Тираж 300 экз.
Заказ № 358

издательство